| 34. | Наратлык киптерелгән (Ст. ос.) ТУМ: А2 – А4, В1 – В3 Бонитет 3 – 4 Торфлык киптерелгән | 9С1Б + Ос | Киптерел-гән торфлыклар | Торфлы-череп баручы | Сирәк нарат | Сирәк – тал эт шомырты | Кассандра, түбәнлекләрдә сазанак, түмәрләрдә кара җиләк, нарат җиләге очрый | Күке җитене, микрокалку-лыкларда яшел мүкләр | Канәгать ләнерлек, нарат, каен белән | Билгесез | Тубыл-гылы | СР Е.з |
| 35. | Каенлык киптерелгән (Б т.ос.) ТУМ: С2 – С4 Бонитет: 2 – 3 (4) Торфлык киптерелгән | 7б2Ос 1С + Ол | Киптерел-гән торфлыклар | Торфлы-череп баручы | Сирәк нарат | Тал, эт шомырты, балан | Сирәкләндерел-гән кара җиләктән, мамыкчадан, башаклы үләннән, ожиктан, төертамырдан тора | Күке җитене | Канәгать ләнерлек каен белән | Билгесез | Тубыл-гылы | СР Л/к |

2.1.6. Агач материалы әзерләү өчен урманнардан файдалану сроклары һәм башка белешмәләр

Һәр урман бүлемтегендә урман үсентеләрен кисү, трелевкалау, агач материалын өлешчә эшкәртү, саклау һәм урман читенә чыгару агач материалын әзерләү максатларында урман кишәрлегеннән файдаланучы зат тарафыннан урман декларациясе нигезендә декларацияләнгән чор башланганнан соң 12 ай эчендә яисә урман үсентеләрен сату-алу шартнамәсе нигезендә агач материалын әзерләү очрагында – урман үсентеләрен сату-алу шартнамәсе белән билгеләнгән срок эчендә гамәлгә ашырыла.

Урман үсентеләрен кисү, саклау һәм агач материалын читкә чыгару буенча әлеге пунктта күрсәтелгән срокларны арттыру шушы таләпләрне үз вакытында үтәүне булдырмый кала торган уңайсыз һава шартлары килеп туган очракта рөхсәт ителә.

Урман үсентеләрен кисү, саклау һәм агач материалын читкә чыгару срогы урманнан файдаланучының язма гаризасы нигезендә 12 айдан да күбрәк вакытка озайтылырга мөмкин.

Агач материалын әзерләгәндә:

а) агач өстерәтү трассалары һәм урман юллары сыйфатында елгалар һәм инешләр үзәннәрен файдалану рөхсәт ителми;

б) урман үсентеләренә, үләнле өслеккә һәм туфракка зарар китерү, урманнарны сәнәгать калдыклары һәм урман бүлемтегеннән читтә бүтән калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;

в) юлларны, күперләрне, урман юлларын, шулай ук киптерү челтәрен, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, су агып төшү урыннарын, инешләрне, елгаларны саклап калырга кирәк;

г) аударылган агачларны (киселгән һәм урман бүлемтегендә калдырылган агачларны да кертеп) һәм кисkәннән соң асылынып калган агачларны шунда калдыру, шытып чыккан һәм сакларга тиешле урман үсентеләрен зарарлау яисә юк итү рөхсәт ителми;

д) чик янындагы, квартал, урман бүлемтен билгеләүче һәм башка баганаларны һәм агачлардагы һәм түмәрләрдәге тамгаларны, келәймәләрне һәм номерларны юк итү яисә зарарлау тыела;

е) кисү өчен билгеләнмәгән һәм агач материалы әзерләү кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе урман законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны шул исәптән орлыкландыру чыганакларын һәм плюслы агачларны кисү һәм зарарлау тыела;

ж) рөхсәт ителгән чор (срокны озайтуны да кертеп) узганнан соң, агач материалы әзерләү, шулай ук файдалану хокукы туктатып торылганнан яисә туктатылганнан соң агач материалын әзерләү рөхсәт ителми;

з) урман бүлемтегендә агач материалын билгеләнгән срокта (срокны озайтуны да кертеп) чыгармыйча калдыру рөхсәт ителми;

и) урман бүлемтеген эшкәртүнең технологик картасы белән каралмаган урыннарда агач материалын чыгару, трелевкалау рөхсәт ителми;

к) урман бүлемтеген чистарту эшләрен башкармау һәм үз вакытында башкармау рөхсәт ителми;

л) туфракның өске уңдырышлы катламын, агач өстерәтү урыннарыннан һәм төяү урыннарыннан тыш, бозу рөхсәт ителми.

Агач материалын әзерләгәндә Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләр сакланып калырга тиеш.

“Агач материалы әзерләү өчен рөхсәт ителми торган агачлар һәм куаклар төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында” Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 05.12.2011 г. № 513 боерыгы белән расланган агачлар һәм куаклар төрләре (токымнары) агач материалы әзерләү өчен рөхсәт ителми.

Агач материалын әзерләгәндә биологик күптөрлелекне арттыру максатларында урман бүлемтегендә аерым кыйммәтле агачлар һәм аларның төрләре теләсә кайсы яруста сакланып калырга мөмкин (картайган агачлар, куышлы, кошлар оялары булган агачлар, шулай ук алар оя кору һәм вак хайваннар яшеренү һәм башкалар өчен потенциаль яраклы агачлар).

Агач материалы әзерләү максатларында кисү өчен билгеләнгән урман кишәрлеге мәйданын (алга таба – урман бүлемтеге) бүлеп бирү, шулай ук урман үсентеләренең сан һәм сыйфат характеристикалары һәм әзерләнергә тиешле агач материалы күләме билгеләнә торган урман бүлемтеген таксацияләү уздырыла. Урман бүлемтеге бүлеп биргәндә җирлектә урман бүлемтекләренең чикләре билгеләнә һәм сызып куела, сайлаулы кисүләр уздырганда кисү өчен билгеләнгән агачлар билгеләп куела.

Урман бүлемтекләрен бүлеп бирү һәм таксацияләү түбәндәгеләр тарафыннан тәэмин ителә:

- урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре нигезендә агач материалы әзерләүче гражданнар һәм юридик затлар;
- үзләренә даими (сроксыз) файдалануга тапшырылган урман кишәрлекләрендә агач материалын әзерләү белән шөгыльләнүче федераль дәүләт учреждениеләре;
- Россия Федерациясе Урман кодексының 82-84 статьялары нигезендә билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, урман үсентеләрен сату-алу шартнамәләре нигезендә гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан агач материалы әзерләү өчен.

Барлык кисү рәвешләрендә урман бүлемтекләрен бүлеп бирү урман кварталы чикләрендә, кагыйдә буларак, карсыз вакытта гамәлгә ашырыла. Урманнарны таксацияләү өчен билгеләнгән бүлемтекләр, мәйданы Агач материалын әзерләү кагыйдәләре белән билгеләнгән күләмнәрдән артмаган рәвештә кисүгә бирелә.

Эксплуатацион урманнарда өлгергән, картайган урман үсентеләрен кискәндә урман бүлемтегенә урман таксацияләү бүлемтекләре кысаларында әлеге урман бүлемтеге чикләрендә гомуми мәйданы 3 гектардан артмаган өлгереп килүче агачлар бүлемтекләре дә кертелергә мөмкин.

Урман кварталында кисүгә өлгергән урман үсентеләренең бер үк вакытта берничә катнаш урман таксацияләү бүлемтеге бирелергә мөмкин, әмма аларның суммар мәйданы урман үсентеләренең иң күп токымы өчен билгеләнгән урман бүлемтеге зурлыгыннан артмаска тиеш.

Урман үсентеләрен кисүләр сайлаулы кисүләр яисә тоташ кисүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Сайлаулы кисүләр тиешле җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә агачларның һәм куакларның бер өлешен кисүдән гыйбарәт (Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 2 өлеше).

Тоташ кисүләр дип тиешле җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урман үсентеләре киселә, ул чакта аерым агачлар һәм куаклар яисә агачларның һәм куакларның төркемнәре урманнарны торгызу өчен сакланып калдырыла (Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 3 өлеше).

Агач материалы әзерләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә тоташ кисүләр әлеге урман кишәрлекләрендә урманнарны торгызу шарты белән генә рөхсәт ителә (Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 5 өлеше).

Киселә торган агчларның һәм кисүләр технологияләренең характерына карап, урманчылыкта өлгергән, картайган урман үсентеләрен кисүләрнең түбәндәге төрләре уздырылырга мөмкин: ирекле-сайлаулы, төркем-төркем-сайлаулы, тигез-акрынлап, төркем-төркем-акрынлап (чокыр-чокыр), полоса аша акрынлап, озаклап-акрынлап кисүләр.

Ирекле-сайлаулы кисүләр вакытында мәйдан буйлап тигез рәвештә беренче чиратта зарарланган, картайган, акрын үсүче өлгергән агачлар киселә, әмма бу чакта агач токымнарын торгызу тәэмин ителергә, урманның яклау һәм мохит барлыкка китерү сыйфатлары сакланып калырга тиеш. Аяк өсли агачларның әлеге кисүләрдән соң тулылыгы 0,5тән түбәнрәк булмаска тиеш.

Төркем-төркем-сайлаулы кисүләр төркем-төркем төрле яшьтәге структурасы булган урман үсентеләрендә алып барыла, аларда картайган һәм өлгергән агачлар урман бүлемтеге мәйданы буенча урнашуларына карап, төркем-төркем киселә. Киселүче төркемнәр мәйданы 0,01 дан 0,5 гектарга кадәр тәшкил итә.

Тигез-акрынлап кисүләр вакытында бер үк класслы яшьтәге аяк өсли агачлар урман бүлемтегендә икенче ярустагы урман үсентеләрен һәм шытып чыккан үсентеләрне кисү барышында башлангыч яисә юлдаш урманнарны торгызуны тәэмин итеп, тигез генә сирәкләү юлы белән берничә мәртәбә башкарыла. Тигез-акрынлап кисүләр шулай ук яшәү көче басымчакланган шытып чыккан үсентеләре булган биек һәм уртача тулылыктагы, өлгерү дәрәҗәсе төрле булган, агач токымнары белән барлыкка китерелгән аяк өсли агачларда, катнаш урман үсентеләрендә (ылыслы-яфраклы, усак-каен һәм башка агачларда) гамәлгә ашырыла.

Башлангыч кисүләр вакытында аяк өсли агачлар тулылыгы 0,5кә кадәр кими. Үсентеләр булмаганда яисә аларны барлыкка китерү өчен яшь үсентеләр җитәрлек булмаганда, тиешле үсеш шартларында тигез-акрынлап кисүләр вакытында урманны торгызуга ярдәм чаралары башкарыла.

Төркем-төркем-акрынлап (чокыр-чокыр) кисүләр вакытында ике класслы яшьтәге агачлар шытып чыгучы оя-оя үсентеләр булган урыннарда төркем-төркем (чокыр-чокыр) берничә мәртәбә киселә (шулай ук аларның тагын шытып чыгулары тәэмин ителә), бер үк яшьтәге урман үсентеләрендә яшь үсентеләр төркем-төркем урнаштырыла. Өлгергән агачны кисү 30 - 40 ел буена 3-4 алымда башкарыла торган 0,01дән алып 1,0 гектарга кадәр мәйданнарда яшь үсентеләр төркемнәре тирәсендә гамәлгә ашырыла.

Озаклап-акрынлап кисүләр, әлеге шартларда тотрыклы булып кала торган, өлгереп җитмәгән, эксплуатацион күләмнәргә җиткән агачлар өлешен икенче

алымга калдырып, ике алымда төрле яшьтәге урман үсентеләрендә башкарыла. Беренче алымнан соң аерым тулылык куе төстәге ылыслы урманнарда 0,5тән һәм ачык төстәге ылыслы урман үсентеләрендә 0,4тән ким булмаска тиеш. Кисү алымнарын кабатлау чоры - 30 - 40 елдан соң.

Басу аша акрынлап кисүләрне уздырганда агач биеклегеннән артмаган киңлектәге билгеле бер тәртиптә чиратлаша торган полосаларда бер класслы яшьтәге агачлар дүрт алымда киселә, ә имәнлекләрдә – имән урман культураларын агачның икеләтелгән биеклегендә киләчәктә булдыру шарты белән киселә. Кисүнең мондый төре бер үк яшьтәге җилгә чыдам, яхшы дренажланган туфракта үсүче урман үсентеләрендә (беренче чиратта йомшак яфраклыларда, кыйммәтле токымнарның икенче ярусы һәм яшь үсентеләр булган) гамәлгә ашырыла

Басу аша кисүләр кискән вакытта тотрыклылыгын югалтучы агачларда кулланылмый.

Тигез-акрынлап, төркем-төркем-акрынлап (чокыр-чокыр), басу аша акрынлап, озаклап-акрынлап кисүләрнең иң соңгы алымы бары тик урман бүлемтегендә яшәргә сәләтле, урман үсентеләрен формалаштыруны тәэмин итүче, йомыкланган яшь үсентеләр формалаштырганнан соң гына гамәлгә ашырыла.

Кисүләр урыннарын кисү калдыкларыннан әрчү агач материалын әзерләү белән бергә башкарыла.

## 2.2. Чәер әзерләү өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Чәер әзерләү өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 31 статьясы, Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 24.01.2012 № 23 боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләре белән регламентлана.

Чәер әзерләү ылыслы үсентеләрнең кайрыларына кирт салу, чәерне саклау һәм аны урманнан читкә чыгару рәвешендәге эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт. Гражданнар, юридик затлар чәер әзерләүне урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашыралар. Урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе 10 елдан алып 49 елга кадәр срокка төзелә. Чәер әзерләү агач материалы әзерләү өчен билгеләнгән урманнарда гамәлгә ашырыла.

Кирт салуга өлгергән һәм картайган урман үсентеләре тапшырыла:

I - IV бонитет класслы нарат үсентеләре;

I - III бонитет класслы чыршы үсентеләре;

I - III бонитет класслы карагай үсентеләре;

Урта яшьтәге, өлгереп килүче һәм өлгергән I - III бонитет класслы пихта үсентеләре.

Кирт салу өчен яраклы дип сәламәт, кәүсәсенең диаметры: наратның һәм карагайның – 20 см һәм аннан да артык булган, чыршының - 24 см һәм аннан да артык булган зарар салынмаган агачлар санала.

Здоровые деревья сосны и лиственницы с диаметром ствола от 16 до 20 см могут отводиться в подсочку не ранее чем за 2 года до рубки.

Сәламәт, кәүсәсенең диаметры 16 сантиметрдан алып 20 сантиметрга кадәр булган нарат һәм карагай агачлары кирт салу өчен кисәренә кимендә 2 ел кала тәкъдим ителергә мөмкин.

Түбәндәгеләргә кирт салу рөхсәт ителми:

зарарлы организмнар чыганакларындагы урман үсентеләренә;

урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар йогынтысы аркасында зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман үсентеләренә;

Россия Федерациясе законнары нигезендә агач материалы әзерләү максатларында өлгергән һәм картайган урман үсентеләрен тоташ яисә сайлап алып кисүләр уздыру рөхсәт ителми торган урманнардагы урман үсентеләренә;

даими урман орлыклары кишәрлекләрендә, урман орлыклары плантацияләрендә, генетик резерватлардагы урман үсентеләренә, шулай ук плюслы агачларга, орлыкка дигән урман үсентеләренә, агачларга, орлык бирүчеләргә, орлык калкулыкларына һәм полосаларына.

Кирт салуга түбәндәгеләр тапшырылырга мөмкин:

урман үсентеләренең агач материалы гомуми запасының кимендә 40 проценты өлгергән агач булган урман үсентеләре;

сазланган туфракларда IV бонитет класслы һәм V бонитет класслы нарат үсентеләре;

нарат сирәклекләре;

нарат орлыклыклары, үз вазыйфасын үтәүче орлык полосалары һәм калкулыклары;

сайлап кисүгә билгеләнгән нарат агачлары;

2 - 3 га кадәр мәйдан биләгән нарат үсентеләре.

Кирт салуның 10 – 15 еллык срогын тәэмин итү өчен өлгергән һәм картайган нарат үсентеләре җитешмәгәндә, кирт салу тәмамланган срокка кисү яшенә җитәчәк һәм кисү өчен билгеләнгән өлгереп килүче агачларда кирт салу рөхсәт ителә.

### 2.2.1. Агачларга кирт салу фонды

Урманчылыкның Агачларга кирт салу фонды 2.2.1 нче таблицада китерелә.

2.2.1 нче таблица

Агачларга кирт салу фонды

Мәйдан, га

| № т/с | Күрсәткечләр | Кирт салу |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Барлыгы кирт салу өчен яраклы өлгергән һәм картайган үсентеләр: | - |
| | Шулардан: | |
| | Кирт салуга җәлеп ителмәгән | - |
| | Кирт салу өчен рентабельле түгел | - |

### 2.2.2. Кирт салу төрләре

2.2.2. Кирт салу төрләре:
- гади кирт салу
- А һәм Б төркемнәре чәер чыгу стимуляторлары булган кирт салу
- хлорлы известьле кирт салу
- күкерт кислоталы кирт салу

2.2.2 нче таблица

| Кирт салу төрләре, стимулятор | Кирт салу категорияләре |
|---|---|
| Гади кирт салу | I, II, III |
| А һәм Б төркемнәре чәер чыгу стимуляторлары булган кирт салу | I, II, III |
| Хлорлы известьле кирт салу | I, II |
| Күкерт кислоталы кирт салу: | |
| 50%лы куертылган ачылык белән | I |
| 75%-лы куертылган ачылык белән | II |

2.2.3. Агачта каррлар саны һәм агач диаметрына бәйле рәвештә каррлар арасындагы ременьнәр киңлеге

Төрле категорияләрдәге кирт салу өчен агачлар кәүсәләрендә каррларның саны һәм агач диаметрына бәйле рәвештә каррлар арасындагы ременьнәрнең гомуми киңлеге 2.2.3.1 нче таблицада китерелә.

2.2.3.1 нче таблица

Төрле категорияләрдәге кирт салу өчен агачлар кәүсәләрендә каррларның саны һәм агач диаметрына бәйле рәвештә каррлар арасындагы ременьнәрнең гомуми киңлеге

| 1,3 метр биеклектә агач кәүсәсе диаметры, см | I категория | | II категория | | III категория | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | агач кәүсәсендә каррлар саны, данә | каррлар арасындагы ременьнәр-нең гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсендә каррлар саны, данә | каррлар арасындагы ременьнәр-нең гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсендә каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы ремень-нәрнең гомуми киңлеге, см |
| 20 | 1 | 20 | 1 | 30 | - | - |
| 24 | 1-2 | 20 | 1-2 | 30 | - | - |
| 28 | 1-2 | 20 | 1-2 | 30 | 1 | 28 |
| 32 | 1-2 | 20 | 1-2 | 32 | 1 | 32 |
| 36 | 1-2 | 20 | 1-2 | 36 | 1 | 36 |
| 40 | 1-2 | 24 | 1-2 | 40 | 1 | 40 |
| 44 | 2 | 24 | 2 | 44 | 1 | 44 |
| 48 | 2 | 24 | 2 | 48 | 1 | 48 |
| 52 | 2 | 30 | 2 | 52 | 1 | 52 |
| 56 | 2 | 30 | 2 | 56 | 1 | 56 |
| 60 | 2 | 30 | 2 | 60 | 1 | 60 |
| 60тан артык | 2-3 | 40 | 2-3 | агач кәүсәсе | 2 | агач кәүсәсенең |

| 1,3 метр биеклектә агач кәүсәсе диаметры, см | I категория | | II категория | | III категория | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | агач кәүсәсендә каррлар саны, данә | каррлар арасындагы ременьнәр-нең гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсендә каррлар саны, данә | каррлар арасындагы ременьнәр-нең гомуми киңлеге, см | агач кәүсәсендә каррлар саны, данә | каррлар арасында-гы ремень-нәрнең гомуми киңлеге, см |
| | | | | диаметрына тигез | | 1/2 диаметры-на тигез |

Чәер чыгару стимуляторы сыйфатында күкерт кислотасы ярдәмендә тамга салганда каррлар арасындагы ременьнәрнең гомуми киңлеге 4 сантиметрга арттырыла.

Соңгы елда нарат урман үсентеләрен кисү алдыннан каррлар арасындагы ременьнәрнең гомуми киңлеге кимендә 10 см итеп калдыру рөхсәт ителә.

Каррлар агач кәүсәсе әйләнәсе буенча тигез бүленә. Каррларны тигез урнаштыру мөмкин булмаса, каррлар арасындагы ременьнәрнең минималь киңлеге кимендә 10 см булырга тиеш. Каррлар арасындагы ременьнәр агач кәүсәсенең сәламәт ягына гына салынырга тиеш.

Каррлар арасындагы ременьнәрнең гомуми киңлеген киметү яисә 15 нче таблицада күрсәтелгән каррлар киңлеген арттыру рөхсәт ителми.

Нарат урман үсентеләрендә тамга салганда чәер чыгару стимуляторлары куллану рөхсәт ителә. Бер сезон эчендә берүк агачларда тамга салганда чәер чыгару стимуляторлары куллану рөхсәт ителми.

Чәер чыгару өчен актив матдәләрнең су катышмалары һәм аларның төрле концентрациядәге катышмалары рәвешендә барлык стимуляторлары да рөхсәт ителә. Хлорлы известь пасталар рәвешендә кулланыла. Күкерт кислотасы капрон яисә каолин белән куертылган сыеклык рәвешендә кулланыла.

Чәер чыгару стимуляторлары аларны куллану инструкцияләре нигезендә катгый рәвештә кулланылырга тиеш.

Сазланган туфракларда үсүче нарат урман үсентеләрендә һәм зәгыйфьләнгән нарат урман үсентеләрендә тамга салганда күкерт кислотасын куллану рөхсәт ителми.

Күкерт кислотасы кулланып тамга салына торган нарат урман үсентеләре кирт салу срогы узганнан соң киселергә тиеш.

Күкерт кислотасы кулланып, беренче сезон башланганда һәм һәр сезон азагында кирт салганда 3-4 мм тирәнлектә күкерт кислотасы кулланмыйча гына саклагыч яңартулар төшерелә.

Туктап торуның, яңартулар алымының, яңартулар тирәнлегенең һәм буразнаның иң чик мөмкин күрсәткечләре 2.2.3.2 нче таблицада китерелә.

2.2.3.2 нче таблица

Туктап торуның, яңартулар алымының, яңартулар тирәнлегенең һәм буразнаның иң чик мөмкин күрсәткечләре

| Кирт салу, стимулятор төрләре | Кирт салу категория-се | Туктап тору кимендә, тәүлек | Яңарту адымы, артмаган, мм | Яңарту тирәнлеге, артмаган, мм | Буразна тирәнлеге, артмаган, мм |
|---|---|---|---|---|---|
| Гади кирт салу | I | 2 | 15 | 6 | 8 |
| | II-III | 3 | 15 | 4 | 6 |
| А һәм Б төркемнәре чәер чыгу стимуляторлары булган кирт салу | I | 3 | 20 | 4 | 6 |
| | II-III | 4 | | 4 | 6 |
| Хлорлы известьле кирт салу | I | 7 | 30 | 4 | 6 |
| | II | 10 | 40 | 4 | 6 |
| Хлорлы известьле кирт салу | I<br>II | 7<br>14 | 40<br>50 | 2<br>2 | 3<br>3 |

Сайлап алып кисүләргә билгеләнгән нарат урман үсентеләре кирт салуга беренче мәртәбә кисүләргә 5 ел кала тапшырыла. Нарат урман үсентеләренә кирт салу озынлыгы кисүләр арасындагы чор озынлыгына бәйле була, әмма ул 15 елдан да артмаска тиеш.

Сайлап алып кисүләр уздыру карала торган төрле яшьтәге нарат урман үсентеләрендә кирт салу кисүләрнең 10 елы эчендә уздырылырга мөмкин. Бу чакта беренче дәвердә киселергә тиешле агачларга гына кирт салына.

## 2.2.4. Чәер әзерләү өчен урманнардан файдалану сроклары

Нарат урман үсентеләренә кирт салу срогы 15 елдан артмаска тиеш.

Кирт салу уздыруның озынлыгына һәм нарат урман үсентеләрен кисүгә керешү срогына бәйле рәвештә кирт салу өч категория буенча уздырыла:

I категория буенча – 1-3 елдан соң кисүгә кертелгән нарат урман үсентеләре;

II категория буенча - 4-10 елдан соң кисүгә кертелгән нарат урман үсентеләре;

III категория буенча - 11-15 елдан соң кисүгә кертелгән нарат урман үсентеләре.

Кирт салу уздыруның дәвамлылыгы категорияләр буенча 11.1 нче таблицада китерелә.

2.2.4 нче таблица

Кирт салу уздыруның дәвамлылыгы

| Кирт салу срогы, ел | Кирт салу чоры, эксплуатация башланганнан бирле, еллар | Кирт салу уздыруның дәвамлылыгы, ел | Кирт салу категориясе |
|---|---|---|---|
| 15 | 1 елдан 5 елга кадәр | 5 | III |
| | 6 елдан 12 елга кадәр | 7 | II |

| Кирт салу срогы, ел | Кирт салу чоры, эксплуатация башланганнан бирле, еллар | Кирт салу уздыруның дәвамлылыгы, ел | Кирт салу категориясе |
|---|---|---|---|
| | 13 елдан 15 елга кадәр | 3 | I |
| 10 | 1 елдан 7 елга кадәр | 7 | II |
| | 8 елдан 10 елга кадәр | 3 | I |

Нарат урман үсентеләре бер категориядән икенчесенә күчкәндә кирт салуның технологик параметрлары үзгәрә.

## 2.3. Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыю өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыю өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе УКның 32 статьясы һәм “Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыю кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 05.12.2011 №512 боерыгы, “Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 22.05.2008 № 22-ТРЗ (22.12.2012 ред.) Татарстан Республикасы Законы белән регламентлана.

Агач булмаган урман ресурсларына түмәрләр, каен тузы, агачлар һәм куак кайрылары, чыбык-чабык, ботаклардан терлек азыгы, чыршы, пихта, нарат һәм (яисә) башка ылыслы токымнарның ботаклары, яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлар, мүк, урман туфрагындагы үсемлекләр җәймәсе, камыш, кыяклылар һәм башка шундый урман ресурслары керә.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю гражданнар, юридик затлар тарафыннан – эшкуарлык эшчәнлеге башкару максатларында, ә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен гамәлгә ашырыла.

Агач булмаган урман ресурсларын эшкуарлык эшчәнлеге башкару максатларында әзерләү һәм җыю урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе 10 елдан алып 49 елга кадәр срокка төзелә..

Үз ихтыяҗлары өчен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю ирекле һәм түләүсез гамәлгә ашырыла.

Чикләрендә агач булмаган урман ресурсларын әзерләү и җыю өчен урманнардан рөхсәтле файдалану кварталлары исемлеге 1.2 нче таблицада китерелә.

Урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе яисә урман үсентеләрен сату-алу шартнамәсе нигезендә агач материалы әзерләгәндә кисүләрдән калган агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өстәмә шартнамә төзүне таләп итми һәм урманнардан файдалануның аерым төре дип саналмый.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, “Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында” 08.01.1998 № 3-

ФЗ Федераль закон нигезендә наркотик чаралар дип танылган, шулай ук агач материалы әзерләү рөхсәт ителми торган агачлар һәм куаклар төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгән үсемлекләр төрләрен файдалану тыела.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен урман кишәрлекләрен арендалый торган гражданнар һәм юридик затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

- арендалау шартнамәсе нигезендә урманнардан файдаланырга;

- урман инфраструктурасы булдырырга (урман юллары, урман складлары һәм башкалар);

- бирелгән урман кишәрлекләрендә туры паетлар һәм башка вакытлы корылмалар төзергә;

- Россия Федерациясенең урман законнарына каршы килмәсә, башка хокукларга ия булырга.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен урманнардан файдаланучы гражданнар һәм юридик затларның бурычлары түбәндәгеләр:

- урманнарны үзләштерү проектын төзергә;

- урманнарны үзләштерү проекты һәм әлеге Урман хуҗалыгы регламенты нигезендә урманнардан файдаланырга;

- урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын үтәргә;

- гражданнар сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зарар китермәскә;

- туфрак эрозиясе булдырмаучы, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, шулай ук су объектларына һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтыны булдырмаучы яисә чикләүче алымнар белән урманнардан файдаланырга;

- урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен, шулай ук урманнарны карау кагыйдәләрен үтәргә;

- урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен тәэмин итү максатларында, санитар-савыктыру чараларын күрергә (черегән һәм зарарланган урман үсентеләрен кисәргә, урманнарны чүп-чардан, пычранудан һәм бүтән тискәре йогынтыдан арындырырга);

- ел саен урман декларациясен тапшырырга;

- квартал саен 1-ВЛ, 1-ОЗЛ и 1-ИЛ хисапларын тапшырырга;

- Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән бурычларны үтәргә.

### 2.3.1. Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен урманнардан файдалану нормативлары (еллык мөмкин күләмнәре) һәм параметрлары

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләгәндә һәм җыйганда урманнардан рөхсәтле файдалануның еллык мөмкин күләмнәре 2.3.1.1 нче таблицада китерелә.

2.3.1.1 нче таблица

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен урманнардан файдалану параметрлары

| № т/с | Агач булмаган урман ресурсы төре | Үлчәү берәмлеге | Әзерләүнең еллык мөмкин күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Каен тузы | т | 248 |
| 3. | Чыбык-чабык | мең $м^3$ | 17,8 |
| 4. | Ботаклардан терлек азыгы | мең $м^3$ | 4,6 |
| 5. | Чыршы һәм нарат ботаклары | т | 648 |
| 6. | Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлар | мең данә | - |

Агач булмаган урман ресурслары классификациясе (Сударев һәм башкалар, 1991 ел) бар, аның нигезенә барлыкка килү (әзерләү) урыны, ресурсны исәпкә алу (бәяләү) алымы, файдалану характеры белән аерылып торучы 3 төркемгә бүлү салынган (2.3.1.2 нче таблица).

2.3.1.2 нче таблица

Агач булмаган урман ресурслары классификациясе

| Агач булмаган урман ресурслары | Билгеләмә, ГОСТ, ОСТ, ТУ |
|---|---|
| Агачның биомассасы компонентлары (урман калдыклары) | |
| Калын ботаклар | Нигездә 3 см дан артык калынлыктагы агачның кәүсәдән чыгучы агачланагн ян үсентеләре, ГОСТ 17462-84 |
| Нәзек ботаклар | Нигездә 3 см һәм аннан да кимрәк калынлыктагы агачның ботакларыннан чыгучы агачланмаган ян үсентеләре, ГОСТ 17462-84 |
| Агачларның яшел өлеше | Ылыс ябалдашлары, яфраклар, бөреләр һәм агачланмаган агач-куакларның үсентеләре, түбәндәгеләрдән гайре: эт шомырты, агулы сумаха, бүре җиләге, кара аю баланы, еламсар тал, чикләвек, бук, алкалы куак, имән, урман чикләвеге – нигездә кимендә 1 см, ГОСТ 21769-84 |
| Чыршы, каен, юкә, башка токымнар кайрылары | Кәүсәнең, калын ботакларның, нәзек ботакларның агач материалы өлешен каплый торган тышкы ягы, |
| ГОСТ 17462-84 | |
| Нарат, башка токымнарның түмәр агач материалы | Агачның сәнәгать эшкәртүе һәм ягулык буларак куллану өчен билгеләнгән тамыр яны өлеше һәм тамырлары, ГОСТ 17462-84 |
| Урманнан гомер буена файдалану ресурслары | |
| Чәер | Ылыслы агачларны яралаганда агып чыга торган сагызсыман матдә, ОСТ 13-428-82 |
| Баррас | Куерып киткән (катып киткән) чәер – түбән бонитетлы нарат үсентеләренә киртә ясаганда агып чыгучы төп продукт, ОСТ 13-197-84 |
| Чыршы чәере | Кәүсәләрне яралаганда чыгучы үзле (сыек) чыршы чәере, ТУ 13-284-80 |
| Башка урман ресурслары | |
| Тал һәм башка токымнар үсентеләре | Йорт җиһазлары әзерләү (ТУ 56-44-86), Имәниль матдә әзерләү өчен кулланыла торган агач-куак токымнарының яшь ботаклары (ГОСТ |

| Агач булмаган урман ресурслары | Билгеләмә, ГОСТ, ОСТ, ТУ |
|---|---|
| | 6663-74) һәм башкалар |
| Яңа ел чыршылары | ТУ 56 РСФСР 41-81 |

Чыгарылган агач материалының 1000 $м^3$да агач булмаган урман ресурсларының беренчел продукциясен исәпләп чыгару мисалы 2.3.1.3 нче таблицада китерелә.

2.3.1.3 нче таблица

Чыгарылган агач материалының 1000 $м^3$да агач булмаган урман ресурсларының беренчел продукциясе (исәпләп чыгару мисалы)

| Агач булмаган урман ресурслары | Натураль чагылышта нормативлар, м3 | | Беренчел продукция | Бер берәмлек продукциягә чимал чыгымы нормасы | Ресурслардан натураль чагылышта чыгучы продукциянең чагыштырма зурлыгы, % | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | калдыклар барлыкка килү (потенциаль ресурслар) | файдаланугa яраклы (икътисадый мөмкин ресурслар) | | | потенциаль | икътиса-дый мөмкин |
| Эре ботаклар | 110 | 24 | Технологик чимал, м3 | 1,3 | 84,6 | 18,5 |
| Вак ботаклар | 90 | 20 | Агач яшеллеге, т | 2,7-3,3 | 30,0 | 6,7 |
| Кабык | 100 | 70 | Имәниль матдә, т | 2,1-3,6 | 39,2 | 24,8 |
| Түмәрләр | 30 | 15 | Түмәр сагызы, т | 5,4 | 5,6 | 2,8 |
| Чыбык-чабык | 110 | 77 | Төрле токымнардагы һәм озынлыктагы чыбык-чабык, м3 | 1,1 | 100,0 | 70,0 |

Агач яшеллеге – ылыслар, яфраклар (бөреләр) һәм төрле агач һәм куак токымнарының кисүгә үк терлек азыгы яисә терлекләргә витамин продуктлары әзерләү өчен чимал рәвешендә кулланылучы диаметры 0.8 см га кадәр булган агачланмаган нәзек ботаклары (үрентеләре).

Техник яшеллек – эшкәртү өчен кулланыла торган агач яшеллегенең бер өлеше. Наратта ул агач яшеллегенең гомуми массасыннан – 35%, чыршыда – 50%, каенда – 20% тәшкил итә.

Ылыс яшеллеге запасларын билгеләү. Агач яшеллеген әзерләү кисү барышында аударылган төрле яшьтәге үсентеләрдә башкарыла. Агач яшеллеген әзерләү диаметры (d=1,3 м) кимендә 18 см булган үсеп утыручы агачларның өлгергән өлешеннән агач кәүсәсенең 30 %ы озынлыгында нәзек ботакларны кисеп алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агач (техник) яшеллеге запасларын билгеләү региональ норматив-белешмә таблицаларны кулланып башкарыла.

Техник яшеллек запасын билгеләү өчен әлеге үсентеләрнең 1 гектарына агачларның уртача санын белергә һәм аларны калынлыгы баскычлары буенча бүләргә кирәк. Әгәр мондый белешмәләр булмаса, агачларны санап чыгып, 0.5 га сынау мәйданнарын билгеләргә, 1 гектарга һәр баскыч калынлыгы агачларының уртача санын билгеләргә кирәк. Табылган санны бер агачтан чыккан техник яшеллек санына тапкырлап, 1 гектарга аның запасын, аннары чимал базасының барлык мәйданындагы ресурсларын билгелиләр. Исәп-хисаплар вакытында шулай ук билгеле бер агач токымының 1 $м^3$ кәүсә массасына техник яшеллекнең уртача саныннан да чыгарга мөмкин.

Кабык, ылыслар, агач материалы органик булмаган һәм органик катышмалар буенча агач яшеллеге ГОСТ 21769-84 таләпләренә туры килергә тиеш.

Терлек азыгы өчен агач яшеллеген әзерләгәндә эт шомыртын, бүре җиләген, аю баланын, еламсар таллыкны, алкалы куакны, имәнне файдалану рөхсәт ителми.

Нарат һәм чыршы ылыслары ботакларының запасларын билгеләү. Пихта, нарат һәм чыршы ылыслары ботакларының запасларын билгеләү 2.3.1.4 нче, 2.3.1.5 нче региональ норматив-белешмә таблицаларны кулланып башкарыла.

2.3.1.4 нче таблица

Нарат ылыслары ботаклары массасы

| D=1.3 м, см | Бер агачтан нарат ылыслары ботаклары массасы, кг, биеклек разрядына карап | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ia | I | II | III | IV |
| 12 | 13 | 12 | 11 | 10 | 9 |
| 16 | 20 | 18 | 17 | 15 | 14 |
| 20 | 28 | 25 | 23 | 21 | 19 |
| 24 | 34 | 31 | 29 | 27 | 25 |
| 28 | 41 | 38 | 36 | 32 | 29 |
| 32 | 48 | 44 | 41 | 37 | 34 |
| 36 | 54 | 48 | 46 | 42 | 38 |
| 40 | 61 | 56 | 51 | 48 | 43 |
| 44 | 66 | 60 | 57 | 52 | 47 |
| 48 | 72 | 67 | 61 | 56 | 52 |
| 52 | 77 | 72 | 66 | 60 | 56 |
| 56 | 82 | 76 | 70 | 66 | 59 |

2.3.1.5 нче таблица

Чыршы ылыслары ботаклары массасы

| D=1.3 м, см | Бер агачтан чыршы ылыслары ботаклары массасы, кг, биеклек разрядына карап | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ia | I | II | III | IV |
| 8 | 10 | 9 | 8 | 7 | 7 |
| 12 | 21 | 18 | 16 | 15 | 13 |
| 16 | 38 | 31 | 44 | 24 | 20 |
| 20 | 63 | 53 | 29 | 37 | 31 |
| 24 | 86 | 72 | 60 | 50 | 42 |
| 28 | 125 | 104 | 80 | 67 | 56 |
| 32 | 150 | 126 | 105 | 88 | 67 |
| 36 | 195 | 163 | 125 | 104 | 87 |
| 40 | 229 | 192 | 146 | 123 | 103 |
| 44 | 269 | 224 | 172 | 144 | 110 |
| 48 | 289 | 239 | 200 | 167 | 128 |
| 52 | 331 | 276 | 232 | 177 | 148 |

Нарат түмәре сагызы дип өлгергән наратның түмәренең һәм тамырларының чәерле матдәләрен алу өчен чимал буларак кулланыла торган сәламәт өлеше атала. Агачларны кискәннән соң түмәрләр акрынлап чери башлый. Черү процессы иң беренче чиратта сагызы аз булган түмәр өлешенә тия. Сагызлы матдәләр агач материалына черүгә каршы тотрыклылык бирә. Башта түмәрнең тышкы ягы һәм вак тамырлары чери. Түмәрнең аз сагызлы өлеше черү процессы түмәр сагызы әзерләү өчен киләчәктә куллану җәһәтеннән түмәрнең өлгерү процессы була.

Түмәрнең өлгерүен карап беләләр. Тышкы ягы черегәч һәм төп өлешеннән җиңел аерыла башлагач, түмәр файдалану өчен өлгергән дип санала. Өлгергән түмәрләрне аралау һәм чистарту җиңел була. Түмәр өлгереп килгән вакытта ул сагызлы матдәләргә байый, сагызы азрак түмәрләр тизрәк череп бетә. 15 елдан соң түмәр сагыз әзерләү өчен өлгергән дип санала, бу вакытта урман бүлемтегендә барлык түмәрләрнең 70%ка якыны кала. Әгәр сагыз әзерләү урман кискәннән соң 25 елдан соң башкарылса, элеккеге урман бүлемтегендә түмәрләрнең башлангыч санынннан 40%ка якыны гына кала. Иң эре һәм сагыз матдәсе зур булганнары гына кала.

Агач кискәннән соң түмәрнең җирдә калу вакытына карап, яңаларга (5 елга кадәр), өлгереп килүчеләргә (5-10 ел) һәм өлгергәннәргә бүленә (10 елдан артык).

Нарат сагызы өлгерү процессы туфрак-климатик һәм урманчылык алып бару факторларына бәйле һәм, кагыйдә буларак, 10-15 елга кадәр сузыла. Көньяк районнарда тизрәк өлгерә, төньяк районнарда – акрынрак. Коры туфракларда дымлы туфракларга караганда акрынрак өлгерә.

Барысыннан да күбрәк вакыт төше шактый зур булган түмәрләр саклана, аларның саны киселгән агач характеристикасына бәйле.

Түмәр сагызы запасларын билгеләү. Түмәр сагызы әзерләү өчен түбәндәге чимал базасы була:

- яңа һәм коры туфракларда яңадан кисүләр булмаган наратлар;
- 13 яшькә кадәрге, I-IV бонитет класслы, ылыслыларда 0,3-0,7 тулылыгы булган һәм яфраклыларда 0,3-0,8 тулылылыгы булган ылыслы һәм яфраклы яшь үсентеләр, аерым якланучы кишәрлекләрдән гайре;
- нарат кисүләрендә 4-5 яшьлек үсеп китү мөмкинлеге 40-50% булган урман культуралары (ябалдашлары кушылмаган культуралар) һәм 6-12 яшьлек 0,4-0,6 тулылыгы булган, рәт аралары киңлеге 2,5 метрдан артык;
- I-IV бонитет класслы ревизион чордагы нарат урман бүлемтекләре.

1 гектарга әзерләргә рөхсәт ителә торган түмәрләр саны (данә) урман культуралары булуга һәм аларның торышына карап билгеләнә.

Әзерләнә торган түмәрләр саны:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | 0,5 метрга кадәр биеклектә: | 5 мең данә/га кадәр<br>5–8 мең данә/га | 0,5 метрга кадәр биеклектә: |
| 2. | 0,5-1,5 метрга кадәр биеклектә: | 3 мең данә/га кадәр<br>3–5 мең данә/га<br>5 мең данә/га дан артык | 0,5-1,5 метрга кадәр биеклектә: |
| 3. | 1,5 метрга кадәр биеклектә: | 5 мең данә/га кадәр<br>5 мең данә/га дан артык | 1,5 метрга кадәр биеклектә: |

Үзләре үсеп чыккан яфраклы яшь токымнарны кисү:

| | |
|---|---|
| 1 метрга кадәр биеклектә: | чикләүләрсез |
| 3метрдан да артыграк биеклектәге каенлыклар: | 100 |

Урманнарның коры дала типларының алда китерелгән категорияләрендәге урманнарга таксация уздыру барышында 20дән артык чыршысы булган наратлыкларны кисүнең күптән узган һәм 1 гектарга кимендә 50 түмәр булса, түмәр сагызын исәпкә алына. Бу чакта 1 гектарга түмәрләр саны, түмәрләрнең уртача диаметры һәм сагызлылыкның өлгерү классы (кисүләр вакыты) исәпкә алына. Түмәр сагызының өлгергәнлек класслары 2.3.1.6 нчы таблицада китерелә.

2.3.1.6 нчы таблица

Түмәр сагызының өлгергәнлек класслары

| Кисү вакыты, ел | Өлгергәнлек классы | Сагыз характеристикасы | Түмәрләрнең өлгергәнлек классының тышкы күренешләре |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1-5 | I | Яшь | Тышкы кайрысы череми һәм төше белән бербөтен |
| 6-10 | II | Өлгереп килүче | Тышкы кайрысы теге яисә бу дәрәҗәдә черегән, җирдән өстә өлешендә бераз көч куюга төшеннән аерыла, җирдән аста өлешендә – аерылмый |
| 11-15 | III | Өлгергән | Тышкы кайрысы шактый гына черегән һәм төштән бик җиңел аерыла |
| 16-20 | IV | Картайган | Тышкы кайрысы бөтенләй черегән, төше чери башлаган |

1 гектарга түмәрләр саны сынау мәйданчыкларында тоташ санау, ленталы санау яисә исәпкә алу адымнары юлы белән билгеләнә (21 түмәр арасындагы аралар буенча билгеләнә торган уртача ара буенча).

Түмәр сагызы ресурслары, түмәрләрнең саныннан һәм диаметрыннан чыгып, региональ норматив-белешмә таблицаларны исәпкә алып билгеләнә.

Нормаль юкә агачларында 1 гектардан мунчала чыгу 2.3.1.7 нче таблицада китерелә.

2.3.1.7 нче таблица

Нормаль юкә агачларында 1 гектардан мунчала чыгу

| Уртача диаметры, см | Агачның тулылыгы | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 0,3 | 0,4 | 0,5 | 0,6 | 0,7 | 0,8 | 0,9 | 1,0 |
| 16 | 53 | 58 | 62 | 64,6 | 65,4 | 66,4 | 67 | 67,5 |
| 18 | 48,8 | 51,2 | 54,8 | 57 | 57,8 | 58,6 | 59,2 | 59,6 |
| 20 | 42 | 45,9 | 49,1 | 51,2 | 51,3 | 52,6 | 53,4 | 53,5 |
| 22 | 38 | 41,6 | 44,5 | 45,3 | 46,9 | 47,6 | 48 | 48,4 |
| 24 | 34,9 | 38,2 | 40,9 | 42,6 | 43,1 | 43,8 | 44,2 | 44,5 |
| 26 | 31,8 | 34,8 | 37,2 | 38,9 | 39,3 | 39,9 | 40,3 | 40,6 |
| 28 | 29,4 | 32,2 | 34,4 | 35,9 | 36,3 | 36,9 | 37,2 | 37,5 |
| 30 | 27,1 | 29,7 | 31,7 | 33,1 | 33,5 | 34 | 34,3 | 34,6 |

Искәрмә. Мунчала запаслары кисә башланган үсентеләре өчен формула буенча билгеләнә: V=0,1KxMxL, анда V – мунчала чыгу; K – үсентеләрдә юкә составы коэффициенты; M – үсентеләр запасы; L –1 $м^3$ юкәгә мунчала чыгу (таблица күрсәткече).

Агач үсентеләренең күп кенә төрләренең кабыгы Имәниль сыйфатында күн производствосында кулланыла. Үсемлек рәвешендәге Имәниль матдәләр арасында тал кайрысы беренче урыннарның берсен алып тора. Тал кайрысы белән эшкәртелгән күн эластик, йомшак һәм югары механик сыйфатларга ия була.

Талның кайбер төрләре (ак, кәҗә, уалучан, әйлән-бәйлән, кызгылт) кайрысыннан йонны, ефәкне, лайка күнен, җитен һәм мамык җепләрен буяу өчен буяулар әзерлиләр, салицил һәм гликозид алалар. Талның яшь кайрысы капчык материалы, баулар, шпагат әзерләү өчен кулланыла.

Тал кайрысының Имәниль матдәләре – таннидлар – билгеле бер эрү ноктасы булмаган аморф (кристаллик булмаган) катышмалар. Таннидлар проценты югарырак булган саен, кайрының Имәниль чимал буларак сыйфаты арта.

Кайрыдагы таннидлар саны асылда талның төренә бәйле. Таннидлыкка тәэсир итүче факторлар – үсемлекнең яше, талда кайрының урнашкан җире, әзерләү сезоны, үсү урыны шартлары.

Агач рәвешендәгеләрдән иң кыйммәте булган таллар арасында кәҗә, уалучан, биек, саз һәм биш яфрак таллар санала, алар кайрысында таннидлар 8 дән алып 12%ка кадәр. Агач-куак рәвешендәгеләрдән таннидлар иң күп булганы – өчьяфрак, коры кайрылы, соры һәм йонлач таллар. Кайрысында 7%тан да азрак таннидлар булганнарга кайрысыз төркем кертелә.

Иске һәм бөкеләнгән кайрыда, бер еллык яшь ботаклардагы кайрылар кебек үк таннидлар бик аз була. Күп төрләр өчен таннидлар 4 елдан алып 15 елга кадәрге яшьтәге талларга хас. Кәүсәнең аскы өлешендәге кайрыда таннидлар өске өлешеннән күбрәк була.

Суты йөргәндә талда таннидлар кышкыга караганда шактый күп була, тал кайрысында Имәниль матдәләрнең иң күп күләме суты иң интенсив йөргән чакта – май башыннан алып июль уртасына кадәр була.

Таннидлар күләменә тал үсентеләренең кайда үсеп чыгулары да тәэсир итә. Уңдырышлырак туфраклар Имәниль матдәләр тупланугa китерә.

Каен тузы әзерләүне исәпкә алу һәм аның үзенчәлекләре. Каен тузы ике төрдә әзерләнә. Сутлы килеш – үсеп утыручы агачлардан һәм шкурка ярдәмендә (ышкып алу)– каенның аскы өлешеннән, утыннардан һәм аударылган агачлардан. Үсеп утыручы агачлардан каен тузы әзерләү, кисү башланырга 1-2 ел кала, урман бүлемтегендәге агачлардан рөхсәт ителә, моңа диаметры 12 см дан ким булган һәм фанер әзерләү өчен билгеләнгән мазсус сортлы агачлар керми.

Үсеп утыручы агачлардан каен тузы салдыру язгы чорда, агачның кайры астына һәм материалга китә торган өлешенә зыян китермичә генә, гомуми биклегенең яртысына кадәр башкарыла.

Аударылган агачлардан һәм корыган агачлардан шкурка ярдәмендә каен тузы әзерләү урман фондының бөтен территориясе буенча елы буена башкарылырга мөмкин.

Әзерләнгән каен тузы сыйфаты “Дегет җитештерү өчен каен тузы” ТУ 13-707-83га туры килергә тиеш. Каен тузының чыгышы, 1 $м^3$ кәүсә агач материалыннан 1 кг күләмендә 2.3.1.8 нче таблицада китерелә.

2.3.1.8 нче таблица

Каен тузы чыгышы, 1 $м^3$дан кәүсә агач материалыннан килограммнарда

| Сортиментлар исеме | Диаметры, см | Каен тузы чыгышы | |
|---|---|---|---|
| | | Яңа гына салдырылган килеш | Коры килеш |
| Эре | 26 һәм аннан да күбрәк | 6,3 | 3,8 |
| Уртача | 14-24 | 7,2 | 4,3 |
| Вак | 13 | 2,2 | 1,3 |
| Утын | 13 һәм аннан күбрәк | 2,2 | 1,3 |

Тал кайрысының чимал базасы елга үзәннәрендәге һәм дымлы урыннардагы куаклы үзәннәрнең, сазланган урманнардагы, ягъни дымы җиткән һәм уңдырышлы туфраклы урыннардагы табигый таллыклардан гыйбарәт.

Тал кайрысын әзерләү кайрысында Имәниль матдәләр 7%тан да ким булмаган талларда башкарыла (дымлылык 16%).

Агачсыман таллар: кәҗә талы – кайрының таннидлыгы 16%; уалучан, биш яфрак - 10%.

Куаклылар: соры, миндальсыман - кайрының таннидлыгы 17%; көлсыман, колаклы - 11; куе кызыл - 9.6; рус талы - 7-15; чыбыклы - 10; йонлач - 11; озын яфраклы, кара тал - 10.5; лапландия талы - 8-14; киң яфраклы - 11%. Түбән таннидлы таллар: ак тал һәм еламсар тал - кайрының таннидлыгы 6-7%.

Тал кайрысын әзерләү өчен 5 яшьтән олырак булган куак таллар, агачсыман таллар – 15 яшьтән олырак булган таллар ярый. Агач материалы запасы кимендә 5 $м^3$/га булган алда күрсәтелгән тал төрләре яраклы.

1 $м^3$ яңа киселгән агачтан тал кайрысы чыгышы – уртача 65 кг.

Тал кайрысы запасларын билгеләү, 1 гектарга тал агач материалы запасыннан чыгып, 2.3.1.9 нчы таблица нигезендә башкарыла.

2.3.1.9 нчы таблица

1 гектарга тал агач материалы запасыннан чыгып,
коры тал кайрысы массасы

| Запас күләменә карап, | Кайры массасы, саннар бүлекләре буенча тонналарда | | | | Запас күләменә карап, | Кайры массасы, саннар бүлекләре буенча тонналарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | меңнәр | йөзләр | меңнәр | йөзләр | | меңнәр | йөзләр | дистәләр | берәмлекләр |

| меңнәр, йөзләр, дистәләр һәм берәмлекләр саны, $м^3$ | Куаксыман таллар | | | | меңнәр, йөзләр, дистәләр һәм берәмлекләр саны, м3 | Агачсыман таллар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 70 | 7 | 0,7 | 0,1 | 1 | 60 | 6 | 0,6 | 0,1 |
| 2 | 140 | 14 | 1,4 | 0,1 | 2 | 119 | 12 | 1,2 | 0,1 |
| 3 | 210 | 21 | 2,1 | 0,2 | 3 | 178 | 18 | 1,8 | 0,2 |
| 4 | 280 | 28 | 2,8 | 0,3 | 4 | 238 | 24 | 2,4 | 0,2 |
| 5 | 350 | 35 | 3,5 | 0,4 | 5 | 298 | 30 | 3,0 | 0,3 |
| 6 | 420 | 42 | 4,2 | 0,4 | 6 | 357 | 36 | 3,6 | 0,4 |
| 7 | 490 | 49 | 4,9 | 0,5 | 7 | 416 | 42 | 4,2 | 0,4 |
| 8 | 560 | 56 | 5,6 | 0,6 | 8 | 476 | 48 | 4,8 | 0,5 |
| 9 | 630 | 63 | 6,3 | 0,6 | 9 | 536 | 54 | 5,4 | 0,5 |

Мисал: куаксыман талдагы агач материалы запасы 10 га урман бүлемтегендә – 175 $м^3$/га. Таблица нормативларыннан чыгып, коры кайры авырлыгы: 7+4,9+0,4=12,3 т/га; 12,3 т/га*10 га=123 т.

Чыршы кайрысын исәпкә алу.

Чыршы кайрысын Имәниль матдәләр алу өчен әзерләү өлгергән һәм картайган агачлы урман бүлемтегендә чыршыларны кискәндә сут йөргән чорда диаметры 20 см булган агачларда гамәлгә ашырыла. Имәниль матдә чыгышы 1 $м^3$ әзерләнгән чыршы агачы материалыннан уртача 40 кг тәшкил итә.

## 2.3.2. Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен урманнардан файдалану сроклары

Түмәр сагызын әзерләү теләсә нинди максатлар өчен билгеләнгән урманнарда рөхсәт ителә, мондый әзерләү урман үсентеләренә, шытып чыгучы һәм яшь үсентеләргә зыян китермәскә тиеш.

Түмәр сагызын әзерләү ысулы (кулдан, трактор ярдәмендә, шартлатып һәм башкалар) аренда шартнамәсендә билгеләнә.

Түмәр сагызын әзерләү эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары буйларындагы, тау һәм аермалар ярларындагы урманнарның яр яклау һәм туфрак яклау участокларында, шулай ук 0,8-1,0 тулышлы яшь үсентеләрдә рөхсәт ителми.

Каен тузы әзерләү кисү өчен бүлеп бирелгән үсеп утыручы агачлардан кисәргә 1-2 ел кала (фанер төбәнәге һәм махсус сортимент әзерләү өчен билгеләнгән агачлардан гайре), шулай ук сайлап алу һәм тоташ кисү уздырылган башка урман бүлемтекләрендәге яңа киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Үсеп утыручы агачлардан каен тузы әзерләү язгы-җәйге һәм көзге чорда төп кабыкка зыян китерелмичә башкарыла. Әзерләү өчен кулланыла торган кәүсәнең өлеше агачның гомуми биеклегенең яртысыннан артмаска тиеш.

Корыган һәм ауган агачлардан каен тузы әзерләү ел дәвамында башкарыла.

Каен тузы әзерләү өчен агачларны кисү тыела.

Кабык һәм кайры әзерләү ел дәвамында агачлар кискән вакытта башкарыла. Тал кайрысы язгы-җәйге чорда әзерләнә.

Тал кайрысы әзерләү өчен 5 яшьлек куак таллар, 15 яшьлек агач таллар яраклы.

Чыбык-чабык әзерләү. Юан очының диаметры 4 см булган нәзек агач кәүсәләре, шулай ук агачларның киселгән ботак очлары, ботаклары һәм чыбыклары була. Чыбык-чабык ике категориягә бүленә: 2-4 м һәм 4 мдан да артыграк.

Ботаклардан терлек азыгы әзерләү. Ботаклардан терлек азыгы дип 1,5 см га кадәр калынлыкта булган, кайбер яфраклы һәм ылыслы агачларның яшь ботакларыннан әзерләнгән һәм терлек азыгы буларак кулланыла торган урман материалы атала.

Ботаклардан терлек азыгы әзерләү өчен яфраклылар (каен, усак, чаган, чикләвек, юкә, тополь, корычагач һәм башкалар) һәм ылыслылар (асылда чыршы) токымнары ботаклары кулланыла. Ботаклардан терлек азыгы әзерләү өчен нигездә җәй көне яфраклыларның яшь ботаклары кулланыла, ылыслылар – кыш көннәре.

Ботаклардан терлек азыгы әзерләү сайлап алына торган һәм тоташ урман кисүләр барышында гамәлгә ашырыла.

Пихта, нарат, чыршы ботакларын әзерләү бары тик сайлап алып һәм тоташ урман кисүләр барышында урман бүлемтегендәге киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачлар әзерләү беренче чиратта махсус плантацияләрдә, чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда) рөхсәт ителә.

Чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачлар әзерләү агач материалы әзерләгәндә, шул исәптән киселгән чыршыларның очларыннан рөхсәт ителә.

Мүк, коелган яфраклар катламын, урмандагы аяк асты япмасын, камыш әзерләү төзелеш, шулай ук авыл хуҗалыгы терлекләре өчен азык һәм асларына салу материалы сыйфатында ярдәмче материал буларак һәм компост әзерләү өчен аларны куллану максатларында башкарыла. Аларны әзерләгәндә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерелмәскә тиеш.

Мүк әзерләү алымнары һәм нормалары аренда шартнамәсендә билгеләнә.

Бензопычкылар ярдәмендә мүк әзерләү бары тик Урманчылык хезмәткәрләре тикшереп торганда гына башкарыла.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю бер үк мәйданда биш елга бер мәртәбә генә рөхсәт ителә. Урмандагы аяк асты япмасын җыю өлешчә, бөтен катламын алмыйча гына гамәлгә ашырылырга тиеш.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю, бу елда коелачак яфраклар һәм ылыс, шулай ук япма табигый ашлама хасил итсен өчен, җәй азагында, әмма яфраклар

коела башлаганчы ук башкарылырга тиеш.

Табигатьне һәм башка объектларны яклау вазыйфасын башкаручы урмандагы аяк асты япмасын җыю тыела.

Урман кишәрлекләрендә агачларны әзерләү (казып алу) I класслы яшьтә булган ылыслы үсентеләрдә, I һәм II яшьтә булган яфраклы үсентеләрдә гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлекләренең өстәмә урманчыгында куакларны әзерләү (казып алу) уртача куелыктагы яисә бөтенләй куе булган урманчыкта яки әзерләнә торган токым бик күп булган өлештә башкарыла. Әзерләнә торган төрнең калган куаклары саны бер гектарга кимендә 1000 данә булырга тиеш.

Чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында, печән чабу урыннарында, электр үткәргеч линияләрдә, су баскан зоналарда, автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларда, торбаүткәргечләрдә һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда), шулай ук сайлап алып яисә тоташ урман кискәндә урман бүлемтекләрендә киселгән агачлардан яфраклы токымнардан (каен, усак, тал һ.б.) мунча себеркесе, себерке һәм кисәкләргә турау өчен ботаклар һәм куаклыклар әзерләнә.

Агач яшеллеген әзерләү. Агач яшеллегенә яфраклы һәм ылыслы токымнарның яфраклары, бөреләре, ылыслары һәм нигезендә диаметры 8 мм га кадәр булган яңа чыккан ботаклары керә.

Ылыслы витамин оны җитештерү өчен агач яшеллеген әзерләү бары тик сайлап алып яисә тоташ урман кискәндә генә урман бүлемтекләрендә киселгән агачлардан гына рөхсәт ителә.

Пихта мае җитештерү өчен агач яшеллеген (пихта ботакларын) әзерләү өлгергән пихта үсентеләрендә язгы-җәйге чорда диаметры кимендә 18 см булган үсеп утыручы агачлардан тере ябалдашының бары тик 30%ы озынлыгында гына үткен корал белән кисеп алу юлы белән кулдан әзерләү рөхсәт ителә. Бу чакта ботаклар кыеклап яисә тип-тигез итеп, тирәсен мунчалалатмыйча гына киселергә, ботакларның агачта калдырылган өлешенең озынлыгы кимендә 30 см булырга тиеш.

Пихта ботакларын бер үк урман үсентеләрендә әзерләү 4-5 елдан соң гына рөхсәт ителә.

Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю тәртибе.

Нарат, чыршы һәм пихта ботакларын әзерләү, бары тик урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар (урманнардан файдаланучылар) белән килештереп кенә, урман үсентеләрен кисү урыннарында киселгән агачлардан гына рөхсәт ителә.

Тал кайрысы киселгән агачлардан, бары тик урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар белән килештереп кенә, язгы-җәйге чорда әзерләнә. Үсеп утырган агачлардан кайры каезлау тыела.

Каен тузы әзерләү корыган һәм ауган агачлардан ел дәвамында башкарыла. Үсеп утырган каеннардан каен тузы әзерләү бары тик агымдагы елда киселергә

тиешле агачлардан бары тик урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар белән килештереп кенә башкарыла.

Мунча себеркесе, себерке һәм кисәкләргә турау өчен, шулай ук терлек азыгына ботаклар һәм куаклыклар әзерләү чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда), шулай ук янгынга каршы, урман хуҗалыгы һәм урман әзерләү билгеләнгән ведомство юлларының бүлеп бирелгән полосасында, урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар белән килештереп, урман хуҗалыгы чараларын гамәлгә ашырганда киселгән агачлардан башкарыла.

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачлар әзерләү чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда) башкарыла. Әзерләү урыннары вәкаләтле орган белән язма рәвештә килештерелә.

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачлар әзерләү агач кискәндә, шул исәптән эшкәртелә торган урман бүлемтегендә, урман үсентеләрен кисү белән шөгыльләнүче затлар белән килештереп, киселгән агачларның очларыннан рөхсәт ителә.

Мүк, урмандагы аяк асты япмасын җыю, бу елда коелачак яфраклар һәм ылыс шулай ук япма хасил итсен өчен, җәй азагында, әмма яфраклар коела башлаганчы ук, бер үк мәйданда җыйганда вәкаләтле орган белән килештерү буенча биш елга бер мәртәбә рөхсәт ителә. Урмандагы аяк асты япмасын җыю өлешчә, бөтен катламын алмыйча гына гамәлгә ашырылырга тиеш.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю бу елда коелачак яфраклар һәм ылыс, шулай ук япма табигый ашлама хасил итсен өчен, җәй азагында, әмма яфраклар коела башлаганчы ук башкарылырга тиеш.

Үз ихтыяҗларың өчен агач булмаган урман ресурсларының аерым төрләрен әзерләгәндә һәм җыйганда урман кишәрлекләрен файдалануга карата “Татарстан Республикасы урманнарыннан файдалану турында” 22.05.2008 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән таләпләр:

Каен тузы әзерләү кисү өчен бүлеп бирелгән үсеп утыручы агачлардан кисәргә 1-2 ел кала (фанер төбәнәге һәм махсус сортимент әзерләү өчен билгеләнгән агачлардан гайре), шулай ук сайлап алу һәм тоташ кисү уздырылганда урман бүлемтекләрендәге яңа киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Үсеп утыручы агачлардан каен тузы әзерләү язгы-җәйге һәм көзге чорда төп кабыкка зыян китерелмичә башкарыла. Әзерләү өчен кулланыла торган кәүсәнең өлеше агачның гомуми биеклегенең яртысыннан артмаска тиеш.

Корыган һәм ауган агачлардан каен тузы әзерләү ел дәвамында башкарыла.

Каен тузы әзерләү өчен агачларны кисү тыела.

Кабык һәм кайры әзерләү ел дәвамында агачлар кискән вакытта башкарыла. Тал кайрысы язгы-җәйге чорда әзерләнә.

Тал кайрысы әзерләү өчен 5 яшьлек куак таллар, 15 яшьлек агач таллар яраклы.

Чыбык-чабык әзерләү агач материалы әзерләү һәм урманнарны карау кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

Ел дәвамында ботаклардан терлек азыгы әзерләү өчен агач-куак токымнары кулланыла.

Ботаклардан терлек азыгы әзерләү сайлап алына торган һәм тоташ урман кисүләр барышында гамәлгә ашырыла.

Пихта, нарат, чыршы ботакларын әзерләү бары тик сайлап алына торган һәм тоташ урман кисүләр барышында урман бүлемтегендәге киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

## 2.4. Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 34, 35 статьялары, Азык-төлек урман ресурсларын әзерләүнең һәм дару үләннәре җыюның Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 05.12.2011 №511 боерыгы, “Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы ТР Законы (22.12.2012 ред.) белән регламентлана.

Азык-төлек урман ресурсларына кыргый үсүче җимешләр, җиләкләр, чикләвекләр, гөмбәләр, орлыклар, каен суты һәм башка урман ресурслары керә.

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында – гражданнар, юридик затлар тарафыннан, үз ихтыяҗлары өчен гражданнар тарафыннан башкарылырга мөмкин.

Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе 10 елдан алып 49 ел срокка төзелергә мөмкин.

Үз ихтыяҗлары өчен азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю ирекле һәм түләүсез башкарыла.

Чикләрендә азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен урманнардан файдалану рөхсәт ителгән кварталлар исемлеге 1.2 нче таблицада китерелә.

Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, “Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында” 08.01.1998 № 3-ФЗ Федераль закон нигезендә наркотик чаралар дип танылган, шулай ук агач материалы әзерләү рөхсәт ителми торган агачлар һәм куаклар төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгән кыргый үсүче үләннәрне һәм гөмбәләрне әзерләү һәм җыю тыела. Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм

дару үләннәре җыю өчен урман кишәрлекләрен арендалаучы гражданнар һәм юридик затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

- урманнардан файдалануны аредна шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырырга;
- кирәк чакта урман инфраструктурасы булдырырга (урман юллары, урман складлары һ.б.);
- бирелгән урман кишәрлекләрендә киптерү, гөмбә пешерү җайланмалары складлар һәм башка вакытлы корылмалар урнаштырырга;
- гамәлгә ашыруы Россия Федерациясе урман законнарына каршы килмәсә, башка хокукларга ия булырга.

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен урман кишәрлекләрен арендалый торган гражданнар һәм юридик затларның бурычлары түбәндәгеләр:

- урманнарны үзләштерү проектын төзергә;
- урманнарны үзләштерү проекты һәм әлеге урман регламенты нигезендә урманнардан файдаланырга;
- урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын үтәргә;
- гражданнар сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүне булдырмаска;
- туфрак эрозиясе булдырмаучы, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, шулай ук су объектларына һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтыны булдырмаучы яисә чикләүче алымнар белән урманнардан файдаланырга;
- урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен, шулай ук урманнарны карау кагыйдәләрен үтәргә;
- урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен тәэмин итү максатларында санитар-савыктыру чаралары күрергә (черегән һәм зарарланган урман үсентеләрен кисәргә, урманнарны чүп-чардан, пычранудан һәм бүтән тискәре йогынтыдан арындырырга);
- ел саен урман декларациясен тапшырырга, шулай ук квартал саен билгеләнгән тәртиптә хисаплар тапшырырга;
- Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән бурычларны үтәргә.

### 2.4.1. Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен аларның төрләре буенча әзерләү һәм җыю нормативлары (еллык мөмкин күләмнәре) һәм параметрлары

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләгәндә һәм дару үләннәре җыйганда урманнардан рөхсәтле файдалануның еллык мөмкин күләмнәре 2.4.1 нче таблицада китерелә.

2.4.1 нче таблица

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләгәндә һәм дару үләннәрен җыйганда урманнардан файдалану параметрлары

| № т/с | Азык-төлек урман ресурсларының һәм дару үләннәрененең төре | Үлчәү берәмлеге | Еллык мөмкин булган әзерләү күләме |
|---|---|---|---|
| Азык-төлек ресурслары | | | |
| 1. | Җиләкләр: нарат җиләге | т | - |
| | мүк җиләге | т | - |
| | күк җиләк | т | - |
| | кура җиләк | т | 2,9 |
| | каен җиләге | т | - |
| | кара җиләк | т | |
| | кызыл бөрлегән | т | - |
| | миләш, шомырт | т | 1,9 |
| | Барлыгы | т | 4,8 |
| 2. | Гөмбәләр: ак гөмбә | т | |
| | майлы гөмбә | т | |
| | ал гөмбә | т | |
| | усак гөмбәсе | т | |
| | каен гөмбәсе | т | |
| | гөрездә | т | |
| | әтәч гөмбәсе | т | |
| | баллы гөмбә | т | |
| | Барлыгы | т | 100,3 |
| 3. | Агач суты: каен | т | 150,4 |
| Дару чималы | | | |
| 4. | Сары мәтрүшкә, таплы яфрак ике оялы, ландыш, сукыр кычыткан, дару ромашкасы, меңьяфрак, тигәнәк, канлы үлән, валериана, гөлбадран, җәенке яфрак, үги ана яфрагы, наратбаш һәм башкалар | кг | 0,5 (коры килеш) |

Җиләкләрнең, гөмбәләрнең һәм дару үләннәре уңышының 60%ы җирле халык тарафыннан үзләштерелә.

## 2.4.2. Әзерләү һәм җыю сроклары.

Кыргый үсүче җимешләр һәм җиләкләр әзерләү катгый рәвештә билгеләнгән срокларда башкарыла. Кыргый үсүче җимешләр һәм җиләкләр әзерләү сроклары уңышның массакүләм өлгерү вакытына бәйле.

Җимешләрне әзерләү өчен җимеш бирүче ботакларны кисү тыела.

Чикләвекләр әзерләү. Чикләвекләр әзерләү алымнары аренда шартнамәсендә күрсәтелә. Чикләвекләр әзерләү өчен урман кишәрлекләре арендага бирелгән затлар чикләвек агачларының һәм куакларының сакланышын тәэмин итәләр.

Чикләвекләр әзерләгәндә чикләвек агачларын һәм куакларын кисү, шулай ук чикләвек агачларын һәм куакларын зарарлауга китерә торган алымнар куллану тыела.

Гөмбәләр әзерләү аларның ресурслары сакланышын тәэмин итә торган алымнар белән башкарылырга тиеш.

Гөмбәләрне тамыры белән йолкып алу, гөмбә җыйганда мүкне һәм урмандагы аяк асты япмасын әйләндереп салу, шулай ук карт гөмбәләрне юк итеп бару тыела.

Иң киң таралган гөмбә төрләре, аларны җыю вакыты һәм урыннары 2.4.2.1 нче таблицада китерелә.

2.4.2.1 нче таблица

Иң киң таралган гөмбә төрләре, аларны җыю вакыты һәм урыннары

| Гөмбәләр исемнәре | Җыю вакыты | Җыю урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Язгы гөмбә | Апрель–май | Барлык урманнарда, күбрәк яфраклы урманнарда |
| Кәҗә гөмбәсе | Апрель–май | Каен булган бөтен урында үсә |
| Ак гөмбә | Июнь–сентябрь | Яшь усаклыкларда һәм усак катыш катнаш урманнарда |
| Нарат гөмбәсе | Август–сентябрь | Наратлыкларда һәм кечкенә яшь наратлыкларда (культураларда) |
| Ал гөмбә | Июнь–октябрь | Нарат урманнарында зәгыйфь торфлы-комлы туфракларда |
| Каен гөмбәсе | Июнь–октябрь | Ылыслы һәм яфраклы токымнарның, аеруча зирекнең түмәрләрендә |
| Усак гөмбәсе | Июль–сентябрь | Каен, ылыслы һәм катнаш урманнарның дымлы урыннарында |
| Майлы гөмбә | Июнь–октябрь | Барлык урманнарда |
| Моховик | Июнь–сентябрь | Юкә һәм чикләвек урманчыгы булган яфраклы һәм катнаш урманнарда |
| Баллы гөмбә | Август–октябрь | Ылыслы һәм яфраклы урманнар авызларында, юл кырыйларында, паркларда |
| Әтәч гөмбәсе | Июнь–сентябрь | Катнаш һәм каен урманнарында |
| Валуй | Июль–октябрь | Нарат урманнарының дымлы урыннарында |
| Гөрездә | Июль–октябрь | Яшелчә, җиләк-җимеш бакчаларында, паркларда, болыннарда, көтүлекләрдә, чүплекләрдә |
| Дуңгыз-гөмбә | Июнь-октябрь | Барлык урманнарда, күбрәк яфраклы урманнарда |
| Йөнтәс гөмбә | Июль–октябрь | Каен булган бөтен урында үсә |
| Ачы гөмбә | Май–октябрь | Яшь усаклыкларда һәм усак катыш катнаш урманнарда |
| Шампиньон | Июль–сентябрь | Наратлыкларда һәм кечкенә яшь наратлыкларда (культураларда) |

Дару үләннәрен әзерләү үсемлекләрнең һәм чимал запасының үз вактында торгызылуын тәэмин итәрлек күләмнәрдә рөхсәт ителә.

Бер үк аланда дару үләннәре чималын кабат җыю бары тик шушы төрнең чималы тулысынча торгызылганнан соң гына рөхсәт ителә.

Дару үләннәрененең кайсы да булса төре өчен кабат әзерләү сроклары турында белешмә булмаганда түбәндәгеләргә таяну тәкъдим ителә:

- берьеллык үләннәрнең чәчәк өлешләрен, җир өсте органнарын әзерләү бер үк аланда 2 елга бер мәртәбә уздырыла;

- берьеллык үләннәрнең җир өсте органнарын әзерләү – 4-6 елга бер мәртәбә;

- дару үләннәрененең күп кенә төрләренең җир асты органнарын – 15-20 елга бер мәртәбәдән дә еш түгел.

Төп дару үләннәре, аларны әзерләү урыннары һәм вакыты 2.4.2.2 нче таблицада китерелә.

2.4.2.2 нче таблица

Төп дару үләннәре

| Үләннәрнең исеме | Әзерләнүче өлеше | Әзерләү вакыты, ае | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| Сазанак | Өске яшь ботаклары, яфраклары һәм җимешләре белән бергә | Август-сентябрь | Нарат үсентеләре каплаган дымлы һәм юеш урыннарда |
| Еламсар каен | Бөреләре | Март-Апрель | Үсентеләр |
| Ком меңьяфрагы | Чәчәкләре | Июль-август | Болыннар кырыйлары, калку урыннар, ярлар, коры лишайниклар һәм ак мүклекләр һәм коры наратлыклар |
| Җете кызыл дүләнә | Чәчәкләре һәм җимешләре | Май, август-сентябрь | Үсентеләр |
| Нарат җиләге | Яфраклары | Апрель-май | Нарат җиләге наратлыклары |
| Дарулык песи үләне | Тамырлары | Апрель, сентябрь-октябрь | Нарат җиләге аланнары |
| Өчьяфрак | Яфраклары | Май-август | Урман авызлары, болыннар, печәнлекләр, түбән урыннар, дымлы урыннар |
| Елан үләне | Тамырлары | Май-сентябрь | Урман авызлары, болыннар, печәнлекләр, түбән урыннар, дымлы урыннар |
| Борычлы тау үләне | Җир өсте өлеше | Июль-сентябрь | Юеш һәм дымлы каен үсентеләре, түбәнлектәге сазлык, сазланган печәнлекләр |
| Язгы утчәчәк | Җир өсте өлеше | Май-сентябрь | Дымлы сирәкләнгән үсентеләр, үзәннәрдәге болыннар |
| Биек сары чәчәк | Тамырлары | Май, | Дымлы урман авызлары, үзәннәр, |

| Үләннәрнең исеме | Әзерләнүче өлеше | Әзерләү вакыты, ае | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| | | сентябрь | аланнар |
| Дарулык кандала үләне | Чәчәк ату фазасында үләннең өске өлеше | Июнь-июль | Коры болыннар, көтүлекләр, ярлар |
| Имән | Кабыгы | Апрель-июль | Үсентеләр |
| Дарулык сыбызгы үлән | Чәчәк атмаучы нөсхәләрнең тамырлары | Апрель, сентябрь-октябрь | Үзәннәр, елга буйларындагы үсентеләр |
| Гади мәтрүшкә | Үләне | Июль-август | Ачыклыклар, печәнлекләр, яфраклы урманнар |
| Эт шомырты | Җимешләре | Август-сентябрь | Ачыклыклар, печәнлекләр, яфраклы урманнар |
| Тишек яфраклы сары мәтрүшкә | Үләне | Июль-август | Ачыклыклар, печәнлекләр. Үзәннәрдәге урманнар һәм болыннар |
| Алтынбаш | Үләне | Июль-август | Ачыклыклар, печәнлекләр. Үзәннәрдәге урманнар һәм болыннар |
| Балан гади | Кабыгы, Җимешләре | Август-сентябрь | Үзәннәр, урман авызлары |
| Таплы яфрак | Яфраклары | Май-сентябрь | Үзәннәр, шәрә җирләр, дымлы һәм юеш урыннарда сирәкләнгән урманнар |
| Дарулык кан үләне | Тамырлары кабыгы белән | Август-сентябрь | Үзәннәрдәге сирәкләнгән урманнар, болыннар |
| Зирексыман эт шомырты | Кабыгы | Март-май | Елга буйларындагы һәм ярлардагы яфраклы урманнар |
| Сары эт шомырты | Тамырлары | Май-октябрь | Сулыклар |
| Ландыш | Үләне чәчәк ату фазасында | Май-июнь | Яфраклы һәм катнаш урманнар |
| Калган | Тамырлары | Апрель, сентябрь-октябрь | Яфраклы урманнар, ачыклыклар |
| Вак яфраклы юкә | Чәчәкләре | Июнь-июль | Үсентеләр |
| Үги ана яфрагы | Яфраклары | Май-июль | Сазланган печәнлекләр |
| Гади кура җиләге | Җимешләре | Июль-август | Киселгән урыннар, сирәкләнгән үсентеләр |
| Гади артыш | Күркә-җиләкләре | Сентябрь-октябрь | Нарат үсентеләренең урманчыкларында |
| Дару тузганагы | Тамырлары | Май-октябрь | Печәнлекләр, көтүлекләр, шәрә урыннар, ачыклыклар |
| Соры зирек | Җимешләре | Август-октябрь | Елга буйларындагы үсентеләр |
| Гади гөлбадран | Чәчәкләре | Июль-сентябрь | Сирәкләнгән үләнсыман наратлыклар, ачыклыклар, болыннар |
| Зур көтүче яфрагы | Яфраклары | Июль-сентябрь | Юл буйлары, аланнар, болыннар |
| Әче әрем | Чәчәк атучы өске | Июнь- | Тик яткан урыннар, юллар, шәрә |

| Үләннәрнең исеме | Әзерләнүче өлеше | Әзерләү вакыты, ае | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| | өлеше, яфраклары | август | урыннар |
| Сукыр кычыткан | Үләне | Июнь-август | Юл буйлары, ярлар, шәрә урыннар |
| Гади миләш | Җимешләре | Сентябрь-октябрь | Яфраклы һәм катнаш урманнар |
| Кара карлыган | Җимешләре, яфраклары | Май-август | Елгалар үзәннәре |
| Гади нарат | Бөреләре, ылыслары | Май-октябрь | Ылыслы урман бүлемтекләре |
| Коры үлән | Үләне | Июнь-август | Аланнар, ачыклыклар, сазланган болыннар |
| Гади әнис | Җимешләре | Июль-август | Болыннар, елга үзәннәре |
| Гади турак уты | Яфраклары | Май-сентябрь | Коры наратлыклар |
| Гади меңьяфрак | Җир өсте өлеше (үләне) | Май-август | Киселгән урыннар, аланнар, ачыклыклар, печәнлекләр |
| Өч чәчәкле миләүшә | Җир өсте өлеше (үләне) | Май-август | Урман авызлары, аланнар, урман юллары |
| Кыр наратбашы | Үләне | Май-сентябрь | Үзәннәр, урман авызлары |
| Чага (каен гөмбәсе) | Өстенә үскән өлешләре | Гыйнвар-декабрь | Каен үсентеләре |
| Лобель аксыргагы | Тамырлары | Май-сентябрь | Үзәннәр, түбәнлекләрдәге көтүлекләр һәм печәнлекләр |
| Өч өлешле эт тигәнәге | Үләне | Май-сентябрь | Елагаларның дымлы ярлары, печәнлекләр |
| Гади шомырт | Җимешләре | Июль-сентябрь | Елгалар үзәннәре |
| Зур канлы үлән | Үләне | Май-август | Урман бүлемтекләре, чүп үләннәре үскән урыннар |
| Гөлҗимеш | Җимешләре | Август-сентябрь | Сирәкләнгән урманнар, аланнар, киселгән урыннар |

## 2.4.3. Агач сутлары әзерләү

Каен суты әзерләү кисәргә 5 ел кала өлгергән урман кишәрлекләрендә рөхсәт ителә.

Каен суты әзерләү кисү өчен әзерләнгән агач үсентеләренә кисеп җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Кисеп җибәрү өчен тулылыгы 0,4 һәм бер гектарга кимендә 200 данә агачы булган, I-III класслы бонитетлы урманның сәламәт өлеше сайлап алына. Кисеп җибәргәндә күкрәк биеклегедә килеш агачның диаметры 20 см һәм аннан да күбрәк булырга тиеш.

Каналлар бораулауны агач тамыры башланган җиреннән 20-35 см биеклектә башкаралар. Агачта бер һәм аннан да күбрәк кисеп җибәрү ясалганда, сут бер

кабул итү савытына агып төшәрлек итеп, алар кәүсәнең бер ягында 8-15 см аралыкта булырга тиеш.

Агач диаметрына карап, бораулана торган каналлар саны нормативлары 2.4.3 нче таблицада китерелә.

2.4.3 нче таблица

Агач диаметрына карап, бораулана торган
каналлар саны нормативлары

| Күкрәк биеклегендә агач диаметры, см | Кисеп җибәргәндә каналлар саны | Искәрмә |
|---|---|---|
| 20-22 | 1 | Түбәндәге йөкләнеш нормасы булганда 16 см диаметрлы агачларны кисеп җибәрү кисәргә бер ел кала рөхсәт ителә:<br>16-20 см – 1 канал<br>21-24 см – 2 канал<br>25 см һәм аннан да күбрәк – 3 канал |
| 23-27 | 2 | |
| 28-32 | 3 | |
| 33 һәм аннан да күбрәк | 3 | |

Кисеп җибәрү сезоны тәмамланганнан соң авыруларны булдырмый калу максатларында, тишекләр сагыз пастасы белән сылап куелырга яисә агач бөке белән ябылырга һәм вар, бакча замазкасы яисә известьлы балчык белән сылап куелырга тиеш.

Калган елларда каналлар беренче елгы кисеп җибәрү каналлары дәрәҗәсендә 10 см интервал белән агач кәүсәсе әйләнесенең теге яисә бу ягына таба бораулана.

Әзерләү агач материалының техник сыйфатларын саклап калырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.

## 2.4.4. Урман абагасы әзерләү

Урман абагасының яшь ботакларын әзерләү аларның үсентеләренә зыян китермәслек алымнар белән гамәлгә ашырылырга тиеш. Урман абагасын тамыры белән йолкып алу, яфракларына һәм тамыр үзәгенә зыян китерү тыела.

Урман абагасының очында өчтән артмаган ачылмаган яфраклы, зарар китерелмәгән яшь ботагы ашарга яраклы дип санала.

Җыярга яраклы яшь ботакларының оптималь биеклеге – әзерләү районына һәм үсү шартларына карап, 20-25 см дан 30-40 см га кадәр.

Урман абагасы чималын әзерләү бер үк кишәрлектә 3-4 ел буена алып барыла. Анары үсентеләр торгызылсын өчен тәнәфес ясарга кирәк: чималны бер мәртәбә җыйганда (сезонга) – 2-3 ел, ике мәртәбә – 3-4 ел.

## 2.4.5. Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен урманнардан файдалану сроклары

Дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе урманнардан азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен файдалану максатларында Россия Федерациясе Урман кодексының 72 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә.

## 2.5. Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

### 2.5.1. Биотехник чаралар уздыру исемлеге һәм аларның нормалары

Биотехник чараларның еллык күләмнәре 2.5.1.1 нче таблицада китерелә.

2.5.1.1 нче таблица

Аучылык хуҗалыгы алып барганда урманнардан файдалану параметрлары

| № т/с | Чаралар төрләре | Үлчәү берәмлеге | Еллык мөмкин күләм |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Хайваннарны шату мәйданчыклары кору | данә | 50 |
| 2. | Пошилар өчен тозлыклар кору | данә | 20 |
| 3. | Куяннар өчен тозлыклар кору | данә/кг | 30/900 |
| 4. | Подрубка осины, ивы | Кбм | 50 |
| 5. | Аучылар вышкаларын кору | данә | - |
| 6. | Ашату өчен печән әзерләү | тонна | 15 |
| 7. | Вак таш урыннары булдыру | данә | 50 |
| 8. | Кошлар өчен урыннар булдыру | данә | 50 |
| 9. | Кабан дуңгызлары өчен ашату басулары булдыру | га | 5 |
| 10. | Аучылыкны чикли һәм тыя торган аншлаглар, күрсәткечләр урнаштыру | данә | 20 |

Урманчы 2.5.1.1 нче таблицада күрсәтелгән чараларны үтәү өчен башкаручылар билгели.

Урман хуҗалыгы һәм урманнардан файдалану чараларын проектлаганда саклау максатлары өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр карала:

- махсус яклану кишәрлекләрен аеру өчен урман тавыгы гөлдерәү урыннарын, сулыкларны, кондызлар күп яши торган урыннарны карталаштыру;
- көртлек һәм урман тавыгы гөлдерәү урыннарында урман культуралары җитештерүдән баш тарту;

- җәнлекләр оя кора торган урыннарда һәм җәйге чорда яшь кыргый хайваннар туплану урыннарында эшләрне чикләү;

- агулы химикатлар һәм минераль ашламалар куллануны чикләү;

- кисүләрдән соң усак һәм башка токымнар шытып чыккан урыннарда 5-10 ел урман культуралары җитештерүдән баш тарту.

### 2.5.2. Аучылык инфраструктурасы урнаштыру өчен рөхсәт ителгән объектлар исемлеге

Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән урман кишәрлегендә (алга таба – урман кишәрлеге) аучылык инфраструктурасы объектлары булдыру чараларын күрергә, шул исәптән:

а) законнар таләпләре нигезендә аучылык базасы, аучы йорты, егерьләр кордоннары һәм башка туктап тору пунктлары булдырырга;

б) көймәләр пристаньнары корырга;

в) кыргый хайваннар өчен питомниклар, кинологик корылмалар һәм аучы токымнары этләре өчен питомниклар, ату вышкалары, тирлар, терлек азыгы саклау урыннары, өстәмә ашату корылмалары, печән чапкан урыннар, урман юллары, башка вакытлы корылмалар, төзелмәләр һәм аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен төзекләндерү объектлары булдырырга;

г) законнар таләпләре нигезендә урман юллары һәм аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка линия объектлары булдырырга, аларны ремонтларга һәм реконструкцияләргә, транспорт чаралары туктап тору урыннарын билгеләргә һәм корырга;

2) агач-ботаклардан терлек азыгы (кайры, нәзек ботаклар, яшь ботаклар, кыйммәте аз булган агач һәм куак токымнары яфраклары) һәм аучылык ресурсларына кертелгән җәнлекләргә һәм кошларга ашату өчен печән әзерләргә;

3) гамәлгә ашыруы урман законнарына, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге законнарга һәм (яисә) урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларына һәм аучылык хуҗалыгы килешүләренә каршы килмәсә, бүтән хокуклардан файдаланырга.

Кыргый хайваннар өчен питомниклар, кинологик корылмалар һәм аучы токымнары этләре өчен питомниклар, ату вышкалары, тирлар, терлек азыгы саклау урыннары кору – урман аланнарында, урман авызларында, янгыннан соң калган урман утыртылмаган урыннарда, буш урыннарда һәм агачлар һәм куаклар үсми торган урыннарда, ә өстәмә ашату урыннары асылда, түмәрләрне, җил аударган агачларны һәм урман туфрагын кулланып, гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Вакытлы корылмалар урман кишәрлеген файдалану срогыннан артмаган срокка урман үсентеләре булмаган яисә агачларның һәм куакларның кыйммәте аз булган токымнары үсә торган урыннарда корылырга мөмкин һәм, объектның төрен һәм аның хуҗасының атамасын күрсәтеп, аншлаглар белән билгеләнергә тиеш.

## 2.6. Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану алар урнашкан җирләрнең билгеләнешенә бәйле рәвештә, урман фонды җирләрендә ул урман хуҗалыгы мәнфәгатьләре туры килгәндә генә рөхсәт ителә һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 38 статьясы белән җайга салына, монда авыл хуҗалыгы җитештерүе дип авыл хуҗалыгы продукциясен, чималын һәм азык-төлек үстерү генә түгел, аны җитештерү, эшкәртү буенча икътисадый эшчәнлек төрләре җыелмасы да санала. (“Авыл хуҗалыгын үстерү турында” Федераль закон, 29.12.2006 № 264-ФЗ, 4 статья.).

Авыл хуҗалыгы җитештерүенә гадәттә авыл хуҗалыгы чималын беренчел эшкәртү генә кертелә. Сәнәгать эшкәртүе авыл хуҗалыгы җитештерүе дип саналмый.

Шул максатта Россия Федерациясе Урман кодексының 38 статьясындагы 2 өлеше белән авыл хуҗалыгы алып бару өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә бары тик вакытлы корылмалар (умарталыклар, киртәләр, өскормалар һәм башкалар) төзү генә рөхсәт ителә.

Әлеге норма авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану кысаларында авыл хуҗалыгы продукциясен сәнәгать эшкәртүен гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми, еш кына хәтта беренчел эшкәртергә дә.

Капиталь төзелеш объектларын төзергә кирәк булганда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә урманнардан авыл хуҗалыгы максатлары өчен файдалану гына түгел, урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану да таләп ителә (РФ УК 46 ст.).

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдаланганда алынган продукция бер үк вакытта урман ресурсы булып та саналырга мөмкин.

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану урманчылык территориясендә түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

- гражданнар, шул исәптән әйдәүче крестьян (фермер) хуҗалыклары, бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче шәхси ярдәмче хуҗалыклар;
- хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләр, җитештерү кооперативлары, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, бүтән коммерциячел оешмалар;
- коммерциячел булмаган оешмалар, шул исәптән кулланучылар кооперативлары, дини оешмалар.

Гражданнар, юридик затлар авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалануны урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре нигезендә гамәлгә ашыралар. Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре “Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 05.12.2011 № 509 боерыгы белән билгеләнә.

Әдеге Кагыйдәләрдә авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалануның теләсә кайсы төренә кагыла торган гомуми нигезләмәләр һәм

урманнарда алып барыла торган авыл хуҗалыгы эшчәнлегенең аерым төрләрен билгеләүче махсус таләпләр бар.

Авыл хуҗалыгы алып бару урман парклары зоналарында, тыюлык урман кишәрлекләрендә тыела.

Авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабудан һәм умартачылык белән шөгыльләнүдән гайре, махсус яклanучы урман кишәрлекләрендә тыела.

### 2.6.1. Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану параметрлары

| № т/с | Файдалану төрләре | Үлчәү берәмлеге | Еллык мөмкин күләм |
|---|---|---|---|
| 1 | Сөрүлекләр | га | 44 |
| 2 | Печән чабу | га/тонна | 217/152 |
| 3 | Көтүлекләр | | |
| | а) урманда | баш/га | 25,3/38,0 |
| | н) көтүлекләрдә | баш/га | 181/136 |
| 4 | Умартачылык | | |
| | а) бал бирүче: | | |
| | - юкә | га | 1157 |
| | -үләннәр | га | 1282 |
| | б) бал продуктлылыгы, шул исәптән: | | |
| | - юкә | кг/га | 131 |
| | - | кг/га | 20 |
| | в) бал кортлары оялары санын тоту мөмкинлеге | саны | 3547 |

### 2.6.2. Авыл хуҗалыгы җирләре, печән чабу мөмкин булган җирләр, авыл хуҗалыгы терлекләре көтүлекләре җирләре, умартачылык җирләре мәйданнары турында белешмәләр

#### Печән чабу

Печәнлекләрне классификацияләгәндә түбәндәгеләр билгеләнә: печәнлекләрнең тибы (су баса торган, коры җирдәге, сазланган), табигыймы ул яисә яхшыртылганмы, агач-куаклар басып китү дәрәҗәсе, печән әзерләүне кыенлаштыра торган факторлар, үләннең төп төрләре, аның каплап кителеш дәрәҗәсе, куелыгы, уңышы, сыйфаты. Печәнлекләр мәйданының 20%ын агач-куаклар басып алган булса, ул агач-куак басып киткән дип санала, 20%тан артыгын түмгәкләр каплаган булса – түмгәкле дип, яхшыртылган печәнлекләр дип – табигый һәм чәчелгән үләннәр каплап алган булса, анда механика кертеп була.

Печән уңышын бәяләү: 10 ц/га һәм аннан да күбрәк – яхшы, 6 – 9 ц/га – уртача, 1 – 5 ц/га – начар.

*Печәнлек җирләрен бәяләү.*

Печәнлекләр өчен түбәндәгеләр кулланыла:

- урман утыртылмаган урман бүлемтекләре, ачыклыклар һәм урман җире капламаган һәм урман культуралары утыртып, урманнарны торгызу мөмкин булмаган җирләр;
- яхшыртуга мохтаҗ, печән чабу өчен яраклы җирләр;
- реконструкция өчен билгеләнмәгән кыйммәте аз булган урман үсентеләре кишәрлекләре.

2.6.2.1 нче таблица

Печәнлек җирләренә характеристика

| Печән чабу тибы | Урнашкан җире | Үләне | Печән чабу тибы сыйфаты |
|---|---|---|---|
| Вакытлыча дымы артып киткән коры җирләр | Сизелер-сизелмәс су бүлү урыннары | Карчыга үләне, тубылгы, гравилат, тузгак кылган, башаклы үлән, түмәрлек, эт үләне, бөтнек | Уртача |
| Коры, | | | |
| тигез-ярлы җирләр | Инешләр үзәннәре, үлән баскан тар ярлар сөзәкләре һәм төбе тигез булмаган уйсулыклар | Тимофеевка, солычa, кылчыклы үлән, төлке койрыгы, бөтнек | Яхшы |
| Утача-артык дымланган түбәнлекләр | Киң үзәнлек түбәнлекләре | Бөртеклеләр, башаклы үлән, кузаклылар | Уртача |
| Сазланган түбәнлекләр | Грунт сулары якын булган сазланган түбәнлекләр | Дым яратучы бөртеклеләр, эре башаклы үлән | Начар |

Авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү өчен урманнардан файдалану

*Терлекләр көтү өчен җирләрне исәпкә алу*

Терлекләрне көтү, махсус сакланылучы табигать территорияләрендә, су саклау зоналарында, яшел зоналарда урнашкан урманнардан, эрозиягә каршы урманнарда һәм ОЗУдан тыш, барлык урманнарда да рөхсәт ителә.

Түбәндәгеләрдә терлекләрне көтү тыела:

- очларына терлек буе җитмәслек булганчы (1.5 – 2.0 м) урман культуралары кишәрлекләрендә;

- урман орлыкларын үстерү, чыршы, тал, тополь һәм чикләвек плантацияләрендә;

- табигый торгызуга ярдәм итү чаралары уздырыла торган кишәрлекләрдә;

- очларына терлек буе җитмәслек булганчы (1.5-2.0 м.) яшь урман үсентеләрендә;

- ылыслы һәм каты яфраклы токымнарны торгызу өчен билгеләнгән, урман үсентеләрен белән капланмаган җирләрдә;

- су һәм җир эрозиясе зарарлаган җирләрдә.

Авыл хуҗалыгы терлекләренең хуҗалары түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- урман культураларын, питомникларны, үзе шытып чыккан яшь урман үсентеләрен һәм башка кыйммәтле урман кишәрлекләрен зарарламас өчен киртәләп алу;

- авыл хуҗалыгы терлекләрен көтүче көтү (коймалы көтүлекләрдән һәм бәйләп куюдан гайре).

Кәҗә көтү авыл хуҗалыгы терлекләре хуҗалары киртәләгән урман кишәрлекләрендә һәм бәйләгән килеш кенә рөхсәт ителә.

*Көтүлекләрнең категорияләре һәм аларның азык продуктлылыгы*

Көтүлекләрне төрләргә бүлгәндә проект капланышын, үләннең төп төрләрен, аның куелыгын, асылда нинди үләннәрдән торуын, аларның сыйфатын региональ шкалалар кулланып күрсәтәләр. Алар булмаганда түбәндәгеләрне кулланырга мөмкин:

- яхшы җирләр – яхшыртылган һәм су баса торган, кузаклы-бөртеклеләр өстенлек итә торган (60% һәм аннан да күбрәк) кишәрлекләр; үләннең проект капламы – 60% һәм аннан да күбрәк);
- начар җирләр – табигый һәм каты үләннәр басып алган (60% аннан да күбрәк) (эре башаклы үлән, камышлык, ситник); башка үләннәрнең проект капламы 50%ка кадәр.

2.6.2.2 нче таблица

Терлекләрнең 1 башына якынча сезонлык көтү нормалары, га

| | |
|---|---|
| 0.5 – 0.6 тулылыктагы каен өстенлек итә торган яфраклы урманнар | 2 |
| 0.5 тулылыктагы чиста каенлыклар | 1.5 |
| Көтүлек өчен яраклы башка урман үсентеләре (1 баш мөгезле эре терлеккә яисә 7 сарыкка) | 4 – 5 |
| Куаклардан һәм шытып чыккан урман үсентеләре булмаган кисүлекләрдә | 0.75 |

Умартачылык

Бал бирүче бал кортлары өчен азык сыйфатында агачлары, куаклары яисә үләнле-куаклы ярусы составында бал бирә торган үләннәре булган урман кишәрлекләре кулланыла.

Умарта оялары һәм умарталыклар урнаштыру өчен беренче чиратта урман авызлары, ачыклыклар һәм урман үсентеләре капламаган башка җирләр бирелә.

Чәчәкле үсемлекләрнең 1000 артык төреннән бал кортлары чәчәк нектары һәм серкәсе җыя. Шуларның берсе – беренче дәрәҗәдә бал бирүчеләр, башкалары – икенче дәрәҗәдә бал бирүчеләр. Түбәндә аеруча киң таралган бал бирүче үсемлекләр тасвирламасы китерелә.

2.6.2.3 нче таблица

Бал бирүче үсемлекләрнең бал продуктлылыгы

| Бал бирүчеләр | Чәчәк атуның уртача сроклары | | Бал продуктлылы -гы, кг/га |
|---|---|---|---|
| | башлануы (дата) | продуктлылыгы (көннәре) | |
| Үги ана яфрагы | 12.04 | 30-60 | П* |
| Чикләвеклек | 20.04 | 6-9 | П* |
| Йолдыз чәчәк | 20.04 | 30 | П* |
| Кызыл тал | 22.04 | 5-30 | 150 |
| Баллыкый (аптека) | 23.04 | 30 | П* |
| Кәҗә талы | 28.04 | 10 | 150 |
| Бүре җиләге | 30.04 | 15 | П* |
| Үрмәләк үлән | апрель | 90 | П* |
| Үткен яфраклы чаган | 08.05 | 7-10 | 200 |
| Сыгылмалы тал | 10.05 | 5-10 | 150 |
| Ак тал | 11.05 | 15-20 | 150 |
| Карлыган | 20.05 | 10-20 | 50-140 |
| Шомырт | 21.05 | 12 | П* |
| Таплы яфрак | 24.05 | 45 | 100 |
| Чия | 23.05 | 10-12 | 30-40 |
| Сары сәрби | 25.05 | 10-14 | 350 |
| Алмагач | 26.05 | 10-12 | 20-30 |
| Дүләнә | май | 15 | П* |
| Нарат җиләге | май | 30 | П* |
| Татар чаганы | май | 7-10 | 100 |
| Миләш | май | 10 | 30-40 |
| Күгән | май | 15 | 25 |
| Зелпе | май | 20 | П* |
| Гади чамбыр | май-июнь | 34 | 140 |
| Кара җиләк | май-июнь | 30 | 30 |
| Болын шалфее | май-июнь | 30-60 | 110 |
| Эт шомырты | 06.06 | 14 | 35 |
| Балан | 11.06 | 30-45 | П* |
| Урман кура җиләге | 15.06 | 25-40 | 60-100 |
| Карлыган | 22.06 | 45-60 | 350-400 |

| Бал бирүчеләр | Чәчәк атуның уртача сроклары | | Бал продуктлылы -гы, кг/га |
|---|---|---|---|
| | башлануы (дата) | продуктлылыгы (көннәре) | |
| Эре яфраклы юкә | 23.07 | 14 | 500-600 |
| Ике еллык кандала үләне | 25.06 | 30 | 200-300 |
| Каен җиләге | июнь | 20 | 10 |
| Песи борчагы | июнь-июль | 30-40 | 180-370 |
| Дару шалфее | июнь-июль | 47 | 117-133 |
| Сары кандала үләне | июнь-июль | 30-40 | 150-200 |

Искәрмә: П* - алу төренә ярдәм итүче тип билгеләнгән.

2.6.2.4 нче таблица

Юкә чәчәк атканда чиста юкәлекләрдә бал җыю дәрәҗәсе, кг/га
(30% гомуми бал продуктлылыгыннан)

| Яше, ел | I – II бонитет | | III бонитет | | IV – V бонитет | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тулылылыгы | | | | | |
| | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 | 0,3 – 0,5 | 0,6 – 1,0 |
| 20 | 29 | 32 | 22 | 25 | 11 | 14 |
| 30 | 115 | 137 | 86 | 104 | 65 | 76 |
| 40 | 155 | 187 | 133 | 162 | 104 | 126 |
| 50 | 190 | 223 | 169 | 198 | 137 | 162 |
| 60 | 216 | 248 | 198 | 227 | 166 | 191 |
| 70 | 227 | 270 | 205 | 245 | 184 | 216 |
| 80 | 227 | 270 | 216 | 259 | 194 | 230 |
| 90 | 205 | 248 | 209 | 252 | 187 | 223 |
| 100 | 198 | 230 | 198 | 230 | 173 | 198 |
| 110 | 176 | 209 | 173 | 205 | 137 | 166 |
| 120 | 162 | 190 | 155 | 184 | 115 | 137 |
| 130 | 140 | 165 | 133 | 155 | 97 | 115 |
| 140 | 126 | 148 | 112 | 133 | 83 | 97 |
| 150 | 108 | 130 | 94 | 115 | 68 | 83 |

Юкәлекләрнең һәм башка урман үсентеләрендәге юкәнең бал продуктлылыгы

2.6.2.5 нче таблица

Нормаль юкәлекләрнең продуктлылыгы (Мурахтанов буенча)

| Яше | Үсентеләр тулылыгы | | |
|---|---|---|---|
| | 1,0 – 0,8 | 0,7 – 0,6 | 0,5 – 0,3 |
| 20 | 6.45 | 6.24 | 5.04 |
| 30 | 28.12 | 27.73 | 22.87 |

| Яше | Үсентеләр тулылыгы | | |
|---|---|---|---|
| | 1,0 – 0,8 | 0,7 – 0,6 | 0,5 – 0,3 |
| 40 | 43.35 | 42.49 | 35.32 |
| 50 | 53.09 | 52.04 | 42.98 |
| 60 | 61.52 | 60.25 | 49.93 |
| 70 | 66.44 | 65.14 | 54.03 |
| 80 | 59.04 | 67.25 | 56.05 |
| 90 | 67.29 | 65.96 | 54.50 |
| 100 | 62.11 | 60.65 | 50.57 |
| 110 | 55.49 | 54.24 | 45.13 |
| 120 | 48.72 | 47.71 | 39.57 |
| 130 | 41.30 | 40.43 | 33.67 |
| 140 | 35.18 | 34.47 | 28.63 |
| 150 | 30.08 | 29.34 | 24.46 |

Башка урман үсентеләре составында юкәнең бал продуктлылыгын исәпләп чыгару өчен түбәндәге формула тәкъдим ителә:

$$M = N \times 0.1K \times C \times S,$$ монда

M – кишәрлектә юкәнең бал продуктлылыгы;

N – 1 га (табл.) бал продуктлылыгы;

K – үсентеләр составында юкә коэффициенты;

C – юкәнең чәчәк ату чоры, көннәр (14 көн дип кабул ителгән);

S – бүлемтек мәйданы.

Гомуми мөмкин булган нектар запасын билгеләгәндә бал кортлары нектарның 30%ын гына җыйганнарын исәпкә алырга кирәк.

Тагын шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, районнардагы умарталыкларда нектар пробаларын алудан һәм үсемлекләрнең һәм умартачылык җирләренең бал продуктлылыгын билгеләүдән гыйбарәт булган бал продуктлылыгын исәпләүләр – бик күп хезмәт таләп итә һәм бары тик фәнни хезмәткәрләр яисә шушы максатлар өчен әзерләнгән эзләнү экспедицияләре белгечләре тарафыннан гына башкарылырга тиеш.

## Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен урманныкы булмаган җирләр, шулай ук урман утыртылмаган урман бүлемтекләре, ачыклыклар һәм урманнар каплап алмаган һәм аларда урманнарны торгызганчы билгеләнгән җирләр кулланыла.

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен кулланыла торган урман кишәрлекләрендә химик һәм биологик препаратлар "Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин эш итү турында" 19.07.1997 № 109-ФЗ Федераль закон нигезендә кулланыла.

Әлеге өлештә авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалануның инде булган хокукый җайга салынышына авыл хуҗалыгы эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затларга түбәндәге бурычлар йөкләнү турындагы нормалар өстәлә:

- гражданнар сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китермәү;

- урманнардан файдаланганда туфрак эрозиясе барлыкка килүне булдырмау, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, шулай ук су һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтыны булдырмау яисә чикләү.

## 2.7. Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Россия Федерациясе урман законнары нигезендә фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (сроксыз) файдалануга, башка фәнни оешмаларга, белем бирү оешмаларына арендага бирелә.

Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалануга урман кишәрлекләрендә урманнарны, табигатьнең бүтән компонентларын өйрәнү, алардан файдалану, аларны саклау, яклау торгызу өлкәсендә уку-укыту-гамәли базасы объектлары (урман табигатен өйрәнү, урманнарны исәпкә алу алымнарына, урман үсентеләрен кисүгә, урманнарны торгызуга өйрәтү һәм башка чаралар өчен полигоннар, тәҗрибә мәйданчыклары), укучыларда махсус белемнәр һәм күнекмәләр булдыру өчен урман инфраструктурасының кирәкле объектларын булдыру һәм алардан файдалану керә.

Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану әлеге Урман хуҗалыгы регламенты һәм урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

махсус тамгалар, мәгълүмат тамгалары һәм белем бирү эшчәнлеге һәм фәнни-тикшеренү эшләре башкарыла торган территорияне чикли торган бүтән тамгалар урнаштыру;

фәнни-тикшеренү максатларында урман үсентеләрен кисү;

урман инфраструктурасы булдыру;

фәнни-тикшеренү эшләнмәләрен һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре нәтиҗәләрен тәҗрибә-җитештерү һәм гамәлгә кертү максатларында, урманнарны саклау, яклау, торгызу һәм алардан файдалану буенча эксперименталь эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

уку-укыту-гамәли базасы объектлары булдыру һәм алардан файдалану;

урманнарны үзләштерү проекты белән каралган бүтән төр эшләр.

Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:

урман кишәрлегеннән читтә бирелгән урман үсентеләрен, үсемлек капламын һәм туфракны зарарлау;

бирелгән урман кишәрлеген һәм аннан читтәге территорияне төзелеш һәм көнүреш калдыклары, агач материалы калдыклары һәм башка калдыклар беләнчүпләү;

бирелгән урман кишәрлеген һәм аннан читтәге территорияне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның бирелгән урман кишәрлегеннән читтә юлларсыз, үзләре салган маршрут буенча узулары.

Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдаланган затлар түбәндәгеләрне тәэмин итәләр:

бирелгән урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып торуны;

эшчәнлек барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, шлюзларны, күперләрне, башка гидротехник корылмаларны, квартал баганаларын, квартал юлларын торгызуны;

әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрүне.

Фәнни-тикшеренү һәм белем бирү эшчәнлеген башкару өчен урманнардан рөхсәтле файдалану сроклары әлеге Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдә булу срогы белән чикләнә.

## 2.8. Рекреацион эшчәнлек башкару өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

### 2.8.1. Рекреацион эшчәнлек башкару өчен урманнардан файдалану нормативлары

Рекреацион эшчәнлек РФ УК белән кешеләрнең ялын, туризмны, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыруга кагылышлы эшчәнлек буларак карала.

Урманнардан мондый файдалану (РФ УКның 41 ст.) урман кишәрлекләре бирүне таләп итә, әмма урман ресурсларын җыймауны күз алдында тота торган эшчәнлек төренә кертелә, бирелгән урман кишәрлекләрендә кирәкле урман инфраструктурасы, шул исәптән твакытлы корылмалар булдырыла, территория төзекләндерелә (РФ УКның 13 ст.).

Рекреацион эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләре Рекреацион эшчәнлек башкару өчен урманнардан файдалану буенча РФ Урман хуҗалыгы министрлыгының 21.02.2012 №62 боерыгы белән расланган кагыйдәләрендә бәян ителә.

Урманчылык урманнары ландшафтлар төркемнәре һәм типлары буенча түбәндәгечә бүленә, күрсәткечләр 2.8.1.1 нче таблицада китерелә.

2.8.1.1 нче таблица

Ландшафтлар төркемнәре һәм типлары

| Төркемнәр | Типлар | Урман ябалдашының гомуми йомыклыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Ябык | Горизонталь рәвештә ябылган агачлар | 1,0-0,6 |
| | 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган шытымнар һәм урманчык ярусын исәпкә алып, вертикаль рәвештә ябылган агачлар | 1,0-0,6 |
| Ярымачык | Агачлар арасы тигез булган сирәкләнгән, 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган сирәк шытымнарлы һәм урманчыклы яисә аларсыз урман | 0,5-0,3 |
| | Агачлар арасы тигез булган сирәкләнгән, 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган сирәк шытымнарлы һәм урманчыклы яисә аларсыз урман | 0,5-0,3 (төркемнәрдә-0,7-0,6) |
| | 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган яшь агчлар | 0,5-0,4 |
| Ачык | Сирәклекләр, биеклегенә бәйсез рәвештә куаклар сирәк кенә шытып чыга башлаган берән-сәрән агачлары булган кишәрлекләр | 0,2-0,1 |
| | 1,5 метрдан артыграк биеклектәге урман яисә куаклыклар торгызыла башлаган кишәрлекләр (куелыгына бәйсез рәвештә) | |
| | Агач-куаклары булмаган кишәрлекләр | |

Урманда рекреацион эшчәнлек башкару түбәндәге санлы күрсәткечләр ярдәмендә бәяләнә: рекреацион файдалану интенсивлыгы, рекреацион йөкләнеш, мөмкин булган рекреацион йөкләнеш, объектның рекреацион сыешлыгы:

Рекреацион йөкләнеш билгеле бер вакыт эчендә (сәгать, көн, ай, сезон, ел) урманнарның бер берәмлек мәйданында (1 гектарда) ял итүче кешеләр саны.

Аерым урман кишәрлекләренә рекреацион йөкләнеш бик зур була, бигрәк тә автомобиль юллары, бакчачылык ширкәтләре, ял йортлары һәм башка савыктыру учреждениеләре буендагы нарат-каен урманнарына. Рекреацион йөкләнешнең һәм тулаем шәһәр урманнарындагы һәм алар янәшәсендәге территорләрдәге антропоген йогынтының төп төрләре түбәндәгеләр:

шәһәр халкының кышын һәм җәен урманнарда йөрүләре;

спорт белән шөгыльләнүләр;
урманнарда пикниклар;
кыргый үсемлекләр (гөмбәләр һәм җиләкләр) әзерләү;
кояшта кызынулар һәм су коенулар;
туристик походлар;
пионер лагерьларында һәм ял йортларында оештырылган сезонлы ял;
бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнү;
сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын ташлап китү;
шәхси транспортның оештырылмаган туктап торулары.

Мөмкин булган рекреацион йөкләнеш – шактый вакыт буена мондый йогынты нәтиҗәсендә урман биогеоценозларының үзлегеннән торгызылу үзенчәлекләреннән артып китмәгән йөкләнеш. Ул гадәттә бик аз бозылуларга китерә һәм биогеоценозларының аерым элементларына сизелер-сизелмәс үзгәрешләр кертә, аның структур һәм функциональ тотрыклылыгын үзгәртми. Антропоген йогынты нәтиҗәләрен бетерү өчен максатлы урманчылык катышуы таләп ителми.

Урман үсентеләренә иң зур рекреацион йөкләнеш елның җылы вакытына туры килә, гәрчә кайбер спорт төрләре кышын да гамәлгә ашырыла.

Түбәндә урман кишәрлекләрен, урман үсентеләренә мөмкин булган рекреацион йөкләнешне бәяләү шкалалары һәм рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрен әзерләгәндә файдаланырга кирәк булган территорияне төзекләндерүнең якынча нормалары китерелә.

2.8.1.2 нче таблица

Урман тирәлегенең рекреацион деградациясен бәяләү шкаласы

| Кишәрлек характеристикасы | Рекреацион деградация стадияләре |
|---|---|
| Урман тирәлеге бозылу күренешләре юк, агачлар һәм куаклар үсеше нормаль, аларда механик бозылулар юк; шытып чыкканнары һәм урманчык (төрле яшьтәге) яшәрлек. Әлеге урман төренә хас мүк һәм үлән капламы; аяк асты урман япмасы (сыгылмалы) бозылмаган. Рекреацияне җайга салу таләп ителми. | 1 |
| Урман тирәлеге сизелер-сизелмәс үзгәргән һәм агачлар һәм куаклар үсеше начарайган, аларда берән-сәрән механик бозылулар бар; шытып чыкканнары һәм урманчык (төрле яшьтәге) яшәрлек, уртача куелыкта, 20%ка кадәр зарарланган һәм кипкән нөсхәләр бар. Мүк белән проект капланышы – 20%ка кадәр, үлән капламы – 50%ка кадәр (шулардан 1/10 – болын үсемлекләре); аяк асты урман япмасы бераз бозылган, туфрак һәм аяк асты урман япмасы тыгызланган; агачларның | 2 |

| | |
|---|---|
| аерым тамырлары шәрәләнгән, туфракның 5%ка кадәр мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреацион эшчәнлекне җайга салу таләп ителә. | |
| Урман тирәлеге шактый үзгәргән һәм агачлар һәм куаклар үсеше зәгыйфьләнгән, кәүсәләр 10%ка кадәр механик зарарланган; шытып чыкканнары һәм урманчык (бер үк яшьтәге) зәгыйфьләнгән, уртача куелыкта яисә сирәк, 21-50% зарарланган һәм зәгыйфьләнгән нөсхәләр. Агач кәүсәләре тирәсендәге мүкләр, аларның проект капламы 70-60% (шулардан 2/10 болын үсемлекләре, чүп үләннәр калкый). Аяк асты урман япмасы тыгызланган, агачларның күп кенә тамырлары шәрәләнгән, туфракның 6-40% мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреацион эшчәнлекне актив җайга салу таләп ителә. | 3 |
| Агач-болын тибындагы урман тирәлеге бик нык үзгәргән, агачлар шактый зәгыйфьләнгән, кәүсәләр 11-20% ка кадәр механик зарарланган; шытып чыкканнары һәм урманчык (төрле яшьтәге) яшәрлек түгел (башлыча яшелләндерелгән кишәрлекләрдә), сирәк яисә бөтенләй юк, 50%тан артык зарарланган һәм зәгыйфьләнгән нөсхәләр. Мүкләр бөтенләй юк, проект үлән капламы 59-40% (шул исәптән 1/2 кадәр болын үсемлекләре һәм чүп үләннәр). Агачларның күп тамырлары шәрәләнгән, ачык урыннарда аяк асты урман япмасы бөтенләй юк, туфракның 41-60% мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреацион эшчәнлекне катгый рәвештә тыярга кирәк. | 4 |
| Урман тирәлеге деградацияләнгән; агачлар бик сирәкләнгән, болын тибында, агачлар бик зәгыйфьләнгән яисә кибеп баралар, 20%тан артыгы механик зарарланган; шытып чыкканнары һәм урманчык, мүкләр, аяк асты урман япмасы юк, проект үлән капламы 10%ка кадәр (шул исәптән 3/4кадәр болын үсемлекләре һәм чүп үләннәр), күп агачларның тамырлары шәрәләнгән һәм зарарланган. Туфракның 60% мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреация рөхсәт ителми. | 5 |

2.8.1.3 нче таблица

Кишәрлекне санитар-гигиеник бәяләү шкаласы

| Кишәрлек (бүлемтек) характеристикасы | Санитар-гигиеник бәяләү классы (баллы) |
|---|---|
| Кишәрлек яхшы санитар хәлдә, һава чиста, яхшы аэрация, техноген шау-шулар, кан эчкеч бөҗәкләр, үтеп чыкмаслык | 1 |

| | |
|---|---|
| куелыклар юк. Хуш исләр, урман авазлары, матур төсләр бар. | |
| Кишәрлек шактый яхшы санитар хәлдә, бераз гына чүпләнгән, берән-сәрән кипкән агачлар бар, һава бераз пычрак, техноген шау-шулар вакыт-вакыт була яисә бөтенләй юк. | 2 |
| Кишәрлек начар санитар хәлдә, черегән агач материалы белән чүпләнгән. Чүпләрне ташлау урыннары, карьерлар һәм аермалар бар, һава бик нык пычранган (шул исәптән тәмсез исләр килә). Җилле, бик күләгә урын, техноген шау-шулар югары дәрәҗәдә, кан эчкеч бөҗәкләр бик күп, артык дымлы, үтеп чыкмаслык куелыклар бар. | 3 |

Искәрмә: бәяләү кишәрлекнең санитар хәлен даими рәвештә күзәтү нәтиҗәсендә бирелә.

2.8.1.4 нче таблица

Үсентеләрнең биологик тотрыклылыгын бәяләү шкаласы

| Тотрыклылык класслары | Агымдагы һәлак булу күләме һәм характеристикасы (кибеп баручы агачлар һәм яңа гына кипкәннәр) | Кибүнең гомуми күләме (2 һәм 3 төркем хәлендәге агачлар + чүпләнү) | Зарарлы бөҗәкләр һәм авырулар булу | Урман тирәлеге торышы |
|---|---|---|---|---|
| 1 – тотрыклы | 2%ка кадәр (1,3м биеклектә диаметры уртачадан кимрәк булган агачлар исәбенә) | 5%ка кадәр | Юк яисә берән-сәрән | Бозылмаган |
| 2– тотрыклылык бозылган | 2 аннан да күбрәк мәртәбә табигый һәлак булудан артык булган (1,3м биеклектә диаметры | 6 % - 40% | Киң таралган яисә саны күп булырга мөмкин | Кагыйдә буларак, бозылган, тулылыгы тигез түгел яисә түбән |

| Тотрыклылык класслары | Агымдагы һәлак булу күләме һәм характеристикасы (кибеп баручы агачлар һәм яңа гына кипкәннәр) | Кибүнең гомуми күләме (2 һәм 3 төркем хәлендәге агачлар + чүпләнү) | Зарарлы бөҗәкләр һәм авырулар булу | Урман тирәлеге торышы |
|---|---|---|---|---|
| | уртачага якын булган агачлар исәбенә) | | | |
| Тотрыклылык класслары | Агымдагы һәлак булу күләме һәм характеристикасы (кибеп баручы агачлар һәм яңа гына кипкәннәр) | Кибүнең гомуми күләме (2 һәм 3 төркем хәлендәге агачлар + чүпләнү) | Зарарлы бөҗәкләр һәм авырулар бар | Урман тирәлеге торышы |

Искәрмә:

Биологик тотрыклылыгы 2 нче класслы булган агачларга сайлап алып кисү уздыралар, 3 нчесендә – тоташ (башка хуҗалык күрсәтмәләре булмаганда).

2 нче һәм 3 нче класслы биологик тотрыклы урман үсентеләренең суммар мәйданы санитар хәле канәгатьләнерлек булмаган урман үсентеләре мәйданнарын тәшкил итә.

Үтеп йөрүчәнлек:
1 – яхшы
2 – уртача
3 – начар

Күрүчәнлек:
1 – яхшы
2 – уртача
3 – начар

2.8.1.5 нче таблица

Кишәрлекне эстетик бәяләү шкаласы

| Класс | Үсентеләр | Ачык пространстволар |
|---|---|---|
| 1 | Агач ябалдашы озын һәм киң, сәламәт һәм матур урманчыклы | 1,0 га кадәр мәйданы (ачыклыклар, аланнар), яхшы дренажланган әйбәт |

| Класс | Үсентеләр | Ачык пространстволар |
|---|---|---|
| | һәм уртача куелыкта шытымнары булган I-II класс бонитетлы ылыслы һәм яфраклы үсентеләр. Үтеп йөрүчәнлеге яхшы булган, чүпләнмәгән кишәрлек | һәм коры туфрак; катлаулы, борылмалы чикләре булган 1 до 3га кадәр мәйданлы, яхшы билгеләнгән рельефлы, декоратив урман авызлары булган кишәрлекләр, берән-сәрән декоратив агачлары яисә формалашкан агач-куак төркемнәре; декортаив үсемлекләр белән әйләндереп алынган, ярлары күренеп торган зур булмаган матур сулыклары бар |
| 2 | Зирек һәм усак катнашында составында 5 берәмлеккә кадәр III класс бонитетлы уртача киңлектәге һәм озынлыктагы ябалдашлы, куе яисә зәгыйфь ары һәм урманчыгы булган үсентеләр. Кишәрлек өлешчә чүпләнгән (5 м3/га кадәр) | Чикләре конфигурациясе гади булган зур күләмле ачык пространстволар; аз декоративлы үсемлекләр белән әйләндереп алынган су пространстволары; агач үсми торган, куак басып алган кишәрлекләр |
| 3 | Зирек һәм усак, шулай ук IV-V класслы бонитетлы ылыслылар өстенлек иткән үсентеләр. Агачларның ябалдашлары начар үскән. Чүпләнү һәм кипкән агач 5 м3/га һәм аннан да күбрәк | Урман утыртылмаган киселгән урыннар, сөрүлекләр, электрүткәргеч линияләр, хуҗалыклар, сазлыклар һәм башка ачык мәйданнар, декоративлыгы түбән булган сулыклар |

Искәрмә:

Ачык ландшафтларны эстетик бәяләү түбәндәге күрсәткечләрне исәпкә алып уздырыла:

- урындагы хәле, туфрак дымлылыгы, үтеп йөрүчәнлек;
- кишәрлекнең күләме һәм конфигурациясе;
- урман авызларының һәм ачык пространстволар янәшәсендәге урыннарның матурлыгы;
- агачларның һәм куакларның берән-сәрән яисә зур булмаган төркемнәре булу һәм аларны урнаштыру характеры;
- үлән һәм мүк капламының сыйфаты;
- сулыкларның күләме һәм конфигурациясе, ярларының һәм әйләнә-тирәсендәге үсемлекләрнең характеры, ял итүчеләрнең суга керә алуы, сулыкның санитар хәле һәм аны ял итү һәм коену өчен куллану мөмкинлеге.

2.8.1.6 нче таблица

Агачлар торышы категорияләре шкаласы
(һәр агач саен инвентарьлаштыру өчен)

| Агачлар категориясе | Төп сыйфатлары | Өстәмә сыйфатлары |
|---|---|---|
| ЫЛЫСЛЫ ТОКЫМНАР | | |
| 1 – зәгыйфьләнү сыйфатларыннан башка | Ылыслары яшел, ялтырап тора, ябалдашы куе, әлеге токым, шушы яшьтәгеләр, үсү шартлары һәм ел фасылы өчен агымдагы елда шытып чыкканнары нормаль | |
| | Ылыслары еш кына ачык яшел, ябалдашы бик челтәрле түгел, шытып чыкканнары нормаль белән чагыштырганда яртылаш кимегән | Кәүсәсендә һәм тамырларында, ботакларында урыны-урыны белән зараланулар булырга мөмкин |
| | Ылыслары ачык яшел яисә соры тоны, ябалдашы челтәрсыман, шытып чыкканнары нормаль белән чагыштырганда яртыдан да күбрәк кимегән | Кәүсәсендә, тамырларында һәм ябалдашында, ботакларында зараланулар булырга мөмкин, кәүсәләрендә яисә ботакларында корткычлар оялау сыйфатлары булырга мөмкин |
| 2 – зәгыйфьләнгән | Ылыслары соры, сары яисә саргылт-яшел, ябалдашы шактый сирәкләнгән, агымдагы елда шытым юк диярлек яисә бөтенләй юк | Кәүсәсендә һәм башка өлешләрендә зарарланулар алдагы категория белән чагыштырганда бик күп, кәүсәләрендә корткычлар оялау сыйфатлары (сагыз бүрәнкәләре, коңгырт он, кайрысында, кайры астында һәм үзагачында бөҗәкләр) булырга мөмкин |
| 3 – бик зәгыйфьләнгән | Агымдагы ел ылыслары, сары яисә коңгырт, ябалдашы бик нык сирәкләнгән, вак ботаклары бар әле, кайрысы сакланган яисә өлешчә коелган | Алдагы категория сыйфатлары; сезон азагында агачның бер өлешендә бөҗәкләр очып чыга торган тишекләр пәйда булу мөмкин |
| 4 – кибеп баручы | Ылыслары коелган яисә өлешчә сакланып калган, вак ботаклары, кагыйдә буларак, сынып беткән, кайрысы коелган | Кәүсәсендә һәм ботакларында бөҗәкләр очып чыга торган тишекләр пәйда булган, кайрысы астында – бик күп коңгырт он һәм гөмбәчек |
| ЯФРАКЛЫ ТОКЫМНАР | | |

| Агачлар категориясе | Төп сыйфатлары | Өстәмә сыйфатлары |
|---|---|---|
| 1 – зәгыйфьләнү сыйфатларыннан башка | Яфраклары яшел, ялтырап тора, ябалдашы куе, әлеге токым, шушы яшьтәгеләр, үсү шартлары һәм ел фасылы өчен агымдагы елда шытып чыкканнары нормаль | |
| 2 – зәгыйфьләнгән (ябалдашларының 1/4е кипкән) | Яфраклары яшел; ябалдашы бик челтәрле түгел, шытып чыкканнары нормаль белән чагыштырганда кимегән, кипкән ботаклары 1/4дән ким | Кәүсәсендә һәм тамырларында, ботакларында урыны-урыны белән зараланулар, механик зарарланулар, берән-сәрән сулы шытымнар булырга мөмкин |
| 3 – бик зәгыйфьләнгән (ябалдашларының 1/2е кипкән) | Яфраклары гадәттәгедән ваграк яисә ачыграк төстә, вакытыннан алда коела, ябалдашы сирәкләнгән, кипкән ботаклары 1/4дән ½ гә кадәр | Алдагы категория сыйфатлары күбрәк чагылыш тапкан; кәүсәләрендә яисә ботакларында корткычлар оялау сыйфатлары булырга мөмкин, суты агу һәм сулы шытымнар булырга мөмкин |
| 4 – кибеп баручы, ябалдашларының 1/2еннән артыграгы кипкән | Яфраклары гадәттәгедән ваграк яисә сары төстә, вакытыннан алда коела яисә шиңә, ябалдашы сирәкләнгән, кипкән ботаклары 1/2дән 3/4кә кадәр | Кәүсәләрендә һәм ботакларында корткычлар оялау сыйфатлары (керү тишекләре, кисекләр, суты агу һәм агач вагы, коңгырт он, кайрысында, кайры астында һәм үзагачында бөҗәкләр), бик күп сулы шытымнар, өлешчә кипкән һәм кибеп баручы ботаклар булырга мөмкин |
| 5 – агымдагы елда корыган (әле генә) | Яфраклары кипкән, шиңгән яисә вакытыннан алда коелган, кипкән ботаклары 3/4, вак ботаклары һәм кайрысы сакланып калган | Кәүсәсендә һәм тамырларында, ботакларында бөҗәкләр оялау һәм гөмбәчекләр белән зарарлану сыйфатлары булырга мөмкин |
| 6 – үткән елларның корыган агачлары | Яфраклары һәм кайбер ботаклары коелган, кабыгы җимерелгән яисә кәүсәсенең бер өлешендә коелган | Кәүсәсендә һәм ботакларында бөҗәкләр очып чыга торган тишекләр пәйда булган, кайрысында һәм кайрысы астында – гөмбәчек һәм гөмбәләрнең үзләре була |

Җил аударганны, буран аударганны, кар аударганны, алар барлыкка килү вакытын күрсәтеп, аерым исәпкә алалар.

Яңадан санап чыкканда төрле категориядәге агачларга кәүсә корткычлары оялау һәм, зарарлану ачык күренеп торса, авырулар белән зарарлану дәрәҗәсе күрсәтелә. Ылыс һәм яфрак кимерүчеләр чыганакларында ылыслары һәм яфраклары торгызылганнан соңгы чорда агачлар яңадан санала, аңарчы кирәк чакта ылысны яисә яфракны ашау дәрәҗәсе процентларда күрсәтелә (1 – зарарсыз, 2 – аз гына зарарланган – 25%тан ким, уртача – 25-50%, бик нык – 50-75%, тулысынча –75%тан артык).

Ял итү өчен табигать ландшафларын тәртипсез һәм системасыз файдалану төзекләндерү элементлары булмау туфрак өстендәге капламны бозуга, урман тирәлеген пычратуга һәм урман бергәлекләренең (урман фитоценозының) гомуми зәгыйфьләнүенә китерә. Территорияне төзекләндерү – кешенең табигатькә тискәре йогынтысын азайтырлык бердәнбер цивилизацияле алым.

Урман тирәлеге, алдан урман кишәрлекләре рекреация өчен әзерләнмәгән булса, 10 кеше/га йөкләнеш булганда җимерелә башлый. Шуңа күрә функциональ зоналар буенча урнаштырыла торган рекреацион объектларның табигать тирәлеген бозмыйча гына ял итү мөмкинлеге тудыра торган мәйданчыклары булырга тиеш. Рекреацион йөкләнешенә карап, урман кишәрлекләреннән ял итү өчен файдалану режимы түбәндәгечә булырга мөмкин:

- ирекле – йөкләнеш 5 кеше/га (тыныч ял итүнең аз төзекләндерелгән зонасы);
- уртача җайга салынучы – йөкләнеш 6-20 кеше/га (актив ял итүнең җитәрлек дәрәҗәдә рекреацион объектлар белән төзекләндерелгән зонасы);
- катгый җайга салынучы – йөкләнеш 20 кеше/га дан артык (актив ял итүнең аерым урман кишәрлекләре, алар максималь рәвештә төзекләндерелгән булырга тиеш).

2.8.1.7 нче таблица

Рекреацион билгеләнештәге урманнарда урманнардан файдалануның төп хуҗалык чаралары һәм төрләре

| № т/с | Чаралар исеме | Функциональ зоналар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ял | ял итеп җәяү йөрү | фауна тынычлыгы |
| *I. Лесохозяйственные мероприятия* | | | | |
| 1. | Түбәндәге максатта урманнарны карау өчен кисүләр: | | | |
| | Ландшафтлар формалаштыру | + | + | - |
| | Кыйммәте булмаган үсемлекләрне бетерү | + | + | + |
| | Табигый торгызылуга ярдәм итү | + | + | + |

| №<br>т/с | Чаралар исеме | Функциональ зоналар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ял | ял итеп җәяү йөрү | фауна тынычлыгы |
| | Шытымнарны карау | + | + | + |
| | Гамәлдәге һәм булдырылган урман ландшафтларын карау | + | + | + |
| | Урман үсентеләрен яңадан формалаштыру һәм яңарту | + | + | - |
| 2. | Реконструкцион кисүләр | + | + | - |
| 3. | Түбәндәге максатта башка кисүләр: | | | |
| | Ачык ландшафтлар булдыру, перспективаларны чистарту | + | - | - |
| | Күзәтү нокталарында, рекреациягә мөнәсәбәте булмаган үсемлекләрдән арындыру | + | - | - |
| | Ял итү һәм төзекләндерү объектларын төзү өчен мәйданчыклар чистарту | + | + | - |
| | Ачык ландшафтларны һәм күзәтү нокталарын карау | + | + | - |
| 4. | Агач һәм куакларны түбәндәге максатта утырту: | | | |
| | Ландшафтлар формалаштыру | + | + | - |
| | Урманның санитар-гигиеник сыйфатларын һәм үсентеләрнең тотрыклылыгын арттыру | + | + | - |
| | Урманны торгызу | - | + | + |
| | Ремизлар булдыру | - | - | + |
| | Үсентеләрне реконструкцияләү | + | + | - |
| 6. | Ачык пространстволарда үләннәрне карау | + | + | - |
| 7. | Табигатьне саклау чаралары | + | + | + |
| 8. | Санитар-яклау чаралары, шул исәптән санитар кисү | + | + | + |
| 9. | Янгынга каршы чаралар | + | + | + |
| 10. | Урманнарны ял итүчеләр тарафыннан бозуларны профилактикалау | + | + | + |
| *II. Биотехник чаралар һәм фаунаны саклау* | | | | |
| 1. | Хайваннарның яшәү тирәлеге | - | - | + |

| № т/с | Чаралар исеме | Функциональ зоналар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ял | ял итеп җәяү йөрү | фауна тынычлыгы |
| | шартларын яхшырту | | | |
| 2. | Хайваннарны өстәмә ашату мәйданчыкларын кору һәм өстәмә ашату | - | + | + |
| 3. | Оялар кору һәм элеп чыгу | + | + | + |
| 4. | Урман хуҗалыгы эшләрен регламентлау һәм чикләү | - | - | + |
| *III. Территорияне төзекләндерү* | | | | |
| 1. | Юл-сукмак, автомобильләр өчен туктап торуның ясалма корылмаларын булдыру | + | + | - |
| 2. | Рекреацион маршрутлар булдыру | + | + | - |
| 3. | Күзәтү нокталары һәм мәйданчыклары булдыру | + | + | - |
| 4. | Ял итү мәйданчыклары булдыру һәм төзекләндерү | + | + | - |
| 5. | Архитектураның кече рәвешләрен һәм урман паркы җайланмаларын төзү һәм урнаштыру | + | + | - |
| 6. | Визуаль мәгълүмат | + | + | + |
| 7. | Күргәзмә агитация | + | + | - |
| 8. | Төн кунып, җәйге стационар ял итү урыннарын кору һәм җиһазландыру | + | - | - |
| 9 | Төзекләндерү объектларын карап тоту, аларга ремонт ясау | + | + | + |
| *IV. Урманнардан файдалану* | | | | |
| 1. | Өлгергән һәм картайган урман үсентеләрен кисү | - | - | - |
| 2. | Урманнарны торгызу өчен кисү | - | - | - |
| 3. | Печән чабу | + | + | - |
| 4. | Терлекләр көтү | - | - | - |
| 5. | Җиләкләрне, гөмбәләрне, чикләвекләрне һәвәскәр җыю | + | + | - |
| 6. | Дару чималын һәвәскәр җыю | + | + | - |
| 7. | Умартачылык | - | - | - |

Искәрмә: «+» тамгасы - файдалану рөхсәт ителә;
«-» тамгасы - файдалану рөхсәт ителми.

### 2.8.2. Рекреацион эшчәнлек зонасы кварталларының һәм (яисә) кварталлары өлешләренең исемлеге

Рекреацион эшчәнлек зонасы кварталларының һәм (яисә) кварталлары өлешләренең урман кишәрлекләре буенча исемлеге әлеге Регламентның 1.2 нче таблицасында китерелде (урманнарны максатчан билгеләнеше һәм яклаучы урманнар категорияләре буенча бүленеше).

### 2.8.3. Рекреацион эшчәнлек зонасы территориясен функциональ зоналаштыру

Функциональ зоналаштыру буенча рекреацион зоналар түбәндәгеләргә бүленә:

1. Интенсив файдалану;
2. Уртача файдалану;
3. Концентрацион ял итү;
4. Резерватив;
5. Тыюлык;
6. Катгый режим;
7. Хуҗалык.

### 2.8.4. Урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар исемлеге һәм аларны төзекләндерү нормативлары

2.8.4 нче таблица

Урманнарда рекреацион территорияне төзекләндерү нормалары
(100 га гомуми мәйданга)

| № т/с | Төзекләндерү элементлары исеме | Яшел зона | | Алар чикләрендә туристик маршрутлар (1 км маршрутка) |
|---|---|---|---|---|
| | | актив ял | ял итеп җәяү йөрү | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Автомобильләр килү өчен киңлеге 4,5 м (км) булган вак ташлы юллар | 0,15 | 0,02 | - |
| 2. | Массивлар эчендә вак ташлы полотно киңлеге 3 м (км) булган юллар | 1,8 | 0,5 | - |
| 3. | 15 машиналык автотукталышлары белән вак таш катыш грунт юллары (данә) | 0,25 | 0,03 | - |
| 4. | Ял итеп йөрү сукмаклары (км) | - | 0,04 | - |
| 5. | 4 урынлык утыргычлар (данә) | 18 | 3 | 1 |
| 6. | 6 урынлык пикник өстәлләре (данә) | 7 | 0,6 | - |
| 7. | Яңгырдан ышыклану урыннары (данә) | 1,5 | 0,2 | 0,2 |
| 8. | Азык-төлек әзерләү учаклары (данә) | 3,5 | 0,5 | 0,6 |
| 9. | Урналар (данә) | 30 | - | - |
| 10. | Чүп җыю савытлары (данә) | 3,5 | - | - |
| 11. | Бәдрәфләр (данә) | 0,18 | - | - |
| 12. | Спорт һәм уен мәйданчыклары, м2 | 37 | - | 5 |
| 13. | Елгаларда һәм сулыкларда кызыну урыннары, м2 | 90 | 15 | - |
| 14. | Кызыну урыннарындагы кабиналар (данә) | 0,18 | 0,02 | - |
| 15. | Беседкалар (данә) | 0,17 | - | - |
| 16. | Күрсәткечләр (данә) | 1,5 | 0,2 | 0,4 |
| 17. | Күзәтү нокталары (данә) | 0,7 | 0,1 | 0,3 |
| 18. | Коелар һәм чишмәләр (данә) | 0,02 | 0,01 | 0,1 |
| 19. | Туристлар палаткаларын кую мәйданчыклары, м2 | 50 | - | 20 |

Рекреацион эшчәнлек башкару өчен объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү карала торган чикләрдә планлаштырыла торган урманнарны үзләштерү зоналары (физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалар):

| № т/с | Участок урманчылыгы исеме | Кварталлар номерлары | Мәйдан, га |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәлбагыш | 1 квартал | 0,08 |
| 2. | Азнакай | 148 квартал | 3,8 |
| 3. | Азнакай | 148 квартал | 4,7 |
| 4. | Азнакай | 146 квартал | 4,75 |

## 2.8.1. Рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдалану параметрлары һәм сроклары

Урманнарда урман законнарының норматив хокукый актлары нигезендә расланган Рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре белән түбәндәгеләр карала:

рекреацион эшчәнлек алып бару өчен бирелә торган урман кишәрлекләре күләмнәрен билгеләгәндә, урман үсентеләренә зарар китермәү шартларын үтәгән килеш, урман экосистемасына оптималь рекреацион йөкләнешкә таянырга кирәк;

ял итү, туризм, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыру максатларында рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдаланучы затлар туристик станцияләр, туристик сукмаклар һәм трассалар оештырырга, мәдәни-массакүләм чаралар, җәяүлеләр, велосипедчылар һәм чаңгычылар өчен йөрүләр, сынлы сәнгать белән шөгыльләнүлә, белем алу һәм экологик экскурсияләр, урманнарда уздыру өчен яраклы аерым спорт төрләре буенча спорт ярышлары, физкультура-спорт фестивальләре һәм күнегүләр өчен җыелулар, шулай ук рекреацион эшчәнлекнең бүтән төрләрен оештырырга мөмкин;

рекреацион эшчәнлек алып бару өчен бирелә торган урман кишәрлекләрендә табигать ландшафтлары, хайваннар дөньясы объектлары, су объектлары сакланырга тиеш;

рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урманнар әйләнә-тирә мохиткә һәм кешеләр сәламәтлегенә зыян китермәслек алымнар белән файдаланыла;

рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдалану гражданнарның урманнарда булу хокукына каршы килмәскә тиеш;

урманнарда рекреацион эшчәнлек алып барганда урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар (беседкалар, эш коралы саклау урыннары һәм башкалар) кору һәм урман кишәрлекләрен төзекләндерү (юл-сукмак челтәре, мәгълүмат стендлары һәм табигатьне саклау тематикасы буенча аншлаглар, утыргычлар, янгырдан ышыклану чатырлары, хәрәкәт итү күрсәткечләре, чүп ташлау өчен контейнерлар һәм башка төзекләндерү элементлары урнаштыру) рөхсәт ителә;

бирелгән урман кишәрлекләрен төзекләндерү максатларында рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдаланучы затлар урманнарны үзләштерү проекты нигезендә урманнарны карап тоталар;

вакытлы корылмалар, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалар урнаштыру иң беренче чиратта – агач-куаклар биләмәгән урман кишәрлекләрендә, андыйлары булмаганда кыйммәте түбән булган урман үсентеләре били торган кишәрлекләрдә, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә;

урманнарда рекреацион эшчәнлек алып бару өчен объектлар төзү максатларында урманнарны үзләштерү проекты нигезендә урман үсентеләрен кисү рөхсәт ителә;

урманнарда рекреацион эшчәнлек алып барганда бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлек капламын һәм туфракны зарарлау, бирелгән урман кишәрлегендә һәм аның янәшәсендәге территорияләрдә мәйданчыкны көнкүреш калдыклары, бүтән төрле калдыклар белән чүпләү,

транспорт чаралары һәм башка механизмнар билгеләнмәгән маршрутлар буенча үз белдекләре буенча үтеп йөрү рөхсәт ителми;

архитектураның кече рәвешләрен урнаштыру һәм ял итү һәм тәмәке тарту урыннарын билгеләү юлы белән халыкның массакүләм ялы өчен уңайлы шартлар тудыру урман экосистемаларының экологик шартларына тискәре йонынтыны киметергә ярдәм итә.

Халыкның культуралы ялы өчен шартлар тудыру һәм рекреацион йөкләнешләрне җайга салу максатында территорияне төзекләндерү буенча төрле чаралар тәкъдим ителә, алар югары дәрәҗәдә халык ял итсен өчен түбәндәгеләр ярдәмендә урман кишәрлекләрен файдаланырга ярдәм итә:

урман плакатлары һәм паннолар элү;

автотукталышлар төзү һәм җиһазлау;

гади җайланмалар ярдәмендә тәмәке тарту урыннары кору;

юл-сукмак челтәре төзү;

урман җиһазлары комплектларын (ашау өстәлләре, утыргычлар) урнаштыру;

яңгырдан һәм башка шундый күренешләрдән ышыклану чатырлары кору;

туристлар палаткаларын кую мәйданчыкларын булдыру;

учаклар өчен урыннар билгеләү һәм җиһазлау;

азык-төлек әзерләү учаклары кору;

учаклар өчен утын әзерләү;

чүп өчен урналар кую һәм чүп җыю урыннарын җайлаштыру;

чишмәләрдә эчәр сулар җыю урыннарын кору;

бәдрәфләр төзү;

кошлар өчен җимлекләр урнаштыру;

тиеннәр, куяннар һәм тояклылар өчен тозлыклар урнаштыру;

рекреацион урманнарда туфрак-мелиоратив чаралар уздырылырга мөмкин: ашламалар кертү, известьлаштыру, мульчалау, йомшарту, киртәләү;

рекреацион эшчәнлек алып бару, урман сукмакларыннан һәм гидротехник корылмалардан гайре, капиталь төзелеш объектларын төземичә генә, урманчылык территориясендә рөхсәт ителә;

урманнар кешеләрнең ялын, туризмны, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыру максатларында рекреацион эшчәнлек алып бару өчен файдаланылырга мөмкин;

рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (сроксыз) файдалануга, башка затларга – арендага бирелергә мөмкин;

рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдаланганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре һәм Урманнарда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итү зарур;

янгыннар сезонында урманнар территориясендә рекреацион эшчәнлек алып барганда массакүләм чаралар уздыру, җирле үзидарә органнары белән килештереп, файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә учак ягу һәм чүп җыю урыннары булдыру шарты белән генә рөхсәт ителә.

Рекреацион эшчәнлек алып бару өчен урман кишәрлекләре даими (сроксыз) файдалануга яисә арендага бирелгән затлар аны уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алган урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашыра.

2.8.5 нче таблица

Төзекләндерү буенча чаралар күләме

| № т/с | Чаралар | Үлчәү берәмлеге | Күләме | Урнашкан җире (участок урманчылыгы, квартал) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Яңгырдан ышыклану чатырлары,, павильоннар кору | данә | 5 | урманчылар карамагында |
| 2. | Ярлар, күлләр, сулар аша җәяүлеләр басамалары кору | данә | 1 | |
| 3. | Утыргычлар һәм диваннар кору | данә | 20 | |
| 4. | Автотукталышлар кору | данә | 2 | |
| 5. | Бәдрәфләр кору | данә | 5 | |
| 6. | Күрсәткеч щитлар, аншлаглар урнаштыру | данә | 20 | |
| 7. | Ял итү өстәлләре кору | данә | 10 | |
| 8. | Учаклар өчен урыннар билгеләү һәм җиһазлау | данә | 10 | |
| 9. | Туристлар палаткаларын кую мәйданчыкларын булдыру | данә | 10 | |
| 10. | Сукмаклар салу | км | 6 | |
| 11. | Уен мәйданнары һәм стадионнар кору | данә | 1 | |

## 2.9. Урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен урманнардан рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү билгеле бер максатчан токым урман үсентеләрен үстерүгә бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт. Билгеле бер (максатчан) токым урман үсентеләренә, куелган характеристикалары булган агач материалын алуны тәэмин итә торган ясалма чыгышлы урман үсентеләре кертелә. Урман плантацияләре урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрдә (урман үсемлекләре каплап алмаган җирләрдә һәм урманныкы булмаган җирләрдә) булдырылырга

мөмкин. Урман плантацияләрендә урман үсентеләрен кисү һәм урман үсентеләренә кирт салу чикләүләрсез рөхсәт ителә (РФ УК 42 ст.).

Гражданнарга, юридик затларга урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре – РФ УК нигезендә, җир кишәрлекләре – җир законнары нигезендә арендага бирелә.

Дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлеген урман плантацияләре булдыру өчен арендага бирү шартнамәсе РФ УКның 72 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә

Плантацияләр булдыру максатларында түбәндәгеләрне файдалану рөхсәт ителми: су саклау зоналарында урнашкан урманнарны; табигать һәм бүтән объектларны яклау вазыйфасын башкаручы урманнарны; кыйммәте булган урманнарны; урманнарның махсус якланучы кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны.

## 2.10. Урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү (РФ УК 39 ст.) җимешләр, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре һәм башка шундый урман ресурслары алуга бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт. Аларны үстерү өчен файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар урнаштыру рөхсәт ителә.

Урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү өчен беренче чиратта урман фондының урманныкы булмаган җирләреннән, шулай ук урман утыртылмаган урман бүлемтекләреннән, ачыклыклардан һәм урман үсемлекләре каплап алмаган, аларда урман культуралары утырткачы урманнарның табигый торгызыла торган җирләреннән; рекультивацияләнергә тиешле җирләрдән (эшкәртелгән торфянниклардан һәм башкалардан) файдаланырга мөмкин.

Урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәрен урман ябалдашлары астында үстерү өчен реконструкция өчен билгеләнмәгән кыйммәте түбән булган урман кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин.

Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр очрый торган урман кишәрлекләре урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану РФ УКның 59 статьясы нигезендә тыела.

*Урман азык-төлек продукциясен плантацион үстерү перспективалары.*

Кыргый үсүче азык-төлек һәм дару үләннәре өлкәсендә шактый гына табигый запаслар булуга карамастан, соңгы 20-30 елда кайбер төр җиләкләрне, җимеш бирә торган үсемлекләрне һәм гөмбәләрне ясалма үстерү тенденциясе барлыкка килде. Моның сәбәбе – плантацияләрдә үстерелгән продукциянең үзкыйммәте халыктан җыелган шул ук төр кыргый үсүче үсемлекләрне сатып алу бәяләренә караганда кимрәк чыга.

Плантацияләрдә барлык төр эшләрне дә бергә туплап һәм механикалаштырып була, шул исәптән әзерләүне дә, бер берәмлек мәйданнан уңышны арттырып, һава шартларына бәйлелекне бетереп, селекция өчен шартлар тудырып, продукциянең сыйфатын арттырып була.

Аз гына чыгымнар белән табигый шартларда иң продуктив үсемлекләрне сайлап алырга һәм аларда җимеш бирү һәм эксплуатацияләү (ягъни культуралаштыру) өчен оптималь шартлар тудырырга мөмкин.

Культивацияләнергә мөмкин булган һәм культураны гамәлгә керткәндә үз сыйфатларын югалтмый торган үсемлек төрләре плантацияләрен булдыру максатка ярашлырак.

Өлкә шартлары түбәндәгеләр плантацияләрен булдыру өчен яраклы: кара миләш (арония), сырганак, гөлҗимеш, кара карлыган һәм башка азык-төлек үсемлекләре, дару үләннәре, гөмбәләрдән – шампиньон плантацияләре.

Сатып алу бәяләре бик зур булган заманда акчаны плантацияләр булдыруга кертергә мөмкин.

Гөлҗимеш плантацияләре өчен иң яхшы туфрак – озак су баса торган елгаларның үзәннәрендәге органик матдәләргә бай кара туфрак һәм куе соры урман туфрагы. Плантацияләр булдыру өчен сөргәннән, органик 100 т/га, фосфорлы 160 кг/га, калийлы 80 кг/га ашламалар керткәннән соң 3 х 1,5 м лы чокырларга һәм буразналарга гөлҗимеш утыртыла, уңыш бу вакытта 5,0 тонна/га җитә.

Урманчылыкларда ясалма алым белән гади вешенка гөмбәсе үстерергә мөмкин. Бер тонна гөмбә җитештерү өчен лабораторияләрдә үстерелә торган инокулянт йоктырырга һәм плантациягә 25-30 см озынлыктагы һәм 22 см диаметрлы 700 усак кисәге утыртырга кирәк, өч ел эчендә бер тонна гөмбә алырга мөмкин булачак.

## 2.11. Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү урманнарны торгызу һәм үрчетү максатында гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (сроксыз) файдалануга, башка затларга арендага бирелә.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану урманчылыкның яисә урман паркының урман хуҗалыгы регламентлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Урман кодексының 24 статьясындагы 2 өлеше нигезендә урманнардан файдаланучы гражданнарның, юридик затларның урман хуҗалыгы регламентын һәм урманнарны үзләштерү проектын үтәмәүләре урман кишәрлеген арендалау шартнамәсен вакытыннан алда туктату, шулай ук урман

кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану хокукын мәҗбүри туктату өчен нигез була.

Урманнардан файдаланучы гражданнар, юридик затлар Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган тәртиптә граждан законнары нигезендә агач материалына һәм башка алынган урман ресурсларына милекчелек хокукына ирешәләр.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 27 статьясы нигезендә чикләнергә мөмкин.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затларның хокуклары һәм бурычлары.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

- урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартлары нигезендә урманнардан файдаланырга;

- Россия Федерациясе Урман кодексының 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы (урман юллары, урман складлары һәм башкалар) булдырырга;

- бирелгән урман кишәрлекләрендә теплицалар, башка корылмалар һәм төзелмәләр урнаштырырга;

- Россия Федерациясе законнары таләпләренә каршы килмәсә, башка хокукларга ия булырга.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затларның бурычлары:

- урманнарны үзләштерү проектын төзергә;

- урманнарны үзләштерү проекты нигезендә урманнардан файдаланырга;

- урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын үтәргә;

- урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен туфрак эрозиясе булдырмаучы, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, шулай ук су объектларына һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтыны булдырмаучы яисә чикләүче алымнар белән урманнардан файдаланырга;

- урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен үтәргә;

- ел саен урман декларациясен тапшырырга;

- урманнардан файдалану турында хисап тапшырырга;

- урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшырырга;

- дәүләт урман рееестрына билгеләнгән тәртиптә документлаштырылагн мәгълүмат тапшырырга;

- Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән бурычларны үтәргә.

### Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалануга карата таләпләр

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен беренче чиратта урман фондының урманныкы булмаган җирләреннән, шулай ук урман утыртылмаган урман бүлемтекләреннән, ачыклыклардан һәм урман үсемлекләре каплап алмаган җирләрдән, урманнар урнашмаган бүтән категория җирләрдән файдаланырга мөмкин.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсентеләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары яисә алар булмаганда урман үсентеләренең нормаль орлыклары кулланыла.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсентеләренең районлаштырылмаган орлыкларын, шулай ук чәчү һәм башка сыйфатлары тикшерелмәгән урман үсентеләре орлыкларын куллану рөхсәт ителми.

Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр очрый торган урман кишәрлекләрен урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану РФ УКның 59 статьясы нигезендә тыела.

## 2.12. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану (РФ УК 43 ст.) урманчылыкның урман хуҗалыгы регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдаланганда урман фонды җирләрендә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясы нигезендә рөхсәт ителә. Урман инфраструктурасы булдыруга бәйсез объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла. Урманнар урнашкан башка категория җирләрдә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүгә бәйле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү башка федераль законнар белән билгеләнгән очракларда шушы җирләрнең максатчан билгеләнеше нигезендә рөхсәт ителә.

Барлык очракларда кебек үк урман инфраструктурасы булдыруга бәйсез объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү җирләрдән файдалану эшләре тәмамланганнан соң рекультивацияләнергә тиеш (РФ УК 21 ст. 6 өлеш).

Урман үсентеләрен кисү урманнардан файдалануның әлеге төренең бер өлеше булган очракларда җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен аренда шартнамәләре нигезендә урман кишәрлекләре бирелә (РФ УК 43 ст. 2 өлеш).

Мондый эшләрне башкару урман үсентеләрен кисүгә китерсә, капиталь төзелеш объектларын төзү өчен урманнар үз вәкаләтләре чикләрендә дәүләт

хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары рөхсәтләре буенча урман кишәрлекләре бирмичә генә файдаланыла (РФ УК 43 ст. 3 өлеш).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану өчен урман кишәрлеген арендалау шартнамәсе, аукцион уздыру таләп ителмәсә, ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә (РФ УК 72 ст. 3 өлеш һәм 74 ст. 3 өлеш).

Урман кишәрлекләре арендалауның күрсәтелгән сроклары җир асты байлыклары законнары таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

21.02.1992 № 2395-1 РФ Законының 10 статьясында билгеләнгәнчә, җир асты байлыклары кишәрлекләре файдалануга билгеле бер срокка бирелә:

- геологик өйрәнү өчен – 5 елга кадәр срокка;

- файдалы казылмалар чыгару өчен – файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү срогына, ул файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итә торган техник-икътисадый нигезләүдән чыгып исәпләнә;

- җир асты суларын чыгару өчен – 25 елга кадәр срокка;

- җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатканда җир асты байлыкларыннан кыска срокта файдалану хокукы бирү нигезендә файдалы казылмалар чыгару өчен – бер елга кадәр срокка.

Файдалы казылмалар ятмаларын эзләүләрне, бәяләүне һәм эшкәртүне тәмамлау яисә ликвидацион чаралар күрү кирәк булган очракта, әлеге җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан лицензия шартларын бозулар булмаганда, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы буенча туктатылырга мөмкин.

РФ УКның 20 статьясындагы 2 өлешендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдаланганда алынган урман материалына милекчелек хокукы урнаштырыла.

Җир асты байлыкларынан файданучылар агач материалы әзерләргә җыенган очракларда, аны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 23.07.2009 №604 карары белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерергә тиеш. Моның өчен урман кишәрлеге бер үк вакытта төрле максатларда файдалану өчен бирелергә мөмкин (РФ УК24 ст. 2 өлеш).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану тәртибе Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 27.12.2010 № 515 боерыгы белән расланган.

Әлеге норматив хокукый актта урман кишәрлеге бирмичә генә эшләр алып баруга рөхсәт бирү процедурасы билгеләнә.

Урман кишәрлеге бирмичә генә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен урман фонды җирләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучы (алга таба – Гариза бирүче) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына язма гариза бирә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

Гариза бирүче турында белешмәләр:

тулы һәм кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше, урнашкан җире, почта адресы, банк реквизитлары – юридик зат өчен;

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урынының адресы, шәхесен раслаучы документ белешмәләре, - индивидуаль эшкуар булган граждан өчен;

планлаштырыла торган эшләрне башкару өчен кирәкле урман фонды җирләренең урнашкан урыны һәм мәйданы, урманнардан файдалануны нигезләү һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару срогы.

Гаризага Гариза бирүче исеменнән эш йөртүче затның вәкаләтләрен раслаучы документ кушып бирелә (кирәк чакта).

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән түбәндәге документларны алалар:

юридик затка карата Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

физик затка карата Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

салым органында исәпкә алынуы турында белешмәләр;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиясе яисә дәүләт ихтыяҗлары өчен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен алып баруга дәүләт контракты булу турында белешмәләр.

Гариза 30 көн эчендә карала һәм әлеге эшләрне башкаруга рөхсәт бирү турында карар кабул ителә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану тәртибе белән җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү эшләрен башкаруга бәйле объектлар урнаштыру максатларында, иң беренче чиратта, урманныкы булмаган җирләр, урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган мәйданнарны файдалану карала. Әлеге максатлар өчен бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү эшләрен башкаруга бәйле объектлар урнаштыруның башка вариантлары булмаган очракта рөхсәт ителә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү эшләрен башкаруга бәйле объектлар урнаштыру бирелгән урман кишәрлеге һәм аның янәшәсендәге территориядә эрозия үсешен булдырмаска тиеш.

Тиешле объектларның саклау һәм санитар-яклау зоналарында урман үсентеләрен кисү урман кишәрлеген биргән дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары белән килештереп гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү эшләрен башкару максатларында урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми: агачларны аудару һәм урман кишәрлекләрен бульдозерлар ярдәмендә агач үсентеләреннән чистарту; чиктәш полосаларны һәм

урман авызларын агач материалы калдыклары белән чүпләү; урман авызы агачларының кәүсәләрен һәм үрелеп үскән тамырларын зарарлау, яңа киселгән агач материалын җәйге чорда махсус яклау чараларыннан башка саклау; урман үсентеләрен су бастыру һәм озак вакыт су астында тоту; урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач материаллары, көнкүреш һәм бүтән калдыклар белән чүпләндерү; урманнарны химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату; транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның юлларсыз, үзләре салган маршрутлар буенча узулары.

Яшел зоналарда һәм урман парклары зоналарында, шулай ук шәһәр урманнары территориясендә файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү тыела.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тәэмин итәләр:

- файдаланылучы урманнарны, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, чүпләрдән даими рәвештә чистартып торуны;

- житештерү эшчәнлеге барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, күперләрне, башка гидротехник корылмаларны, квартал баганаларын, квартал юлларын, аншлагларны, урманнар территориясен төзекләндерү элементларын торгызуны;

- әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калуны, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрүне;

- сейсмик разведка эшләрен планлаштыру һәм башкару максатларында, квартал юллары, урман юллары биләгән һәм урман үсентеләре белән капланмаган башка җирләрдән максималь рәвештә файдалануны, шул исәптән хәрәкәт составын һәм йөкләрне шуларда урнаштыруны.

## 2.13. Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану РФ УКның 44 статья нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлекләре сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен су законнары нигезендә файдаланыла.

Россия Федерациясе Су кодексының 1 статьясы су объекты дип табигый яисә ясалма сулыкны, су агып төшү урынын йә суларның даими яисә вакытлыча җыелып торулары су режимының характерлы рәвешләренә һәм сыйфатларына ия булган бүтән су объектын аңларга тәкъдим итә.

Россия Федерациясе Су кодексының 5 статьясы ясалма су объектлары дип, аерым алганда, сусаклагычларны, буаларны һәм каналларны игълан итә.

Урман хуҗалыгында сусаклагычлар һәм буалар асылда кече һәм уртача елгаларда, шулай ук инешләрнең урман үткәрүчәнлеген көчәйтү өчен, урман әзерләүне һәм бүтән җитештерүне су белән тәэмин итү өчен инешләрдә корыла һәм файдаланыла.

Урман хуҗалыгында каналлар асылда киптерү, сугару һәм суландыру максатларында корыла һәм файдаланыла. Аерым очракларда урман агыза торган каналлар да корылырга һәм файдаланылылырга мөмкин.

Мондый максатлар өчен гидротехник корылмалар корыла һәм файдаланыла, аларга "Гидротехник корылмаларның иминлеге турында" 21.07.1997 № 117-ФЗ Федераль законның 3 статьясы нигезендә плотиналар, гидроэлектростанцияләр бинаалары, су җыю, су җибәрү һәм су чыгару корылмалары, туннельләр, каналлар, насос станцияләре, суднолар йөрү шлюзлары, суднолар күтәргечләр; су басулардан саклагычлар һәм сусаклагычлар ярлары, елгалар ярлары һәм үзәннәре төпләре җимерелүдән яклау өчен билгеләнгән корылмалар; сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы оешмаларының сыек калдыкларыннан саклану өчен корылган корылмалар (дамбалар); каналларда су ишмәсен өчен билгеләнгән җайланмалар, шулай ук су ресурсларын файдалану һәм суларның һәм сыек калдыкларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу өчен билгеләнгән башка корылмалар кертелә.

РФ УК шулай ук махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалануны күз алдында тота.

РФ Сәүдә өчен диңгездә йөзү кодексының 9 статьясыннан чыгып, анда махсуслаштырылган диңгез портларына билгеләмә бирелә, РФ УКның 44 статьясында күрсәтелгән махсуслаштырылган портлар дигәндә махсус бирелгән территориядә һәм акваториядә урнашкан һәм урман ресурсларын һәм урман хуҗалыгы һәм урман сәнәгате өчен кирәкле бүтән йөкләрне ташучы судноларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән корылмаларны аңларга кирәк.

Сусаклагычлар, бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар, махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану РФ УКның 21 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла яисә әлеге файдалану төре урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзүгә, реконструкцияләүгә һәм эксплуатацияләүгә бәйле булмау мөмкинлеге күрсәтелә.

РФ УКның 21 статьясы 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгәнчә, урман фонды җирләрендә, шулай ук урманнар урнашкан башка категория җирләрдә сусаклагычлардан һәм бүтән ясалма су объектларыннан, шулай ук гидротехник корылмалардан һәм махсуслаштырылган портлардан файдалану өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителә.

| 1.3 | Урманнарның фактта яну чоры (янгын куркынычы тудыручы һава торышы чоры) | Һава торышы буенча янгын куркынычының 2 - 5 класслары көннәре |
| 1.4 | Конкрет урманчылык буенча янгын куркынычы сезонының факттагы озынлыгын билгеләү (урманчылык буенча урман кишәрлеге) | Кар катламы кузгалу һәм барлыкка килү. 10 ел һәм аннан да күбрәк еллар эчендә урманнарның фактта яну чорының максималь һәм уртача чоры озынлыгы. Җирле шкалалар буенча һава торышының янгын куркынычы дәрәҗәсе – һава торышының 2 класслы янгын куркынычы башлану һәм бетүнең иң соңгы һәм уртача даталары |
| 1.5 | Урманнарның чагыштырмача янучанлыклары | Янгыннарның уртача еллык мәйданын урман фонды мәйданына бүлүдән килеп чыккан зурлык |
| 1.6 | Урман янгыннары күләмнәре:<br>- эре<br><br>- исәпкә алына торган | Мәйданы 25 гектардан артык<br><br>Теләсә нинди мәйданда урман фонды территориясе янып китү |
| 1.7 | Янгын интенсивлыгы<br>- түбән | Ялкын биеклеге 0.5 м һәм аннан ким |

| № т/с | Күрсәткечләр | Нормативлар |
|---|---|---|
| | - уртача<br>- югары | Ялкын биеклеге -.6 - 1.0 м<br>1.0 метрдан артык |
| **2.** | **Җир өсте сагы районнарында урманнарны янгынга каршы планлаштыру нормативлары:** | |
| 2.1 | Ылыслы токымнарның янгын куркынычы булган эре массивларын планлаштыру | 2 гектардан алып 12 мең гектарга кадәр мәйданда өске һәм аскы янгыннар таралуга каршы торырлык (янгын куркынычы дәрәҗәсенә һәм урман хуҗалыгы интенсивлыгына бәйле рәвештә) янгынга каршы табигый яисә ясалма барьерлар яисә аермалар белән, шулай ук гамәлдәге янгыннарны локальләштергәндә таяныч линияләре белән эре йомык блокларга бүлү. Аларда гомуми юллар челтәренә кирәрлек юллар салалар. |
| 2.2 | Урман массивлары территориясендә янгынга каршы табигый барьерлар сайлау | Су баса торган киң тугайлары булган күлләр һәм елгалар, яфраклылар өстенлек иткән урман кишәрлекләре (составы буенча кимендә 7 берәмлек), урманнар һәм янучан материаллар капламаган кишәрлекләр |
| 2.3 | Янгынга каршы ясалма барьерлар һәм аермалар сайлап алу | Тимер юллар һәм автомобиль юллары трассалары, электрүткәргеч линияләре, торбаүткәргечләр һәм башкалар, аларның ике ягы буйлап мөмкин булганда 50-60 м киңлектәге яфраклылар полосалары булдыралар. Барьерның гомуми киңлеге -120-150 м. Яфраклылар полосаларының урманга караган тышкы яклары буйлап 1,4 м киңлектәге минполосалар булдырыла, яфраклылар полосалары янгын куркынычының 1 һәм 2 классларына кертелгән очракларда, - бер-береннән 5-10 м ераклыкта торган ике минполоса ясала. Яфраклылар полосалары булдыру мөмкин булмаган ылыслы урман үсентеләре территориясе (урман бүлемтеге сәбәпле) чокырның һәр ягыннан киңлеге 120-150 м булган полосаларда янучан материаллардан (агач материалы чүбеннән, ылыслы шытымнардан, янгын куркынычы булган урманчыклардан, ылыслыларның 1,5-2,0 метрга кадәрле аскы ботакларыннан һәм башкалардан) даими рәвештә чистартылып торыла. Мондый полосалар ылыслы урманны янәшәдәге урманнан чиклиләр һәм 20-30 м саен һәр 1.4 м киңлектәге минполосалар белән буйга бүленә. Мондый каршылыкларның киңлеге (аерма яисә юл киңлеге белән бергә) -260-320 м. |
| 2.4 | Янгынга каршы өстәмә барьерлар һәм аермалар булдыру | 2.2 һәм 2.3 пунктларда күрсәтелгән барьерлар йомык боҗра булдыру өчен җитәрлек булмаган очракта, блок тирәли юллары һәм ике яклап яфраклы полосалары булган ясалма аермалар казыйлар |

| № т/с | Күрсәткечләр | Нормативлар |
|---|---|---|
| 2.5 | Уртача интенсивлыктагы урман хуҗалыгы алып барыла торган зоналарда урнашкан, янып китүчәнлеге югары булган ылыслыларның кыйммәтле токымнары массивларында планлаштыру | 2-12 мең га (2.1 п.) кадәр мәйданлы эре блоклар һәм массивлар барьерлар (чокырлар, уттан каршылыклар) 2.2-2.4 пунктларда каралган тәртиптә 400дән 1600 га кадәр мәйданлы уртача йомык блокларга бүләләр. Киң кулланудагы юлларның (тимер, шоссе) ике ягында да (шуларның хуҗалары көчләре белән) 30-50 м киңлектәге яфраклылар полосалары булдырыла, ә башка аермалар буйлап, шул исәптән квартал юллары буйлап һәр ягында - 10-15 м киңлектәге. Аеруча кыйммәтле массивларда (яфраклылар полосалары булдыру мөмкин булмаганда) һәр ягыннан 100 м киңлектәге полосаларда ылыслылар чокыры янәшәсендә янучан материаллардан чистарту уздырыла һәм 2.3 пунктта күрсәтелгәнчә 20-30 м саен аркылы миниполосалар салына. Мондый яфраклылардан торган эчке (өстәмә) каршылыклар киңлеге 60-100 м булырга тиеш, ылыслы токымнардан - 200 м, урман юллары буйларында - 20-30 м (чокырларның һәм урман юлларының киңлеген исәпкә алмыйча) |
| 2.6 | Яшел зоналарда һәм 1 класслы ылыслы культураларның һәм яшь урман үсентеләренең эре кишәрлекләрен планлашлыктыру | Аларны 25га мәйданлы блокларга минполосалар яисә юллар ярдәмендә бүләләр, аларда яфраклы яшь агачлардан һәм куаклардан ике яклап 10 м киңлектәге полосалар булдыралар. Гади юл белән бүлүнең киңлеге аның үзәге буенча – 30 м. Яфраклылар полосаларын булдыру мөмкин булмаганда, 100 м киңлектәге полосалардагы ылыслылар чокырына якын урыннарда һәрьяклап янучан материалны юк итәргә, шулай ук 20-30 м саен аркылы минполосалар салырга кирәк (2.3 п.). |
| 2.7 | Поселоклар янәшәсендәге ылыслы урманнарны планлаштыру | Урман массивы тирәли киңлеге кимендә 150 м булган янгынга чыдам яфраклылардан торган урман авызлары булдырыла. Мондый урман авызларының ике чиге буйлап киңлеге кимендә 2,5 м булган минполосалар салына. Әгәр яфраклылардан торган урман авызларын булдыру мөмкин булмаса, поселок янәшәсендәге ылыслы урман полосаларында 250-300 м киңлектә янучан материалларны тулысынча җыеп алалар һәм 50 м саен аркылы миниполосалар салалар (2.3 п.) |
| 2.8. | Яклаучы миниполосаларны бульдозерлар, тракторлар, туфрак эшкәртүче һәм башка кораллар ярдәмендә туфрак өстендәге каплам төренә һәм куәтенә бәйле рәвештә салганда: | |

| № т/с | Күрсәткечләр | Нормативлар | |
|---|---|---|---|
| | - лишайниклардан һәм яшел мүкләрдән<br>- җиләкләрдән һәм арчаннан<br>- куе үлән капламы булганда һәм минималь киңлектәге чүпләнгән кишәрлекләрдә<br>- блоклар һәм ылыслы массивлар эчендә<br>(2.1, 2.5 - 2.7 пунктлар) | 1.0 дан 1.5 метрга кадәр<br>1.5 дан 2.5 метрга кадәр<br>2.5 дан 4.0 метрга кадәр<br><br>1.4 м (ПКЛ-70 сукасы бер уза)<br>Корылмалар, урман культуралары, табигый шытып чыккан урманнар биләгән мәйданнар тирәсендә, ылыслы, яфраклы урман үсентеләрендә уза торган агач ташу юллары буйларында, миниполосалар дәвамы буларак, булдырылган янгынга каршы барьерларда һәм ылыслы урман үсентеләрендә, шулай ук кирәк булган башка урыннарда | Полоса киңлеге мөмкин булган аскы янгын биеклегеннән ике мәртәбә артык киңлектәге каршылык хезмәтен генә үтәргә мөмкин |
| | - янгын куркынычы булган сезонга калдырылган коры туфракларда урнашкан ылыслы тигез урманнардагы коры туфраклы урман бүлемтекләрендә | Урман әзерләүчеләр урман бүлемтекләрен минполосалар белән әйләндереп алалар. Моннан тыш, 25 гектардан артык мәйданлы урман бүлемтекләре аркылы полосалар белән 25 гектардан артмаган кишәрлекләргә бүленәләр. Агач материалын складлаштыру урыннары шулай ук аерым, йомык миниполосалар белән әйләндереп алына, ә ылыслы урманнарны кисү урыннарында – бер-береннән 5-10 м ераклыкта булган ике шундый полоса белән әйләндереп алына | |
| | - тимер юлларда, шосселарда һәм агач ташу юлларында (үз карамакларындагы оешмалар көчләре белән) | Алар буйларындагы полосаларны (агач ташу өчен – һәр ягыннан 10 м) янгын сезоны эчендә ауган агачлардан, агач чүпләреннән һәм башка тиз кабынып китүчән материаллардан чистартып торыла. Минполосаларны бүлү полосаларының тышкы ягына салалар, коры туфрактагы ылыслы урман үсентеләрендә – бер-береннән 5 м ераклыктагы ике минполоса. Бу шартларда минполосалар белән юл буйларында яткан шпаллар өемнәрен һәм кар саклау щитларын, агач күперләрне, стационар платформаларны, торак йортларны һәм юлларны карап йөрүчеләр будкаларын әйләндереп алалар, учак ягу рөхсәт ителгән урыннар, урманда ял итү һәм тәмәке тарту урыннары, урманнарда эшләр башкарганда ЯММ саклау урыннары тирәли, янгын куркынычы урман промыселлары мәйданчыклары тирәли (күмер ягу, сагыз, дегет эшкәртү һәм башкалар), арадаш һәм төп чәер складлары тирәли, авыл хуҗалыгы җирләре чикләре буйлап әйләндереп алалар | |
| 2.9 | Янгын куркынычы сезонында янгынга каршы аермалар кору: | | |
| | - урманда агач материалы складлары тирәли | Складларны ачык урыннарда түбәндәге аралыкта урнаштыралар: яфраклы урман диварларыннан складлаштыру урыннары мәйданы 8 га - 20 м кадәр, 8 га һәм аннан да күбрәк - 30 м, ылыслы һәм катнаш урман диварларыннан складлаштыру урыннары мәйданы 8 га - 40 м, 8 га аннан да күбрәк - 60 м. | |

<table>
<tr><th>№ т/с</th><th>Күрсәткечләр</th><th colspan="2">Нормативлар</th></tr>
<tr><td></td><td></td><td colspan="2">Складлаштыру урыннары һәм күрсәтелгән янгынга каршы аермалар янучан материаллардан чистартыла</td></tr>
<tr><td></td><td>- торф чыгаручы предприя-тиеләр тирәли</td><td colspan="2">Чокырның эчке ягы буйлап су үткәргеч йомык каналы булган, 75 -100 м киңлектәге аермалар белән шундагы урман массивларын аералар. Аерма полосасында нарат урманын, шулай ук 8 м биеклектәге яфраклы агачларны кисәләр һәм янучан материалны җыеп алалар</td></tr>
<tr><td>2.10</td><td colspan="3">Янгынга каршы сулыклар кору: урман янгыннары чыгу мөмкин булган урыннан ерак урнашкан су чыганакларын урнаштыру :</td></tr>
<tr><td></td><td>Урман үсентеләренең янгын куркынычы классы</td><td>Ара, км</td><td>Бер сулыктан тәэмин ителә торган урман үсентеләре мәйданы, га</td></tr>
<tr><td></td><td>1</td><td>2 - 4</td><td>500</td></tr>
<tr><td></td><td>2</td><td>2 - 8</td><td>2000 - 5000</td></tr>
<tr><td></td><td>3 - 5</td><td>8 - 12</td><td>5000 - 10 000</td></tr>
<tr><td></td><td>- янгын сүндерү өчен табигый су чыганакларын әзерләү</td><td colspan="2">Аларга килү юлларын төзекләндерү, янгын автоцистерналары һәм мотопомпалар белән су алу өчен махсус мәйданчыклар җиһазландыру, ә кирәк очракларда сулыкларны тирәнәйтү һәм буалау</td></tr>
<tr><td></td><td>- ясалма янгын сүндерү сулыклары төзү</td><td colspan="2">"Росгипролес" институтының типовой проектлары буенча, янгын куркынычы югары булган урман массивларында аларда табигый су чыганаклары булмаганда, яхшыртылган автомобиль юллары янында, алардан сулыкларга кадәр килү юллары салынган булырга тиеш</td></tr>
<tr><td></td><td>- янгынга каршы сулыкта эффектив су запасы</td><td colspan="2">Кимендә 100 $м^3$ елның иң эссе чорында</td></tr>
<tr><td>2.11</td><td>Урман юлларын кору:</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td></td><td>- юллар челтәренең гомуми тыгызлыгы (куелыгы)</td><td colspan="2">Кимендә 6 км - 1000 га гомуми мәйданга, шул исәптән янгын куркынычы түбән булган һәм янгын тиз таралмый торган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда юллар челтәре куелыгы 6 км/мең га рөхсәт ителә, янгын куркынычы югары булган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда ул бу күрсәткечтән артык булырга тиеш</td></tr>
<tr><td></td><td>- урман хуҗалыгы юллары</td><td colspan="2">Урман янгыннары белән көрәш өчен түгел, урман хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен кирәкле юллары булган кишәрлекләрдә урман хуҗалыгы интенсив алып барыла торган үзләштерелгән урманнарда корыла.<br>5 категория гомуми файдаланудагы юлларга тиңләштерелә һәм 3 типка бүленә.<br>1 тип урман хуҗалыгы юллары: бер полосалы, полосаларның гомуми киңлеге - 8 м, юл кырые киңлеге – 1,75 м.<br>Исәпләп чыгарылган хәрәкәт тизлеге - 60 км/сәг, сикәлтәле урыннарда 40 км/сәг кадәр кими</td></tr>
</table>

| № т/с | Күрсәткечләр | Нормативлар |
|---|---|---|
| | - янгынга каршы юллар | 3 тип урман хуҗалыгы юлларына, җир полотносы киңлеге 4,5 м тигез, юл кырыйлары киңлеге - 0,5 м. Янгын куркынычы булган кишәрлекләренә һәм сулыкларга килү урыннарын тәэмин итә торган урман юллары челтәренә өстәмә итеп коралар. Аларга шулай ук табигый грунт юллары, квартал урман юллары һәм төрле трассалар кертелә |
| 2.12 | Көчләрне һәм чараларны янгын сүндерү урынына илтеп җиткерү вакыты | Янгын күренгәннән соң 3 сәгатьтән дә артмаска тиеш. Янгын куркынычы югары булган кишәрлекләр өчен А - 0,5 – 1,0 сәгатьтән дә артмаска тиеш |
| 2.13 | Янгын урынына бару юлына китә торган вакытны исәпләп чыгарганда юлларның, сукмакларның яисә җәяүлеләр узып йөрерлек урыннарның сикәлтәлеген һәм җир өсте рельефын исәпкә алу өчен аларны озынайту коэффициентлары | |
| | - 1 тип урман хуҗалыгы юллары өчен<br>- 3 тип урман хуҗалыгы юллары өчен (янгынга каршы) | Тигез урында – 1,1; калкулыклы урында – 1,25<br>Тигез урында – 1,15; калкулыклы урында – 1,65 |
| 2.14 | Янгын сүндерүче хәрәкәте тизлеге | Гадәттә 1 - 3 км/сәг (автомобиль юлыннан коралларын күтәреп янгын урынына килгәндә) |
| 2.15 | Җир өстендә патруль уздыру маршрутларын планлаштыру нормативлары: | |
| 2.15.1 | Урнашу урыннары | Агач-куаклар аз булган урыннарда (15% һәм аннан да түбән) һәм территория буйлап вак урман кишәрлекләре тигез урнашканда. Кыр саклау урман үсентеләрен, чокырлар һәм балкалар буйлап үсентеләрне саклаганда яшел зоналар урманнарында, урман паркларында һәм башкаларда. Стационар күзәтү пунктларыннан күзәтүгә һәм авиапатрульгә өстәмә рәвештә – агач материалы әзерләү урыннарында, төрле объектлар төзү урыннарында һәм трассаларда, ял зоналарында, елгалар һәм күлләр ярлары буйлап, янгын куркынычы югары булган урыннарда |
| 2.15.2 | Патруль уздыру маршруты озынлыгы | Транспорт төренә, юллар торышына һәм саклана торган кишәрлекне карап чыгу санына бәйле рәвештә |
| 2.15.3 | Янгын куркынычы булган кишәрлекләрдә урман янгынына патруль уздыру хәрәкәте тизлеге | |
| | - мотоцикллар, машиналар һәм башка транспорт чаралары | Гомуми файдаланудагы шоссей юллары буйлап - 30 км/сәг артык, урман юллары буйлап -15-20 км/сәг. Урмансыз киңлекләрдә юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләре нигезендә арттырылырга да мөмкин |
| | - моторлы көймәләрдә һәм катерларда | Су юллары буйлап - 15 - 20 км/сәг чикләрендә |
| 2.16 | Урман янгыннары чыгуны күзәтү өчен пунктларда урнашу нормативлары: | |
| 2.16.1 | Күзәтүнең максималь радиусы (бик әйбәт күреп булганда) вышкаларның әйләнә-тирәдә белән чагыштырганда биеклегенә карап:<br>- вышкалар биеклеге, м | 10 15 20 25 30 35 40<br>12 15 17 19 21 23 24 |

| №<br>т/с | Күрсәткечләр | Нормативлар |
|---|---|---|
| | - күзәтү радиусы, км | |
| 2.16.2 | Вышкаларны оптималь урнаштыру | Калку урыннарда – бер-береннән 10-12 км ераклыкта, ә тигез урыннарда - 5-7 км. 2-3 пункттан янгын урынын төгәл билгеләү исәбеннән алар чыгарга мөмкин районда почмак үлчәү инструменты (буссоли һәм башкалар) һәм бинокль ярдәмендә билгеләү методы белән. ПТУ-59 телевизион җайланмасының күзәтү радиусы 8 км га кадәр (күзәтүче өскә менмичә). Видеоконтроль җайланмасы һәм идарә пульты мачтадан 1 км ераклыкта теләсә нинди ябык бинада урнаштырыла, кабель озынлыгы 1 дән 3 км кадәр булганда линия көчәйткечләрен тоташтырырга кирәк |
| 2.16.3 | Допустимое размещение вышек (при недостатке средств) | 10-12 км ераклыкта 35 м биеклектәге типовой метал вышка һава торышы начар булган шартларда күрү җитәрлек итеп урнаштырыла, яхшы һава торышы булганда бу ара 20 км кадәр. Шуңа күрә икеләтелгән araларда минималь дәрәҗәдә күрерлек итеп (20-24 км) урнаштырыла. ПТУ-59 телевизион җайланмасының күзәтү радиусы 10-15 км кадәр |
| 2.16.4 | Күзәтү вышкаларының хезмәт итү срогы:<br>- агач - 10 ел<br>- метал - 30 ел | Вышкаларның хакы бертөрле диярлек |
| 2.17 | Янгын - химия станцияләрен планлаштыру һәм урнаштыру нормативлары: | |
| 2.17.1 | ЯХХ оештыруның максатка ярашлылыгы күрсәткечләре (урманнарны янгынга каршы кору планнары нигезендә) | Беренче чиратта беренче өч класслы янгын куркынычы булган кыйммәтле урманнарга һәм урман фондының һәр 1000 гектарына кимендә 6 км ераклыкта юллар челтәренә һәм сулыкларга ия урман хуҗалыкларында |
| 2.17.2 | Һәр ЯХХ тирәли беркетелә торган урман территориясе радиусы:<br>- юллар челтәре әйбәт булганда<br>- канәгатьләнерлек булганда<br>- сыйфатсыз булганда | 40 км артык түгел<br>30 км артык түгел<br>20 км артык түгел |

| № т/с | Күрсәткечләр | Нормативлар |
|---|---|---|
| 2.17.3 | ЯХХ урнаштыру урынын сайлап алу | Аеруча янгын куркынычы булган һәм янучан урман кишәрлекләренә мөмкин кадәр якын, беркетелә торган территория үзәгендә, урман хуҗалыгы (урманчылык) конторасыннан, агач материалы цехларыннан, аскы складлардан һәм эшләүчеләре күп булган башка бүлекчәләрдән, төп транспорт юлларыннан, сулыклардан ерак түгел. Берничә варианттан әлеге шартларда иң мөһим таләпләргә туры килә торган оптималь вариантын сайлап алалар. Техника һәм ЯХХ урман янгыннары бригадалары гадәттә бер пунктта туплана, әмма ЯХХ бүлекчәсе кирәк булганда ике һәм аннан да күбрәк пунктларда урнашырга мөмкин (ерак урнашкан зур булмаган урманчылыкларда яисә аерым ЯХХ оештыру максатка ярашсыз булган урыннарда) |
| **3.** | **Урманнарга янгыннарга карата авиапатруль уздырганда эшләрне планлаштыру нормативлары** | |
| 3.1 | Урында маршрутлар линияләрен урнаштыру:<br>- авиапатруль уздырганда | Бер-беренә парралель рәвештә һәм хезмәт күрсәтелә торган кишәрлекнең озын ягы белән<br>Бер-береннән 60 км ераклыкта, хезмәт күрсәтелә торган кишәрлек чигенә кадәр маршрут - 30 км артык түгел |
| 3.2 | Очыш биеклеге:<br>- урманнарда янгыннарга карата авиапатруль уздырганда | Оптималь - 600 м. Һәр аерым очракта куелган бурыч характеры, җирле очу шартлары, аппаратның техник характеристикалары, аңарда герметик кабина булу белән билгеләнә (АН-24 самолетында - 7000 м кадәр) |
| | - авиапатрульне урманнарның гомуми санитар хәлен күзәтү белән бергә алып барганда | Урманнарның аерым кишәрлекләрен җентекләп карап чыгу өчен самолетларда очу 200 метрга кадәр һәм вертолетларда 100 метрга кадәр түбәнәя (урынның рельефын һәм андагы калку элементлар булуга карап) |
| 3.3 | Авиапатруль уздырганда янгын урынын билгеләү төгәллеген бәяләү: | |
| | - бик яхшы<br>- яхшы<br>- канәгатьләнерлек<br>- канәгатьләнерлек түгел | Ялгышмыйча<br>0,5 км кадәр ялгышып<br>0,5 км дән 1,0 км кадәр ялгышып<br>1 км артык ялгышып |
| 3.4 | Биклектән янгын мәйданын билгеләү төгәллеге | Ялгышу 30% чамасы рөхсәт ителә |
| 3.5 | Парашютист янгын сүндерүчеләр төшү кишәрлекләренә һәм урыннарына таләпләр: | |
| | - очыш биеклеге<br>- җиргә якын җил тизлеге<br>- төшү өчен ачык мәйданчыклар күләмнәре<br>- сикерү тыела | 800 метрдан түбән түгел (парашют тибына карап)<br>8 м/с артык түгел<br>75 х 75 м ким түгел (урман ачыклыклары, кипкән сазлыклар, кырлар һәм башкалар, алар булмаганда- куаклыклар һәм 20 метрга кадәр биеклектәге агачлар<br>Киселгән урыннарда, янгыннан соң калган урыннарда, кипкән урман үсентеләрендә, җил аударган урыннарда, шулай ук югары вольтлы линияләргә якын җирдә |
| 3.6 | | |

| № т/с | Күрсәткечләр | Нормативлар |
|---|---|---|
| | Авиация сагында торган урманнар территориясендә урман хуҗалыклары тарафыннан башкарыла торган эш урыннарын һәм кишәрлекләрен планлаштыру нормативлары: | |
| 3.6.1 | Авиахәбәрләрне кабул итү пунктларын оештыру :<br>- урнашу урыны | Урманчылыклар, ЯХХ участок урманчылыклары конторалары, авыл, колхоз, совхоз администрацияләре белән янәшә, урман сакчылары яшәгән урыннарда, телефоны һәм радиоэлемтәсе булган торак пунктларда |
| | - аларны җиһазлау патруль самолетлар (вертолетлар) өчен тану тамгасы булып тора | Кизү оештырылган йортларның ике ягында ак майлы буяу яисә известь белән гарәп цифрлары кулланып пунктның номеры языла. Цифрларны шулай ук ышкылаган агачтан ясап куеп була.<br>Цифрлар зурлыгы: биеклеге -2,5-3,0 м, киңлеге -0,75 м |
| 3.6.2 | Патруль самолетлар һәм вертолетлар ориентировкасы өчен яхшы шартлар тудыру максатларында өстәмә ясалма ориентирлар кору: | |
| | - ориентирлар типлары һәм аларны урнаштыру урыны | Урман территориясендәге корылмалар (кордоннар, аучы йортлары, бараклар һәм башкалар. Алар булмаган очракта ачык кишәрлекләрдә (кимендә 100х100 м) җир өстендә казып утыртылган таяклардан (казып утыртылмаган каен таякларыннан) шалашлар, түбәләр яисә 7 м биеклектә ак флагы булган баганалар утырталар. |
| | - аларны тану тамгасы белән тәэмин итү | Корылмалар яисә шалашлар түбәләренең ике ягында да бөтен буена квартал номеры сугыла (патруль картасының). Тамганың биеклеге - кимендә 3 м, киңлеге - кимендә 0,75 м |
| 3.6.3. | Вертолетлар эшләгән районнарда төшү мәйданчыкларын сайлап алу һәм төзекләндерү: | |
| | - билгеләнеше<br><br>- урнашу урыны | Ягулык салу пунктлары, янгын сүндерү көчләрен һәм чараларын алу һәм төшерү, хәбәрләрне кабул итү һәм башкалар.<br>Янгыннар еш чыга торган яисә янгын куркынычы югары булган урман массивларында |
| | - вертолетлар очып китү һәм утыру мәйданчыкларының минималь күләмнәре (килүләрне исәпкә алу) | Вертолетлар типлары — Тигез урын, м<br>МИ - 6 — 50 х 50<br>МИ - 8 — 30 х 30<br>МИ - 4 — 30 х 30<br>МИ - 2 — 16 х 16<br>МИ - 1А — 16 х 16 |
| | - очып китү һәм утыру юнәлешендә каршылыклар урнаштыру (шулар өчен кишәрлекләр) | Барлык каршылыклар мәйданчык чигеннән үзенең икеләтелгән биеклеге күләмендә ераклашкан булырга тиеш |
| | - 0,5 метрлан артык биеклектә каршылыклар урнаштыру ( МИ-2, МИ-1А, Ка-26 өчен) 1 метрдан да күбрәк (МИ-6, МИ - 8, Ми – 4 өчен) | Мәйданчык чигеннән 10 метрдан да якынрак түгел |

2.17.1.6 нче таблица

Урман хуҗалыгы алып баручы урман фондын биләүчеләрне урман янгыннарын сүндерү җайланмалары һәм чаралары белән тәэмин итү нормалары

| № т/с | Янгын сүндерү чараларының исеме | Үлчәү берәмлеге | Урманчылык | Бер участок урманчылыгында агач материалы әзерләүче структур бүлекчәнең урман янгыны пункты (ПСПИ) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Урман янгынының модуль җайланмасы (салдырыла торган цистерналар, шул исәптән үзләре җитештергән) яисә 1500 литр су сыешлы резина мичкәләр | данә | 1 | 1 | янгынга каршы махсус автоцистерна-ларга салдырыла торган цистерналар булдыру мәҗбүри түгел |
| 2 | Янгынга каршы урман патруле машиналары | данә | 1 | 1 | комплектта |
| 3 | 600-800 л/мин җитештерүчәнлеге булган янгынга каршы күчерелмә мотопомпалар | данә | 1 | 1 | |
| 4 | Су куа торган җиңсәләр (Д=26,51, 66 мм) | п.м | 300 | 300 | |
| 5 | Торф урман янгыннары баганалары | к-т | 1 | | торф ятмалары булган урман кишәрлекләре өчен генә |
| 6 | 100 ат көченнән дә күбрәк тракторлардагы бульдозерлар | данә | 1 | | |

| № т/с | Янгын сүндерү чараларының исеме | Үлчәү берәм-леге | Ур-ман-чы-лык | Бер участок урманчылыгын-да агач материалы әзерләүче структур бүлекчәнең урман янгыны пункты (ПСПИ) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 7 | Сукалы яисә туфрак эшкәртә торган башка җайланмасы булган тракторлар | данә | 1 | | |
| 8 | Кыен җирләрдән үтеп йөри ала торган автомобильләр яисә вездеходлар | данә | 1 | | кешеләр йөртү өчен |
| 9 | Елга катерлары, йөк сыйдырышлылыгы кимендә 2 т | данә | 1 | | су юллары булган районнар өчен генә |
| 10 | Кабызгычлы аппаратлар | данә | 5 | 4 | |
| 11 | Юешләткечләр, күбек барлыкка китерүчеләр | кг | | 20 | |
| 12 | Ранецлы ут сүндергечләр | данә | 10 | 2 | |
| 13 | Һава өрүчеләр | данә | 1 | 1 | |
| 14 | Кул инструментлары:<br>көрәкләр<br>балталар<br>китмәннәр<br>тырмалар<br>аркылы пычкылар | <br>данә<br>данә<br>данә<br>данә<br>данә | <br>30<br>10<br>10<br>10<br>3 | <br>50<br>5<br>5<br>5<br>5 | |
| 15 | Эчәр сулар өчен билгеләнгән 20 литрлы чиләкләр һәм бүтән канистрлар | данә | 5 | 2 | |

| № т/с | Янгын сүндерү чараларының исеме | Үлчәү берәм-леге | Урман-чы-лык | Бер участок урманчылыгын-да агач материалы әзерләүче структур бүлекчәнең урман янгыны пункты (ПСПИ) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 16 | Эчәр сулар өчен билгеләнгән 20 литрлы бидоннар яисә канистрлар | данә | 2 | 2 | |
| 17 | Бензопычкылар | данә | 2 | 1 | |
| 18 | Электромегафоннар | данә | 1 | | |
| 19 | УКВ- яисә КВ-диапазонындагы радиостанцияләр, үзең белән йөртелә торган | данә | 2 | 2 | янгын хезмәте белән урманчылык арасында оешкан радиоэлемтә булганда |
| 20 | Кизү өчен махсус кием-салым (кирза итәкләр, чалбарлар, курткалар, бияләйләр) | к-т | | | янгын сүндерүнең даими командасы әгъзалары санынча |
| 21 | Беренче ярдәм аптечкасы | к-т | 2 | 1 | |
| 22 | Индивидуаль яра бәйләү пакетлары Яклаучы күзлекләр | к-т | | | янгын сүндерүдә катнашучылар санынча |
| 23 | Яклаучы күзлекләр | данә | | | янгын сүндерүнең даими командасы әгъзалары санынча |
| 24 | Респираторлар | данә | | | янгын сүндерүнең |

| № т/с | Янгын сүндерү чараларының исеме | Үлчәү берәмлеге | Урманчылык | Бер участок урманчылыгында агач материалы әзерләүче структур бүлекчәнең урман янгыны пункты (ПСПИ) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | даими командасы әгъзалары санынча |
| 25 | Су өчен кружкалар | данә | | | янгын сүндерүдә катнашучылар санынча |

2.17.2. Урманнарны зарарлы организмнардан яклауга карата таләпләр

Урманнарны зарарлы организмнардан яклау Россия Федерациясе Урман кодексының 54-56 статьялары һәм "Үсемлекләрнең карантины турында" 15.07.2000 № 99-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29.06.2007 № 414 карары белән расланган Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре (алга таба – Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны яклау зарарлы организмнарны (үсемлекләрне, хайваннарны, билгеле бер шартларда урманнарга һәм урман ресурсларына зарар китерерлек авыру кузгатучы организмнарны) ачыклауга һәм алар таралуны булдырмауга юнәлдерерлә, карантин объектларга кертелгән зарарлы организмнар чыганаклары барлыкка килгән очракта, аларны локальләштерүгә һәм бетерүгә.

Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре урманнарны зарарлы организмнардан, шулай ук зарарлы йогынтыдан яклауның бердәм тәртибен һәм шартларын, шулай ук урманнарда санитар иминлек тәэмин итүгә юнәлдерелгән урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен билгели.

Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре һәр урман районы өчен Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Урманнарда санитар иминлекне тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) урманнарны яклау ягыннан районлаштыру (урман патологиясе яный торган зәгыйфь, уртача һәм көчле зоналарны билгеләү);

б) урман патологиясе ягыннан тикшерү һәм урман патологиясе ягыннан мониторинг;

в) зарарлы организмнар чыганакларын локальләштерү һәм бетерү буенча авиация һәм җир өсте эшләре;

г) санитар-савыктыру чаралары (корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү, урманнарны чүптән, пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан яклау);

д) урманнардан файдалануга карата санитар таләпләр урнаштыру.

Арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә санитар-савыктыру чаралары шушы кишәрлекләрнең арендаторлары тарафыннан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләр урманнарны үзләштерүне планлаштырганда исәпкә алына.

Урманнарда санитар иминлекне тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда алынган документлаштырылган мәгълүмат дәүләт урман реестрына кертү өчен билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

Урман патологиясе ягыннан тикшерү һәм урман патологиясе ягыннан мониторинг, зарарлы организмнар чыганакларын локальләштерү һәм бетерү, санитар-савыктыру чараларын билгеләү һәм уздыру эшләре Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы тарафыннан расланган методик документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.17.2.1 нче таблица

Урманнарны яклау чараларының еллык күләме

| № т/с | Чаралар исеме | Үлчәү берәмлеге | Проект-ланган | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Урман патологиясе ягыннан тикшерү | га | 4000 | |
| 2. | Туфракта казулар | чокыр | | |
| 3. | Яңа гына зарарланган агачларны сайлап алу (ау агачлары) | $м^3$ | | |
| 4. | Питомникларга профилактик яктан агу сиптерүләр | га | | |
| 5. | Орлыкларны агулау | кг | 15 | |
| 6. | Җир өстендә котркычларга каршы көрәш чаралары | га | - | |
| 7. | Биологик көрәш чаралары | | | |
| 7.1 | Күкәй күзәнәкләрен нефтьләштерү (ел саен) | га | 500 | |
| 7.2 | Антрактант аулар куллану | га | 400 | |
| 8. | Оештыру-хуҗалык чаралары | | | |
| 8.1 | Корткычлар һәм авырулар чыганаклары барлыкка килүне күзәтү һәм ачыклау | мең га | 46,1 | |
| 8.2 | Яклау почмаклары оештыру | данә | 6 | |
| 8.3 | Санитар-савыктыру чарасы (урманны чүп-чардан арындыру) | га | 2014 – 430<br>2015 – 500;<br>2016 – 450<br>2017 – 400;<br>2018 – 400 | |

Урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

а) пестицидлар һәм агрохимикатлар яисә кешеләр сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч булган бүтән матдәләр, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә карата Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләрне бозу нәтиҗәсендә туфракны пычрату;

б) урман бүлемтекләрен чистарту эшләрен, шулай ук гражданнарга яисә юридик затларга бирелгән урман кишәрлекләрен урман законнарында билгеләнгән тәртиптә шушы кишәрлекләрне максатчан файдалану өчен яраклы хәлгә китерү эшләрен яисә рекультивация эшләрен башкармау яисә вакытында башкармау;

в) авыл хуҗалыгы эшләрен алып бару өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгы терлекләрен киртәләмәгән урыннарда, көтүчесез яисә бәйләмичә көтү;

г) кырмыска ояларын, кош ояларын, хайван өннәрен яисә башка яшәү урыннарын юк итү (туздыру);

д) урманнарда урнашкан мелиоратив системаларны юк итү яисә аларга зыян салу;

е) урманнарны сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары белән пычрату;

ж) урманнарга зарар китерерлек бүтән гамәлләр.

Урманнарда табигый экологик системаларга хас булмаган, шулай ук ясалма юл белән чыгарылган һәм үрчүләрен тикшереп торуның нәтиҗәле чаралары булмаган үсемлекләр, хайваннар һәм башка организмнар үрчетү һәм алардан файдалану тыела.

Сайлап алына торган кисүләр һәм урманнарны карап тоту барышында беренче чиратта корыган һәм зарарланган агачлар киселә.

Агач материалын зарарлый торган корткыч организмнар чыганакларында кисүләрдән калган калдыклар, урман законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланган янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәгән килеш, яндырылырга тиеш.

Урман бүлемтекләрен эшкәрткәндә һәм линия объектлары трассалары өчен кискәндә кисүләрдән калган калдыкларны урман кырыена этеп кую тыела.

Язгы-җәйге чорда әзерләнгән агач материалын урманнарда, кабыгын алмыйча яисә пестицидлар белән эшкәртмичә, 30 көннән дә артык саклау (калдыру) рөхсәт ителми.

Әзерләнгән агач материалын кабыгын алмыйча яисә пестицидлар белән эшкәртмичә урманнарда саклауны (калдыруны) тыя торган конкрет сроклар (даталар) урман үсентеләре зоналары һәм урман районнары буенча Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы тарафыннан билгеләнә.

Агызу өчен билгеләнгән агач материалын химик эшкәртү тыела.

Кәүсә корткычлары оялаган әзерләнгән агач материалы алар очып чыкканчы инсектицидлар белән эшкәртелергә яисә кабыгыннан арындырылырга тиеш. Әзерләнгән агач материалына яклау чаралары аз нәтиҗә бирә торган яисә бетерүе мөмкин булмаган кәүсә корткычлары оялаган очракта, мондый агач материалын кичекмәстән урманнан чыгарырга яисә эшкәртергә кирәк.

Чәер әзерләү өчен зарарлы организмнар чыганакларында урнашкан, шулай ук зәгыйфьләнгән урман үсентеләре бирелми.

Чәер әзерләү өчен бүлеп бирелгән урман үсентеләрендә аны әзерли башлаганчы корып баручы һәм корыган агачлар киселә.

Чәер әзерләүне, шулай ук агач булмаган урман ресурслары (агачлар һәм куаклар кайрылары, чыбык-чабык, ботаклардан терлек азыгы, чыршы, пихта, нарат һәм (яисә) башка ылыслы токымнарның ботаклары, яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлар, мүк, урман туфрагындагы үсемлекләр җәймәсе, камыш, кыяклылар) һәм башка шундый урман ресурслары әзерләү һәм җыюны зарарлы организмнар барлыкка килүне һәм агачлар коруны булдырмый торган алымнар белән башкару рөхсәт ителә.

Урманнарда авыл хуҗалыгы алып бару өчен пестицидлар һәм агрохимикатлар куллану “Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин эш итү турында” Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Рекреацион максатлар өчен урманнардан файдалану урманнарның санитар һәм урман патологиясе начараюга китермәскә тиеш.

Электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линия объектлары төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү, сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехник корылмаларны һәм махсуслаштырылган портларны төзү һәм эксплуатацияләү, агач материалын һәм башка урман ресурсларын эшкәртү, шулай ук башка максатлар өчен урманнардан файдалану гражданнарга һәм юридик затларга бирелгән урман кишәрлекләрендә һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә урманнарның санитар торышы начараюга китермәскә тиеш.

Санитар-савыктыру чараларының нормативлары һәм параметрлары 2.17.2.2 нче таблицада китерелә.

2.17.2.2 нче таблица

Санитар-савыктыру чараларының нормативлары һәм параметрлары

<table>
<tr><th rowspan="3">№№ т/с</th><th rowspan="3">Күрсәткечләр</th><th rowspan="3">Үлчәү берәмлеге</th><th colspan="3">Корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү</th><th rowspan="3">Урманнарны чүпләрдән чистарту</th><th rowspan="3">Барлыгы</th></tr>
<tr><th rowspan="2">Барлыгы</th><th colspan="2">шул исәптән</th></tr>
<tr><th>тоташ</th><th>сайлап алып</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td></tr>
<tr><td colspan="8">Токымы - нарат</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1</td><td rowspan="2">Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд</td><td>га</td><td>89</td><td></td><td>89</td><td></td><td>89</td></tr>
<tr><td>мең.м3</td><td>17,03</td><td></td><td>17,03</td><td></td><td>17,03</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Кисү яисә җыю срогы</td><td>ел</td><td></td><td></td><td>3</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>3</td><td>Агач материалын ел</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

| №№ т/с | Күрсәткечләр | Үл-чәү берәмлеге | Корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү | | | Урманнарны чүпләр-дән чистарту | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бар-лыгы | шул исәптән | | | |
| | | | | тоташ | сайлап алып | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 30 | | 30 | | 30 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м3 | 5,68 | | 5,68 | | 5,68 |
| | -ликвид | мең.м3 | 4,54 | | 4,54 | | 4,54 |
| | -эшлекле | мең.м3 | 2,89 | | 2,89 | | 2,89 |
| **Ылыслылыр барлыгы** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 89 | | 89 | | 89 |
| | | мең.м3 | 17,03 | | 17,03 | | 17,03 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | 3 | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 30 | | 30 | | 30 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м3 | 5,68 | | 5,68 | | 5,68 |
| | -ликвид | мең.м3 | 4,54 | | 4,54 | | 4,54 |
| | -эшлекле | мең.м3 | 2,89 | | 2,89 | | 2,89 |
| **Токымы - имән** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 163 | | 163 | | 163 |
| | | мең.м3 | 7,24 | | 7,24 | | 7,24 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | 3 | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 54 | | 54 | | 54 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м3 | 2,41 | | 2,41 | | 2,41 |
| | -ликвид | мең.м3 | 1,45 | | 1,45 | | 1,45 |
| | -эшлекле | мең.м3 | 0,75 | | 0,75 | | 0,75 |

| №№ т/с | Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | шул исәптән | | | |
| | | | | тоташ | сайлап алып | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| **Барлыгы каты яфраклылар** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 163 | | 163 | | 163 |
| | | мең.м3 | 7,24 | | 7,24 | | 7,24 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | 5 | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 54 | | 54 | | 54 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м3 | 2,41 | | 2,41 | | 2,41 |
| | -ликвид | мең.м3 | 1,45 | | 1,45 | | 1,45 |
| | -эшлекле | мең.м3 | 0,75 | | 0,75 | | 0,75 |
| **Токымы - каен** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 226 | 123 | 103 | | 226 |
| | | мең.м3 | 22,43 | 16,32 | 6,11 | | 22,43 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | 3 | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 75 | 41 | 34 | | 75 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м3 | 7,48 | 5,44 | 2,04 | | 7,48 |
| | -ликвид | мең.м3 | 1,49 | 0,25 | 1,24 | | 1,49 |
| | -эшлекле | мең.м3 | | | | | |
| **Токымы - усак** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 6 | | 6 | | 6 |
| | | мең.м3 | 0,19 | | 0,19 | | 0,19 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | 3 | | 3 |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 2 | | 2 | | 2 |

| №<br>№<br>т/с | Күрсәткечләр | Үл-чәү берәм леге | Корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү | | | Урманнарны чүпләр-дән чистарту | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бар-лыгы | шул исәптән | | | |
| | | | | тоташ | сайлап алып | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м$^{3}$ | 0,06 | | 0,06 | | 0,06 |
| | -ликвид | мең.м$^{3}$ | 0,03 | | 0,03 | | 0,03 |
| | -эшлекле | мең.м$^{3}$ | | | | | |
| | **Токымы - юкә** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 33 | | 33 | | 33 |
| | | мең.м$^{3}$ | 3,56 | | 3,56 | | 3,56 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | 3 | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 11 | | 11 | | 11 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м$^{3}$ | 1,13 | | 1,13 | | 1,13 |
| | -ликвид | мең.м$^{3}$ | 0,68 | | 0,68 | | 0,68 |
| | -эшлекле | мең.м$^{3}$ | - | | - | | - |
| | **Токымы – кара зирек** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 2 | | 2 | | 2 |
| | | мең.м$^{3}$ | 0,05 | | 0,05 | | 0,05 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | 5 | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 1 | | 1 | | 1 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м$^{3}$ | 0,01 | | 0,01 | | 0,01 |
| | -ликвид | мең.м$^{3}$ | 0,01 | | 0,01 | | 0,01 |
| | -эшлекле | мең.м$^{3}$ | - | - | | | - |
| | **Барлыгы йомшак яфраклылар** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча | га | 267 | 123 | 144 | | 267 |
| | | мең.м | 26,23 | 16,32 | 9,91 | | 26,23 |

| №<br>№<br>т/с | Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | шул исәптән | | | |
| | | | | тоташ | сайлап алып | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | ачыкланган фонд | 3 | | | | | |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 89 | 41 | 48 | | 89 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м 3 | 3,24 | 5,44 | 3,24 | | 8,68 |
| | -ликвид | мең.м 3 | 2,21 | 0,25 | 1,96 | | 2,21 |
| | -эшлекле | мең.м 3 | 1,44 | | 1,44 | | 1,44 |
| **Барлыгы урманчылык буенча** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 519 | 123 | 396 | | 519 |
| | | мең.м 3 | 50,5 | 16,32 | 34,18 | | 50,5 |
| 2 | Кисү яисә җыю срогы | ел | | | | | |
| 3 | Агач материалын ел саен алуның мөмкин күләме: | | | | | | |
| | -мәйданы | га | 132 | 41 | 132 | | 173 |
| | сайлана торган запас | | | | | | |
| | -тамырда килеш | мең.м 3 | 11,33 | 5,44 | 11,33 | | 16,77 |
| | -ликвид | мең.м 3 | 8,2 | 0,25 | 7,95 | | 8,2 |
| | -эшлекле | мең.м 3 | 5,08 | | 5,08 | | 5,08 |

## 2.17.3. Урманнарны торгызуга таләпләр

Урманнарны торгызу Россия Федерациясе Урман кодексының 61, 62 статьялары, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 16.07.2007 № 183 боерыгы белән расланган Урманнарны торгызу кагыйдәләре (алга таба – Урманнарны торгызу кагыйдәләре) белән гамәлгә ашырыла.

Урманнарны торгызу урман кисүләр җирләрендә, янгыннан соң калган җирләрдә, бушлыкларда, урман үсентеләре белән капланмаган башка ачыклыкларда яисә урман торгызу өчен яраклы җирләрдә киселгән, корыган, зарарланган урманнарны торгызу максатларында гамәлгә ашырыла. Урманнарны

торгызу урман үсентеләрен тогызуны, урманнарның биологик күптөрлелеген, аларның файдалы функцияләрен саклап калуны тәэмин итәргә тиеш.

Урманнарны торгызу түбәндәгеләр белән тәэмин ителә:

- агач материалы әзерләү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә - шушы урман кишәрлекләренең арендаторлары тарафыннан;

- урман кишәрлекләрендә, агач материалы әзерләү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләреннән гайре, – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан.

Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән һәр урман кишәрлегендә урманнарны торгызу гамәлләре урманнарны торгызу проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны табигый торгызуга ярдәм итү максатларында түбәндәге чаралар күрелә:

- урман үсентеләре ябалдашлары астында шытып чыккан урман үсентеләренең яшәргә сәләтле, әлеге табигый-климат шартларында яңа урман үсентеләре булдырырга сәләтле төп урман агач токымнары (алга таба – төп урман агач токымнары) буынын (яшь агачларны) саклап калу. Ике яшькә кадәрге агач үсентеләре (үзлегеннән үсеп чыккан) яшь агачларга кертелми;

- урман үсентеләрен кисүләр уздырганда яшәргә сәләтле, яхшы тамыр җибәргән, 2,5 метрдан артык биеклектәге төп урман агач токымнары булдыруда катнашучы урман үсентеләрен саклап калу;

- урман үсемлекләре белән капланамаган мәйданнарда кыйммәтле агач токымнарының урман үсентеләре шытымнарын карау;

- туфрак өслеген минеральләштерү;

- мәйданнарны киртәләү.

Кыйммәтле урман агач токымнарының урман үсентеләре шытымнарын саклап калу чаралары урман үсентеләрен кисү белән бер үк вакытта гамәлгә ашырыла. Мондый очракларда кисүләр башлыча кар өсли кыйммәтле урман агач токымнары шытымнары һәм яшь агачлары санын урман бүлемтеге биргәндә каралганнан күбрәк юк итүдән һәм зарарлаудан саклауны тәэмин итәрлек технологияләр кулланып гамәлгә ашырыла. Кисүләр уздырганнан соң шытымнарны һәм яшь агач токымнарын кисек калдыкларыннан, сынган һәм зарарланган урман үсентеләреннән арындыру юлы белән аларны карау уздырыла.

Кисүләр уздырганда урман үсентеләрен яшәргә сәләтле нарат, чыршы, пихта, имән, бук, корычагач һәм үзләренә туры килә торган табигать-климат шартларындагы кыйммәтле агач токымнарының бөтән урман үсентеләре шытымнары һәм яшь агачлары сакланып калырга тиеш.

Мәйданнарны киртәләү юлы белән урманнарны табигый торгызуга ярдәм күрсәтү яңа чыккан урман үсентеләренә һәм шытымнарына кыргый яисә йорт хайваннары зарар китерү куркынычы булган очракларда планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла.

Туфракны минеральләштерү юлы белән урманнарны табигый торгызуга ярдәм күрсәтү урман үсентеләренең кыйммәтле агач токымнары орлыклары чыганаклары (якындагы урман үсентеләре, аерым орлык агачлары яисә аларның төркемнәре, чәчәклекләре, полосалары, тулылыгы 0,6 дан артык булмаган урман

үсентеләре ябалдашлары астындагы кисергә керешелә торганнары) булган мәйданнарда гамәлгә ашырыла.

Хуҗалык эшчәнлеге чикләнгән режимдагы урманнарда, шул исәптән милли парклардагы урманнарда, табигать тыюлыкларында урманнарны табигый торгызуга ярдәм итүнең башка чаралары, алар тиешле территорияләрне саклау режимын бозарлык булмаса гына, гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Урманнарны табигый торгызуга ярдәм итү буенча уздырылган чаралар нәтиҗәләре Урманнарны торгызу кагыйдәләре белән билгеләнгән шытымнарның куелык нормативларына туры килгәндә генә нәтиҗәле дип таныла. Урманнарны табигый торгызуга ярдәм итү чараларының нәтиҗәлелеген исәпкә алу эшләр башкарылганнан соң ике ел узгач гамәлгә ашырыла.

Агач токымнары белән урманнарны табигый торгызу уңышлы уздырылган мәйданнар урман үсемлекләре каплаган җирләргә кертелә.

Шытымнар саны Урманнарны торгызу кагыйдәләре белән билгеләнгәнннән кимрәк булганда, урманнарны ясалма яисә катнаш торгызуның өстәмә чаралары карала.

Кыйммәтле урман агач токымнарын табигый торгызуга бәйле рәвештә урманнарны торгызу алымнары 2.17.3.1 нче таблицада китерелә.

2.17.3.1 нче таблица

Кыйммәтле урман агач токымнарын табигый торгызуга бәйле рәвештә урманнарны торгызу алымнары

| Урманнарны торгызу алымнары | Агач токымнары | Урманнар типлары төркемнәре, урман үсү шартлары типлары | Яшәргә сәләтле шытым һәм яш үсенте саны, 1 гектарга мең данә |
|---|---|---|---|
| Урман-дала зонасы | | | |
| Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | | | |
| Шытымнарны саклап калу чаралары ярдәмендә урманнарны табигый торгызу | Нарат | Бик коры һәм коры наратлыклар, катнаш наратлыклар һәм катнаш имәнлекләр | 4,0тән артык |
| | Имән | Бик коры һәм коры имәнлекләр, имәнлекләр һәм катнаш имәнлекләр | 3,0тән артык |
| | | Яңа имәнлекләр һәм катнаш имәнлекләр, дымлы һәм тугай имәнлекләре | 2,0дән артык |
| Туфракны минеральләштерү юлы белән урманнарны табигый торгызу яисә урманнарны катнаш торгызу | Нарат | Бик коры һәм коры наратлыклар, катнаш наратлыклар һәм катнаш имәнлекләр | 1,5 – 4,0 |
| | | Яңа наратлыклар, катнаш наратлыклар һәм катнаш имәнлекләр | 0,5 – 2,0 |

| Урманнарны торгызу алымнары | Агач токымнары | Урманнар типлары төркемнәре, урман үсү шартлары типлары | Яшәргә сәләтле шытым һәм яш үсенте саны, 1 гектарга мең данә |
|---|---|---|---|
| | | Дымлы наратлыклар, катнаш наратлыклар һәм катнаш имәнлекләр | 0,5 – 1,5 |
| | Имән | Бик коры һәм коры имәнлекләр, катнаш имәнлекләр | 2 – 3,0 |
| | | Яңа имәнлекләр һәм катнаш имәнлекләр, дымлы һәм тугай имәнлекләре | 1 – 2,0 |
| Урманнарны ясалма торгызу | Нарат | Бик коры һәм коры наратлыклар, катнаш наратлыклар һәм катнаш имәнлекләр | 1,5тән ким |
| | | Дымлы наратлыклар, катнаш наратлыклар һәм катнаш имәнлекләр | 0,5 тән ким |
| | Имән | Бик коры һәм коры имәнлекләр, катнаш имәнлекләр | 2,0дән ким |
| | | Яңа имәнлекләр һәм катнаш имәнлекләр, дымлы һәм тугай имәнлекләре | 1,0дән ким |

Урманнарны ясалма торгызу хуҗалык өчен кыйммәтле урман агач токымнарын урманнарны табигый торгызуны тәэмин итү мөмкин булмаганда яисә урманнарны катнаш торгызу максатка ярашсыз булганда, шулай ук урман культуралары һәлак булган урман кишәрлекләрендә гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын булдыру өчен урман кишәрлеген әзерләгәндә шуннан соңгы барлык технологик гамәлләрне сыйфатлы үтәү өчен, шулай ук янгын куркынычын киметү һәм урман культураларының санитар торышын яхшырту өчен шартлар тудыру чаралары гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлеген әзерләүгә түбәндәгеләр керә:

- урман кишәрлеген тикшерү;
- урманнарны торгызуны проектлау;
- урман кишәрлеге бүлемтеге;
- урман культураларының яисә туфрак эшкәртү полосаларының булачак рәтләре линияләрен маркировкалау һәм техника эшләү өчен куркыныч булган урыннарны билгеләү;
- мәйданны ауган агачлардан, ташлардан, кирәксез агач үсемлекләреннән, вак түмәрләрдән, корыган агач кәүсәләреннән тоташ яисә полосалап чистарту;
- түмәрләрне казып алу яисә аларның биеклеген техника йөрешенә комачауламаслык дәрәҗәдә киметү;

- урман кишәрлеге өслеген планлаштыру, мелиоратив эшләр алып бару, авышлыкларда террасалар кисү;

- зарарлы туфрак организмнары белән башлангыч көрәш.

Туфракны эшкәртү алымнары урманнарны ясалма торгызуны проектлаганда табигать-климат шартларына, туфрак типларына һәм бүтән факторларга бәйле рәвештә сайлап алына.

Туфракны эшкәртү барлык кишәрлекләрдә (тоташ эшкәртү) яисә аның бер өлешендә (өлешчә эшкәртү) механик, химик яисә термик алымнар белән гамәлгә ашырыла. Нигезе, техника кулланып, туфракны механик эшкәртү була.

Урман культуралары төп бер агач токымының урман үсентеләреннән (чиста токымнардан) яисә төп берничә агач токымыннан һәм юлдаш агач һәм куак токымнарыннан булдырылырга мөмкин.

Төп урман агач токымы җирле урман агач токымнарыннан сайлап алына һәм урманнарны торгызу максатларына җавап бирергә һәм урман кишәрлегенең табигать-климат шартларына туры килергә тиеш.

Юлдаш агач һәм куак токымнарын сайлап алганда аларның төп урман агач токымына йогынтысын исәпкә алырга кирәк.

Юлдаш агач һәм куак токымнары урман культураларына кертү башлыча аларның рәтләрен төп урман агач токымы рәтләре белән чиратлаштырып гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын булдыруның төп ысулы утырту материалының төрле төрләре белән гамәлгә ашырыла торган утыртудан гыйбарәт. Су һәм җил эрозиясенә дучар булган туфракларда, артык дымлы туфракларда һәм утырту урыннарын чүп үләннәр бик тиз басып китә торган кишәрлекләрдә, шулай ук дымылык булмаган районнарда гамәлгә ашырырга кирәк.

Зарарлы организмнар таралу чыганакларында утыртуның (чәчүнең) башлангыч куелыгы) һәм урман культуралары составы махсус тикшеренүләр нигезендә билгеләнә.

Урман культураларын утырту һәм чәчү туфракка ашламалар, үсемлекләрне яклау чаралары кертү, шулай ук туфракны яхшырта торган махсус үләннәр чәчү белән бергә алып барылырга мөмкин.

Күп очракларда урман культураларын утыртуның һәм чәчүнең иң яхшы срогы – яз башы, бөреләр уяна башлаганчы.

Туфрак өслеген чүп үләннәр һәм агач-куак үсемлекләре сырып алмасын, туфракта дым җыелсын өчен урман культураларын агротехник карау уздырыла.

Агротехник карауга түбәндәгеләр кертелә:

- үсентеләрне үлән һәм туфрак өемнәреннән, ком басып китүдән, туфрак юылудан һәм җил алып китүдән, суыклар кысудан кулдан төзәтү;

- культуралар рәтләрендә һәм рәт араларында үлән һәм агач үсемлекләрен юк итеп, туфрак йомшарту;

- үлән һәм кирәксез агач үсемлекләрен юк итү һәм чыгуларын булдырмый калу;

- урман культураларын өстәү, минераль ашламалар белән тукландыру һәм урман культураларына су сибү.

Урман зонасында агротехник карау башлыча төп урман агач токымының урман үсентеләрен чүп үләннәр һәм кирәксез тиз үсә торган урман агач токымнары йогынтысы аркасында начар үсүдән һәм һәлак булудан саклап калу максатларында уздырыла.

Агротехник карау алымнары, саны һәм озынлыгы табигать-климат шартларына, культивацияләнә торган урман агач токымның биологик үзенчәлекләренә, туфрак эшкәртү алымына, урман культураларын булдыру ысулына, кулланыла торган утырту материалы зурлыгына бәйле була.

Чүп үләннәрне һәм кирәксез агач үсемлекләренә каршы көрәш өчен химик чаралар куллану, Россия Федерациясе урман законнары нигезендә әйләнә-тирә мохитне саклауны исәпкә алып, бик сирәк очракларда гына рөхсәт ителә.

Үсеп китү мөмкинлеге 25-85% булган урман культуралары (үсемлекләрнең һәлак булган нөсхәләре урынына яңаларын утырту) өстәлергә тиеш. Тигез һәлак булмый торган урман культуралары кишәрлек мәйданы буйлап үсеп китүчәнлегенә карамастан өстәләләр.

Урманнарны катнаш торгызу төп урман агач токымы урман үсентеләрен табигый торгызуның урман кишәрлекләрендә утырту һәм чәчү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын утырту һәм чәчү юлы белән кертелгән төп урман агач токымы урман үсентеләре саны урман үсентеләре шытымнарына тигез яисә аннан да күбрәк булган урман кишәрлекләре мәйданнары урманнарны катнаш торгызу биләгән урман үсентеләрен саны ким булган мәйданнарга кертелә.

Урманнарны катнаш торгызганда урман культуралары куелыгы (бер берәмлек мәйданган утырту яисә чәчү урыннары саны) төп урман агач токымы урман үсентеләренең гамәлдәге шытымнары һәм яшь агачлары санына карап билгеләнә.

Урман үсентеләре ябалдашлары астында урманнарны катнаш торгызу санитар-гигиеник функцияләрен арттыру максатларында башлыча яшел зоналарда, эрозиягә каршы һәм башка яклаучы урманнарда уздырыла.

Урман үсентеләре ябалдашлары астында урманнарны катнаш торгызу урман культураларының башлангыч куелыгы тиешле табигать-климат шартларында урманнарны ясалма торгызу өчен билгеләнгән норманың кимендә 50%ын тәшкил итәргә тиеш.

Үсеп китүчәнлеге кимендә 25% булган урман культуралары һәлак булган дип санала..

Урман агач токымнарының утырту материалына һәм урманнарны ясалма һәм катнаш торгызганда булдырылган, мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелә торган яшь агачлар сыйфатына карата таләпләр 2.17.3.2 нче таблицада китерелә.

2.17.3.2 нче таблица

Урман агач токымнарының утырту материалына һәм урманнарны ясалма һәм катнаш торгызганда булдырылган, мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелә торган яшь агачлар сыйфатына карата

таләпләр

| Агач токымнары | Утырту материалына карата таләпләр | | | Мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелә торган яшь агачлар сыйфатына карата таләпләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | яше, кимен дә, ел | тамыр башланган җирдә кәүсәсе диаметры, кимендә, мм | кәүсәсе биеклеге кимендә, см | урманнар типлары төркеме яисә урман үсентеләре шартлары типлары | яше, кимен-дә, ел | төп токымнар агачлары саны кимендә, 1 гектарга мең данә | төп токым-нар агачлары ның уртача биеклеге кимендә, м |
| Урман-дала зонасы | | | | | | | |
| Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | | | | | | | |
| Еламсар каен | 1-2 | 2,0 | 20 | Яңа һәм дымлы имәнлек | 5 | 2,0 | 1,3 |
| Ботаклы-чатаклы имән | 1 - 2 | 4,0 | 15 | Коры һәм ярым коры чыршы катыш урман | 7 | 1,5 | 0,9 |
| | | | | Яңа һәм дымлы чыршы катыш урман | 7 | 1,5 | 1,1 |
| Европа чыршысы (гади) | 2 - 3 | 2,0 | 12 | Дымлы һәм ярым дымлы чыршылыклар | 7 | 1,5 | 1,3 |
| | | | | Яңа һәм дымлы чыршы катыш урман | 7 | 1,5 | 0,7 |
| Сукачев һәм Себер карагайлары | 1-2 | 2,5 | 15 | Яңа наратлык һәм карагай катнаш урман | 5 | 1,5 | 1,4 |
| Гади нарат<br>Ак тополь | 2<br>1 | 3,0<br>3,0 | 10<br>15 | Коры наратлык, нарат катыш һәм чыршы катыш урман | 6 | 2,2 | 1,1 |
| | | | | Яңа һәм дымлы наратлык, нарат катыш һәм чыршы катыш урман | 6 | 2,0 | 1,3 |
| | | | | Дымлы һәм ярым дымлы чыршылыклар | 4 | 0,8 | 2,5 |
| Гади корычагач һәм ланцет корычагачы (яшел) | 1 | 2,0 | 12 | Яңа һәм дымлы имәнлек | 6 | 2,0 | 1,7 |
| | | | | Нарат җиләкле, ачы җиләкле, кара җиләкле | 7 | 2,0 | 1,2 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Озын мүкле һәм сфагналы | 7 | 2,2 | 1,0 |
| Ясень обыкновенный | 2 | 4,0 | 15 | Яңа һәм дымлы имән катыш һәм имәнлекләр һәм имәнлекләр | 6 | 2,0 | 1,5 |

Урманнарны үрчетү Россия Федерациясе Урман кодексының 63 статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 08.06.2007 № 149 боерыгы белән расланган Урманнарны үрчетү кагыйдәләре (алга таба – Урманнарны үрчетү кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны үрчетү урман фонды җирләрендә һәм элек урманнар үсмәгән бүтән категория җирләрдә туфракның су, җил һәм бүтән эрозиясен булдырмый калу, яклаучы урманнар булдыру максатларында һәм урманнарның куәтен арттыруга бәйле бүтән максатларда гамәлгә ашырыла.

Урманнарны үрчетүгә түбәндәгеләр керә:

- урман фонды җирләре составындагы урманныкы булмаган җирләрне урманлату (киптерелгән сазлыклар, рекультивацияләнгән җирләр, авыл хуҗалыгы файдалануыннан төшеп калган җирләр, ярлар һәм башкалар);

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә, сәнәгать, транспорт җирләрендә, су фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрдә яклаучы урман үсентеләре булдыру;

- сәнәгать эшчәнлеге белән бозылган җирләрне рекультивацияләгәндә урман үсентеләрен булдыру;

- шифаханә-ял йортлары зоналарында һәм башка объектларда урман үсентеләре булдыру.

Урманнарны үрчетү куелган максатлар, җир кишәрлекләренең урман үсү үзенчәлекләре, агач һәм куак токымнарының урманчылык-биологик үзлекләре нигезендә гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- җирләрне һәм объектларны уңайсыз факторлардан яклауны;

- территориянең урманлылыгын арттыру һәм әйләнә-тирә мохит шартларын яхшыртуны.

Урманнарны үрчетү утыртмалар, чәчкеннәр, ботаклар утырту яисә орлык чәчү ысуллары белән ясалма урман үсентеләре булдырып гамәлгә ашырыла .

Урманнарны үрчетү максатларында сөрүлек җирләрендә булдырылган урман үсентеләренең төп төрләре кыр саклаучы һәм сулар агышын җайга салучы урман полосаларыннан гыйбарәт була.

Көтүлекләрдә микроклиматны яхшырту, көтүлекләрнең продуктлылыгын арттыру, терлекләрне уңайсыз климат шартларыннан яклау өчен урман мелиоратив үсентеләре булдырыла.

Гомуми файдаланудагы тимер юллар һәм автомобиль юллары буйлап урнашкан урманнарның яклаучы полосаларын кар һәм ком каплап китүдән яклау өчен, шулай ук янәшәдәге авыл хуҗалыгы җирләрен авыр металлар керүдән яклау өчен аларда урман үсентеләре булдырыла.

Рекультивацияләнергә тиешле җирләрдә урманнар үрчетү рекультивациянең техник этабын (планлаштыру, уңдырышлы катлам грунт

кертү, авышлыкларны террасалау һәм башкалар) уздырганнан соң урман үсентеләре булдыру юлы белән шушы җирләрне биологик рекультивацияләү максатында гамәлгә ашырыла.

Су саклау зоналарында һәм су объектларының яр буе яклау полосаларында урманнарны үрчетү яр ныгытучы үсемлекләр һәм бүтән урман үсентеләре утырту юлы белән аларны ярлары җимерелүдән, сазланудан, ләмләнүдән һәм су ресурсларын бөтәшүдән яклау максатларында гамәлгә ашырыла.

Торак пунктлар җирләрендә урманнарны үрчетү рекреацион йөкләнешләргә, сәнәгать чыгарып ташлауларына һәм башка уңайсыз факторларга карата тотрыклы урман үсентеләре булдыру юлы белән әйләнә-тирә мохитне яхшырту максатларында гамәлгә ашырыла.

Урманнарны үрчетү эшләрен башкару ысуллары һәм технологияләре урманнарны үрчетү проектлары белән билгеләнә. Урманнарны үрчетү проектында урманнарны үрчетү эшләрен тәмамланган дип тану өчен урманнар үрчетүнең булдырылган объектлары торышын бәяләүнең конкрет критерийлары (урман мелиоратив үсентеләренең яшен, агачларның уртача биеклеген, ябалдашларның йомыклыгы күрсәткечен, бер берәмлек мәйданда яшәргә сәләтле агачлар һәм куаклар санын һәм башкаларны) булырга тиеш.

Урман үсентеләре бер генә төп агач яисә куак токымыннан йә берничә төп токымнан һәм юлдаш агач һәм куак токымнарыннан булдырылырга мөмкин.

Төп агач токымы урманнарны барлыкка китерә торган җирле токымнардан сайлап алына, уңай тәҗрибә булганда – интродуцияләнгән токымнардан. Ул урманнар үрчетү максатларына җавап бирергә һәм җир кишәрлегенең урман үсү үзенчәлекләренә туры килергә тиеш.

Юлдаш агач һәм куак токымнарын сайлап алу утырту материалының төрле төрләрен кулланып гамәлгә ашырылырга мөмкин. Юлдаш агач һәм куак токымнарын сайлап, аларның төп токымга йогынтысын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Урманнарны үрчеткәндә урман үсентеләрен булдыруның төп ысулы утырту материалының төрле төрләрен кулланып урман үсентеләрен утыртудан гыйбарәт була. Утырту өчен чәчкеннәр һәм утыртмалар, шулай ук ботаклар кулланыла.

Утырту материалы утыртыр алдыннан аны кибүдән һәм зарарлы организмнар белән зарарланудан яклау, шулай ук үсеп китүчәнлеген һәм үсү тизлеген арттыру өчен төрле матдәләр белән эшкәртелергә мөмкин.

Булдырыла торган урман үсентеләренең башлангыч куелыгы һәм утырту урыннарының урнашуы агачлар һәм куаклар үсә барган саен уңайсыз факторларга тотрыклы, озак тора торган һәм урман үрчетү максатларына җавап бирүче урман үсентеләрен формалаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

Булдырыла торган урман үсентеләренең башлангыч куелыгы һәм утырту урыннарының урнашуы төп агач токымының төренә, урман үсү зонасына, урман үсү шартлары тибына, урман үрчетү ысулына һәм максатларына, кулланыла торган утырту материалы тибына бәйле.

Агач һәм куаклар токымнарын утырту туфракка ашламалар, үсемлекләрне зарарлы организмнардан яклау чаралары кертү, шулай ук үләннәрне киләчәктә

ашлама рәвешендә файдалану, печән әзерләү һәм башка максатларда файдалану өчен чәчү белән бергә алып барырырга мөмкин.

Утыртылган урман үсентеләрен карау агротехник (агротехник карау) һәм урманчылык алымнары (урманчылык каравы) белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Агротехник карау, кагыйдә буларак, агачлар һәм куаклар ябалдашлары кушылганчы гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләр ярдәмендә тәэмин ителә:

- үсемлекләрне үлән һәм туфрак каплаудан, ком томалап китүдән, туфрак юылудан һәм җил алып китүдән, кар басудан яклау өчен кулдан төзәтеп чыгу;

- үләннәрне механик юл белән юк итеп, туфрак йомшарту;

- үләннәрне химик чаралар ярдәмендә юк итү;

- урман үсентеләрен өстәү (һәлак булганнары, тамыр җибәрмәгәннәре урынына агачлар һәм куаклар утырту), минераль, органик ашламалар белән тукландыру һәм су сибү (махсус чаралар буларак планлаштырыла һәм уздырыла).

Агротехник карау максаты – үләннәрне һәм кирәксез урман үсентеләрен юк итү.

Агротехник караулар алымнары, саны, кабатлану сроклары һәм уздыру озынлыгы (утыртканнан соң число, ел) урман үсү шартлары тибына, культивацияләнә торган агач һәм куак токымнарының биологик үзенчәлекләренә, туфрак эшкәртү алымына, урман үсентеләрен булдыру алымына, кулланыла торган утырту материалының зурлыгына һәм башка үзенчәлекләренә карап билгеләнә.

Чүп үләннәре һәм кирәксез агач үсентеләре белән көрәшү өчен химик чаралар куллану пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин эш итү турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә рөхсәт ителә.

Минераль һәм органик ашламалар, кагыйдә буларак, ярлы (комнан торган, юылган, киптерелгән, рекультивацияләнгән), үләннәр үсми торган туфракларга кертелә.

Үсеп китүчәнлеге 25тән алып 85 процентка кадәр булган урман үсентеләре өстәлергә тиеш (утыртылган яисә чәчелгән урман үсентеләре саныннан үсеп киткән үсентеләр яисә шытымнар саны процентларда). Кишәрлек мәйданы буйлап үсеп киткән үсемлекләре яисә шытымнары тигез урнашмаган урман үсентеләре ничек үсеп китсәләр дә өстәлергә тиеш.

Өстәгәндә утырту материалы яше культивацияләнгән үсемлекләр яшенә туры килергә тиеш.

Урман үрчетү максатларында булдырылган урман үсентеләрен урманчылык каравы зәгыйфьләнгән, һәлак булган кирәксез агач үсентеләрен һәм калганнары яхшы үссен, файдалы функцияләрен үтәүне тәэмин итәрлек үсентеләр структурасын формалаштыру өчен сәламәт агачлар һәм куаклар өлешләрен урманнарны үрчетү максатлары нигезендә даими рәвештә кисеп торудан гыйбарәт.

Урманчылык каравы культивацияләнгән агачларның һәм куакларның ябалдашлары кушылганнан соң уздырыла.

Агачларның һәм куакларның ябалдашлары кушылганнан соң урман үсентеләрен карау Россия Федерациясенең урман законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман үрчетү объектларын булдыру эшләре, булдырылган урман үсентеләре урман үрчетү проекты белән билгеләнгән критерийларга туры килсә, тәмамланган дип санала.

Урманнарны карау Россия Федерациясе Урман кодексының 64 статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 16.07.2007 № 185 караы белән расланган Урманнарны карау кагыйдәләре (алга таба - Урманнарны карау кагыйдәләре).

Урманнарны карау урманнарның продуктлылыгын арттыру һәм аларның файдалы функцияләрен агачларның һәм куакларның өлешләрен кисү юлы белән саклап калу, Татарстан Республикасы Урман планы, әлеге Урманчылык регламенты, шулай ук урманнарны үзләштерү проекты нигезендә урманнарны агромелиоратив карау максатларында гамәлгә ашырыла.

Урманнарны карауны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

- урманнарны үзләштерү проекты нигезендә урманнардан фйдаланучы гражданнар һәм юридик затлар;

- Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы.

Урманнарны караганда токым составын һәм сыйфатын яхшыртуга, аларның тискәре йогынтыларга тотрыклылыгын һәм экологик ролен арттыруга юнәлгән теләсә нинди кисүләр (алга таба – урманнарны карау өчен кисү) рөхсәт ителә.

Эксплуатацион урманнарда урманнарны карау чаралары югары сыйфатлы агач материалын һәм урман ресурсларын урманнарның файдалы функцияләрен саклап калган килеш, аларны эшкәртү продуктларын мөмкин кадәр нәтиҗәле алуга юнәлгән.

Яклаучы урманнарда урманнарны карау чаралары урманнарның тирәлек барлыкка китерүче, су саклаучы, яклаучы, санитар-гигиеник, савыктыру һәм бүтән файдалы функцияләрен саклап калуга юнәлгән.

Урманнарны карау өчен кисүләр урман үсентеләренең токым составын яхшырту, урман үсентеләренең сыйфатын һәм тотрыклылыгын арттыру, яклаучы, санитар-гигиеник һәм бүтән файдалы функцияләрен саклап калу, техник яктан өлгергән агач материалын үстерү срокларын кыскарту, агач материалы ресурсларынна нәтиҗәле файдалану максатларында уздырыла.

Урман үсентеләренең яшенә һәм карау масатларына бәйле рәвештә урманнарны карау өчен түбәндәге төр кисүләр гамәлгә ашырыла:

- яшь агачларның сыйфат составын һәм төп агач токымы агачларының үсү шартларын яхшыртуга юнәлгән яктыртулар;

- урман үсентеләренең куелыгын җайга салуга һәм төп агач токымы урман үсентеләренең үсү шартларын яхшыртуга, шулай ук урман үсентеләренең токым һәм сыйфат составын формлаштыруны дәвам итүгә юнәлгән чистарту;

- агачларның кәүсәләре һәм ябалдашлары дөрес формалашсын өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлгән сирәкләү;

- агачлар саны артсын өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлгән аркылы узу өчен кисүләр;

- өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган үсентеләрдә булган яшь перспектив агачлар үссен өчен уңай шартлар тудыру максатында урман үсентеләрендә уздырыла торган яңартулар;

- формалашкан урта яшьтәге һәм өлкән яшьтәге урман үсентеләрендә аларның составын, структурасын һәм корылышын максатчан токымнар агачлары, буыннары, яруслары үссен өчен уңайлы шартлар тудыру юлы белән бөтенләй үзгәртү максатында уздырыла торган үзгәртеп корулар;

- урман парклары ландшафтлары формалаштыруга һәм аларның эстетик, савыктыру кыйммәтен һәм тотрыклылыгын арттыруга юнәлдерелгән ландшафт формалаштыру.

Яктырту, чистарту, сирәкләү, аркылы узу өчен кисүләр уздыру яше чорлары 2.17.3.3 нче таблицада китерелә.

2.17.3.3 нче таблица

Урманны карау буенча кисүләр барышында агачларның яше чорлары

| Урманны карау буенча кисүләр төрләре | Урман үсентеләре яше, ел | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | орлык рәвешендәге һәм беренче шытып чыккан рәвештәге ылыслы һәм каты яфраклы агач токымнарының кисү яше вакыты | | кисүләр яше вакытында калган агач токымнары | | |
| | 100 елдан артык | 100 елдан ким | 60 елдан артык | 50-60 ел | 50 елдан ким |
| Яктырту | 10га кадәр | 10га кадәр | 10га кадәр | 10га кадәр | 5кә кадәр |
| Чистарту | 11-20 | 11-20 | 11-20 | 11-20 | 6-10 |
| Сирәкләү | 21-60 | 21-40 | 21-40 | 21-30 | 11-20 |
| Аркылы узу өчен кисүләр | 60тан артык | 40тан артык | 40тан артык | 30дан артык | 20дән артык |

Урманнарны карау өчен чираттагы кисү дүрт төркемгә бүленә:

- беренче төркемгә яшь урманнарда карау өчен кисү һәм катнаш урман үсентеләрендә кисү керә;

- икенче төркемгә бик куе чиста урман үсентеләрендә сирәкләү, катнаш урман үсентеләрендә аралар буйлап беренче кисү керә;

- өченче төркемгә катнаш урман үсентеләрендә соңгы аралар буйлап кисү, яңарту, яңадан формалаштыру өчен кисү керә;

- дүртенче төркемгә чиста урман үсентеләрендә аркылы узу өчен кисүләр керә (шул исәптән агач материалының гомуми запасында йомшак яфраклылар өлеше 30 процентка кадәр булган ылыслылар).

Урманнарны карау өчен кисү сроклары:

- яктырту һәм чистарту – барлык вегетацион чорда агачлар яфраклы вакытта;

- сирәкләү һәм аркылы узу өчен кисүләр – елы буена;

- җиләклекләрен саклап калу максатларында (нарат җиләге, кара җиләк һәм башкалар) урман үсентеләрендә кисү – кар өсли.

Урманнарны карау өчен кисү ылыслы һәм каты яфраклы орлыклы урман үсентеләрендә өлгергән агачларны кисү – билгеләнгән яшеннән 20 ел алдан, йомшак яфраклы һәм каты яфраклы яшь урман үсентеләрендә 10 ел алдан тәмамлана.

Урманнар өчен агромелиоратив чаралар уздыру юлы белән урманнарны карау яклаучы урман үсентеләрен булдырудан һәм торгызудан, аларны реконструкцияләүдән, кисү юлы белән урманнарны формалаштырудан һәм санитар кисүдән, куакларны яңартудан, шытымнарны караудан, урманнарны табигый торгызудан, хәрәкәтчән комлыкларны ныгытудан, көтүлекләрне яхшыртудан, деградацияләнгән җирләрне урманландырудан, җир кишәрлекләренең туфрак эрозиясеннән зарар күргән җирләрне яклаудан, урманнарны янгыннардан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә бүтән афәтләрдән саклаудан гыйбарәт.

Кыйммәте аз булган урман үсентеләрен реконструкцияләү бер класслы яшь дәвамында урман үсентеләрен тулысынча яисә өлешчә алмаштыру юлы белән тамырдан үзгәртүгә юнәлдерелгән чаралар комплексыннан тора (реконструкцияләү өчен кисү, урман культуралары булдыру, башка чаралар).

Икътисадый, экологик максатларга туры килми торган һәм урманнарны карау өчен кисү юлы белән формалаштыру өчен үз составында хуҗалык кыйммәтенә ия җитәрлек санда әлеге урман үсентеләре шартларына һәм урман кишәрлеге максатларына туры килә торган кыйммәтле токым агачлары булмаган кыйммәте аз урман үсентеләреннән гыйбарәт (шул исәптән табигый яңартуга ярдәм итәрлек).

Эксплуатацион урманнарда реконструкцияләү җитештерүчәнлеге һәм сыйфаты түбән булган (тыгызлыгы түбән, составы канәгатьләнерлек булмаган, товарлылылыгы түбән һәм башкалар) агачларны хуҗалык кыйммәте булган агачларга аламаштыру максатларында гамәлгә ашырыла.

Яклаучы урманнарда реконструкцияләү тирәлек барлыкка китерү, су саклау, санитарно-гигиеник, савыктыру һәм бүтән файдалы функцияләрен югалта баручы урман үсентеләрен урманнарның яклаучы һәм бүтән файдалы функцияләрен тәэмин итәрлек урман үсентеләренә алмаштыру максатларында гамәлгә ашырыла.

Реконструкцияләү өчен кисү нормативлары (урман бүлемтегенең киңлеге һәм мәйданы, урман бүлемтекләренең кушылу срогы) урта яшьтәге, өлгергән, өлгереп килүче һәм картайган кыйммәте аз булган урман үсентеләрендә йомшак яфраклы урман үсентеләрен төп файдалануның тоташ кисүләре өчен агач материалын әзерләү нормативлары нигезендә билгеләнә.

Яшь агачларны реконструкцияләгәндә реконструкцияләү өчен кисүләр уздырыла торган урман кишәрлекләре мәйданы чикләнми, урманнарны торгызу чаралары реконструкцияләү өчен кисүләрдән соң бер ел узгач гамәлгә ашырыла.

Кыйммәте аз булган урман үсентеләрен реконструкцияләгәндә яклаучы урманнарда бер мәртәбә реконструкция уздырыла торган кишәрлекләрнең алдан

билгеләнгән мәйданнары күләмнәре 5 гектардан артмый, ике-өч мәртәбә реконструкция уздырганда – 10 гектардан артмый.

Күрше кишәрлекләрдә реконструкцияләү өчен шуннан соңгы һәр кисү бары тик аның янәшәсендәге кишәрлекләрдә яшь агачларның ябалдашлары урманнарны торгызуның таләпләренә туры килерлек итеп кушылган очракта гына рөхсәт ителә.

Урманчыкны карау мөмкин кадәр урманнарны карау өчен чираттагы кисү белән бергә алып барылырга тиеш.

Химик карау түбәндәгеләрдә рөхсәт ителми (шул исәптән фәнни максатларда да):

- биосфера полигоннарыннан гайре, махсус саклanучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнарда;

- су саклау зоналарында урнашкан урманнарда;

- яшел зоналарда һәм урман паркларында.

Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны карау өчен кисүләр тамыр системасы тирән булган агач һәм куаклар токымнары катнашындагы сәламәт, тотрыклы урман үсентеләрен үстерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Яфраклы токымнары 20-30 процент булган катнаш ылыслы-яфраклы урман үсентеләрен формалаштыру максатка ярашлы була.

Һәр кисү вакытында урман үсентеләре ябалдашларының ябык булу дәрәҗәсе 0,6-0,7дән дә кимемәскә тиеш.

Су кырые буйлап 30-50 м киңлектәге яр саклау урман кишәрлекләре калдырыла, алар буйлап тракторлар йөрмәскә тиеш. Урманнарны карау өчен кисүләр асылда кыш көне җир туңган вакытта гамәлгә ашырыла. Кисүләрдән калган калдыклар яндыру өчен яр саклау урман кишәрлекләреннән читкә чыгарыла.

Гомуми файдаланудагы тимер юллар, гомуми файдаланудагы федераль автомобиль юллары, Россия Федерациясе субъектлары милкендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап урнашкан яклаучы урман полосаларында урманнарны карау өчен кисүләр урман үсентеләренең кар тоту, җил тизлеген киметү, туфракны ныгыту сыйфатларын арттыруга юнәлдерелә.

Кисүләрнең интенсивлыгы еш булмаска, тулылылыгы 0,7дән кимемәскә тиеш. Технологик коридорлар ярып чыгу юл янәшәсендәге 25-30 метр киңлектәге урман авызында башкарылмаска тиеш.

Чокырлар һәм яр буйларындагы урман полосаларында туфрак юылмасын һәм бу полосаларның кар тоту функцияләрен саклап калу өчен, урманнарны карау өчен кисү юлы белән куаклыклардан һәм икенче ярус агачларыннан торган урман авызын саклап калган килеш, ябалдашларның йомыклыгы югары дәрәҗәдә тотыла.

Чокырлар һәм ярларда урнашкан урман үсентеләрендә урманнарны карау өчен кисүләр башка урманнардагы кебек үк уздырыла.

Сәнәгать чыгарып ташлаулары белән зәгыйфьләнгән урманнарны кискәндә иң тотрыклы агач һәм куак токымнарына өстенлек бирелә. Кисүләр интенсивлыгы аз яисә уртача булырга, тулылылыгы 0,7дән кимемәскә тиеш.

Реликт һәм эндемик урман үсентеләре булган аеруча якланучы урман кишәрлекләрендә урманнарны карау өчен кисүләр интенсивлыгы кыйммәтле үсемлекләр үсеше өчен шартларны яхшыртуны исәпкә алып билгеләнә.

Фәнни һәм тарихи әһәмияте булган урманнарда урманнарны карау өчен кисүләр интенсивлыгы түбән була, аларда урманнардан файдалану максатларына каршы килми торган очракларда гына берән-сәрән агачлар киселә.

Дәүләт яклаучы урман полосаларында урманнарны карау өчен кисүләр кимендә 50% сәламәт агачы булган очракта гына гамәлгә ашырыла. Калган очракларда реконструкцияләү кисүләре генә уздырыла.

Эрозиягә каршы табигый һәм ясалма барлыкка китерелгән урманнарда, эрозиягә каршы әһәмияте булган махсус яклаучы урман кишәрлекләрен дә кертеп, урманнарны карау өчен кисүләр белән югары тыгызлыгы булган (тулылылыгы 0,7-0,8), төрле яшьтәге һәм катлаулы (ике һәм күп яруслы) тамыр системалары куәтле агачлар өстенлек иткән урман үсентеләре формалаштырыла.

Махсус яклаучы урман кишәрлекләрендә көртлекләр гөлдери торган урыннарда, сирәк һәм бетеп бара торган кыргый хайваннар яши торган урыннарда, кондызлар яши торган елгалар буйларындагы урман полосаларында бары тик корыган һәм кибеп баручы агачлар гына киселә.

Махсус хуҗалык әһәмияте булган урман кишәрлекләрендә (урман үсентеләре – бал бирүче, орлык бирүче урман плантацияләре, даими орлык бирүче урман үсентеләре һәм башкалар) урманнарны карау өчен кисүләр ярдәмендә хуҗалык максатларына мөмкин кадәр туры килә торган (шаулап чәчәк атучы һәм җимеш бирүче, тиешле формадагы һәм корылыштагы, шулай урман кишәрлекләре башка максатчан сыйфатларга һәм характеристикаларга ия булган) урман үсентеләре формалаштырыла.

Яклаучы урман полосалары бүлеп бирелгән тимер һәм автомобиль юллары янәшәсендәге 50-100 м урман авызларында урманнарны карау өчен кисүләр тотрыклы, асылда катнаш һәм төрле яшьтәге урман үсентеләрен, шулай ук, бертөрлелектән һәм ландшафт бертөрлелегеннән котылу өчен төрле токымдагы, формадагы һәм корылыштагы урман үсентеләрен формалаштыруга юнәлдерелә.

Агач материалы әзерләүгә бәйләнмәгән урманнарны карау чаралары уздыру таләп ителә торган мәйданнар күләмнәре 2.17.3.4 нче таблицада китерелә.

2.17.3.4 нче таблица

Яшь агачларны карау һәм агач материалы әзерләүгә бәйләнмәгән урманнарны карауның бүтән чаралары нормативлары һәм параметрлары

| Токымнар | Мәйдан, га | Киселә торган запас, $м^3$ | Кабатлану срогы | Еллык күләм | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәйдан, га | киселеә торган запас м3 | |
| | | | | | гомуми | 1 гектардан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Яктыртулар | | | | | | |

| Токымнар | Мәйдан, га | Киселә торган запас, $м^3$ | Кабатла-ну срогы | Еллык күләм | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәйдан, га | киселеә торган запас м3 | |
| | | | | | гомуми | 1 гектар-дан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Нарат | 144 | 1,02 | 3 | 48 | 0,34 | 7 |
| Чыршы | 5 | 0,08 | 3 | 2 | 0,03 | 15 |
| **Барлыгы ылыслылыр** | 149 | 1,10 | | 50 | 0,37 | 7 |
| Имән биек кәүсәле | 37 | 0,23 | 3 | 12 | 0,08 | 6 |
| Имән тәбәнәк кәүсәле | 1 | 0,02 | 3 | | 0,01 | 15 |
| **Барлыгы каты яфраклылар** | **38** | **0,25** | | **12** | **0,09** | **7** |
| Каен | 8 | 0,07 | 3 | 2 | 0,02 | 9 |
| Усак | 1 | 0,02 | 3 | 1 | 0,01 | 14 |
| **Барлыгы йомшак яфраклылар** | **9** | **0,09** | | **3** | **0,03** | **10** |
| **Барлык яктыртулар** | | | | | | |
| | **196** | **1,44** | | **65** | **0,49** | 7 |
| **Чистартулар** | | | | | | |
| Нарат | 768 | 13,17 | 8 | 96 | 1,65 | 17 |
| Чыршы | 126 | 2,43 | 8 | 16 | 0,30 | 19 |
| карагай | 8 | 0,13 | 8 | 1 | 0,02 | 16 |
| **Барлыгы ылыслылар** | **902** | **15,73** | | **113** | **1,97** | **17** |
| Имән биек кәүсәле | 138 | 1,53 | 5 | 27 | 0,30 | 11 |
| Имән тәбәнәк кәүсәле | 8 | 0,13 | 5 | 2 | 0,03 | 17 |
| **Барлыгы каты яфраклылар** | 146 | 1,66 | | 29 | 0,33 | 11 |
| Каен | 24 | 0,40 | 8 | 3 | 0,05 | 16 |
| Усак | 2 | 0,03 | 5 | 1 | 0,01 | 15 |
| Юкә | 11 | 0,25 | 5 | 2 | 0,05 | 23 |
| **Барлыгы йомшак яфраклылар** | **37** | **0,68** | | **6** | **0,11** | **19** |
| **Барлыгы чистартулар** | | | | | | |
| | **1085** | **18,07** | | **148** | **2,41** | **16** |
| **Барлыгы яшь үсентеләрне карау** | | | | | | |
| | **1281** | **19,51** | | **213** | **2,90** | **14** |
| Шул исәптән: ылыслылар | 1051 | 16,83 | | 1632 | 2,34 | 15 |
| каты яфраклылар | 184 | 1,91 | | 41 | 0,42 | 12 |
| Йомшак яфраклылылар | 46 | 0,77 | | 9 | 0,14 | 17 |

Урман үсү шартлары типларын, бонитетлар классларын, урманнарны караганчы составы буенча урман үсентеләре төркемнәрен, караганнан соң

ябалдашның минималь йомыклыгын, агачлар саны һәм массасы буенча сайлап алу процентын күрсәтеп, һәр күбрәк токым буенча кисүләр режимының Россия Федерациясе ТРМның 16.07.2007 № 185 боерыгы белән расланган Урманнарны карау кагыйдәләре белән билгеләнгән нормативлары 2.17.3.5 нче таблицада китерелә.

2.17.3.5 нче таблица

Урман барлыкка китерүче төп токымнарның урман үсентеләрендә токымын һәм сыйфатын яхшырту максатларында ылыслы-киң Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы урманнар районындагы урманнар типлары төркемнәре буенча кисүләр режимы нормативлары

| Кисүләргә кадәр урман үсентеләре составы | Урман типлары төркемнәре (бонитет классы) | Карый башлау яше, ел | Яктырту | | Чистарту | | Кисүләр яшенә максатчан состав (өлгергәнлек) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | карауга кадәр ябалдашларның минималь йомыклыгы | кисүләр интенсивлыгы, запас буенча % | карауга кадәр ябалдашларның минималь йомыклыгы | кисүләр интенсивлыгы, запас буенча % | |
| | | | караганнан соң | кабатланыш (ел) | караганнан соң | кабатланыш (ел) | |
| 1. Нарат үсентеләре | | | | | | | |
| 1.1. Нарат үсентеләре, чиста һәм 2 берәмлеккә кадәр яфраклылар катыш | лишайниклы (III-IV) | 8-10 | 0,9 | 15-20 | 0,9 | 15-20 | 8С2 Б |
| | | | 0,7 | 6-10 | 0,7 | 10-15 | |
| | нарат җиләкле (II-I) | 5-10 | 0,8 | 20-25 | 0,8 | 20-25 | (8-9) С |
| | | | 0,6 | 6-8 | 0,6 | 8-10 | (1-2) Б |
| | катлаулы (I - Ia) | 5-10 | 0,8 | 25-30 | 0,8 | 25-30 | (9-10) С |
| | | | 0,6 | 5-7 | 0,6 | 7-10 | (1-+) Б |
| | кара җиләкле (I - II) | 5-10 | 0,9 | 20-25 | 0,9 | 20-25 | (8-9) С |
| | | | 0,7 | 6-8 | 0,7 | 8-10 | (1-2) Б |
| | озын мүкле (III) | 8-10 | 0,9 | 20-25 | 0,9 | 15-25 | 8С2Б |
| | | | 0,7 | 6-10 | 0,7 | 8-10 | |
| 1.2. Составында нарат өстенлек итә торган нарат-яфраклылар (5-7 нарат, 3-5 яфраклы) | лишайниклы (III-IV) | 4-7 | 0,9 | 20-30 | 0,9 | 20-30 | (7-8) С |
| | | | 0,6 | 6-8 | 0,7 | 10-15 | (2-3) Б |
| | нарат җиләкле (II-I) | 3-6 | 0,7 | 30-50 | 0,7 | 30-50 | (8-9) С |
| | | | 0,5 | 4-6 | 0,5 | 8-12 | (1-2) Б |
| | катлаулы (I-Ia) | 3-5 | 0,6 | 35-60 | 0,6 | 30-50 | (8-10) С |
| | | | 0,4 | 3-5 | 0,4 | 8-12 | (0-2) Б |
| | кара җиләкле (I-II) | 3-6 | 0,7 | 30-50 | 0,7 | 30-50 | (7-9) С |
| | | | 0,5 | 4-6 | 0,5 | 8-12 | (1-3) Б |
| | озын мүкле (III) | 4-7 | 0,8 | 30-40 | 0,8 | 25-35 | (6-8) С |
| | | | 0,6 | 5-7 | 0,6 | 8-12 | (2-4) Б |
| 1.2.1. Составында 3-4 берәмлек нарат һәм 6-7 | нарат җиләкле (II-I) | 3-5 | 0,7 | 35-60 | 0,7 | 35-60 | (6-8) С |
| | | | 0,4 | 3-5 | 0,4 | 8-10 | (2-4) Б |
| | катлаулы (I-Ia) | 3-5 | 0,6 | 40-70 | 0,6 | 40-60 | (6-9) С |

| Кисүләргә кадәр урман үсентеләре составы | Урман типлары төркемнәре (бонитет классы) | Карый башлау яше, ел | Яктырту | | Чистарту | | Кисүләр яшенә максатчан состав (өлгергәнлек) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | карауга кадәр ябалдашларның минималь йомыклыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | карауга кадәр ябалдашларның минималь йомыклыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | |
| | | | караганнан соң | кабатланыш (ел) | караганнан соң | кабатланыш (ел) | |
| яфраклы катыш нарат-яфраклылар | | | 0,3 | 3-5 | 0,4 | 8-10 | (1-4) Б |
| | кара җиләкле (I-II) | 3-5 | 0,6<br>0,3 | 40-70<br>3-5 | 0,6<br>0,4 | 40-50<br>8-10 | (6-8) С<br>(2-4) Б |
| | озын мүкле (III) | 4-6 | 0,7<br>0,5 | 30-50<br>4-6 | 0,7<br>0,5 | 30-45<br>8-12 | (5-7) С<br>(3-5) Б |
| 1.3. Яфраклы-наратлы (агачлар җитәрлек санда булганда 7 берәмлектән артык яфраклы, 3 берәмлек нарат) | нарат җиләкле | 3-5 | 0,6<br>0,4 | 40-60<br>3-6 | 0,7<br>0,4 | 40-60<br>10-15 | (5-8) С<br>(2-5) Б |
| | катлаулы | 3-5 | 0,5<br>0,3 | 40-70<br>3-5 | 0,6<br>0,4 | 40-60<br>10-15 | (6-9) С<br>(1-4) Б |
| | кара җиләкле | 4-6 | 0,6<br>0,4 | 40-70<br>4-6 | 0,6<br>0,4 | 40-50<br>10-15 | (5-8) С<br>(2-5) Б |
| | озын мүкле | 4-7 | 0,7<br>0,4 | 30-60<br>5-7 | 0,7<br>0,5 | 30-45<br>8-12 | (4-7) С<br>(3-6) Б |
| 2. Чыршы үсентеләре | | | | | | | |
| 2.1. Чыршы үсентеләре: чиста һәм 2 берәмлеккә кадәр яфраклылар катыш | катлаулы (Ia-I) | 8-10 | 0,8<br>0,6 | 15-30<br>5-8 | 0,8<br>0,6 | 15-30<br>6-8 | (9-10) Е<br>(0-1) Б<br>(Ос) |
| | кара җиләкле (I-II) | 8-10 | 0,8<br>0,5 | 20-35<br>6-8 | 0,8<br>0,6 | 15-25<br>6-8 | (8-9) Е<br>(1-2) Б<br>(Ос) |
| | елга буе (II-III) | 8-10 | 0,8<br>0,5 | 20-35<br>6-8 | 0,8<br>0,6 | 15-25<br>6-8 | (8-9) Е<br>(1-2) Б<br>(Ос) |
| 2.2. Составында чыршы өстенлек итә торган чыршы-яфраклылар (5-7 чыршы, 3-5 яфраклы) | катлаулы (Ia-I) | 6-8 | 0,7<br>0,5 | 30-40<br>4-6 | 0,7<br>0,5 | 30-40<br>8-10 | (9-10) Е<br>(0-1) Б<br>(Ос) |
| | кара җиләкле (I-II) | 6-8 | 0,7<br>0,5 | 30-40<br>4-6 | 0,7<br>0,5 | 30-40<br>8-10 | (8-9) Е<br>(1-2) Б<br>(Ос) |
| | елга буе (II-III) | 6-8 | 0,7<br>0,5 | 30-40<br>4-6 | 0,7<br>0,5 | 30-40<br>8-10 | (8-9) Е<br>(1-2) Б<br>(Ос) |
| 2.2.1. Чыршылы-яфраклы (агачлар җитәрлек санда булганда 7 берәмлектән артык яфраклы, 3 берәмлек чыршы) | катлаулы (Ia-I) | 4-6 | 0,6<br>0,3 | 50-60<br>4-6 | 0,6<br>0,4 | 50-60<br>4-8 | (8-10) Е<br>(0-2) Б<br>(Ос) |
| | кара җиләкле (I-II) | 4-6 | 0,6<br>0,3 | 50-60<br>4-6 | 0,6<br>0,4 | 40-50<br>4-8 | (8-9) Е<br>(1-2) Б<br>(Ос) |
| | елга буе (II-III) | 4-6 | 0,6<br>0,3 | 50-60<br>4-6 | 0,6<br>0,4 | 40-50<br>4-8 | (8-9) Е<br>(1-2) Б |

| Кисүләргә кадәр урман үсентеләре составы | Урман типлары төркемнәре (бонитет классы) | Карый баш-лау яше, ел | Яктырту | | Чистарту | | Кисүләр яшенә максатчан состав (өлгергәнлек) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | карауга кадәр ябалдашларның минималь йомыклыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | карауга кадәр ябалдаш-ларның мини-маль йомык-лыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | |
| | | | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | |
| | | | | | | | (Ос) |
| 2.3. Яфраклы-чыршылы, яфраклылар ябалдаларшы астында чыршы агачлары җитәрлек санда булганда | катлаулы (Iа-I) | 4-6 | юк<br>огр. | юк<br>огр.<br>4-6 | юк<br>огр. | юк<br>огр.<br>4-8 | (8-10) Е<br>(0-2) Б<br>(Ос) |
| | кара җиләкле (I-II) | 4-6 | юк<br>огр. | юк<br>огр.<br>4-6 | юк<br>огр. | 40-50/100<br>4-8 | (7-8) Е<br>(2-3) Б<br>(Ос) |
| | елга буе (II-III) | 4-6 | юк<br>огр. | юк<br>огр.<br>4-6 | юк<br>огр. | 40-50/100<br>4-8 | (>4) Е<br>(<6) Б<br>(Ос) |
| 3. Имән үсентеләре | | | | | | | |
| 3.1. Имән үсентеләре чиста һәм 2 берәмлеккә кадәр башка токымнар катыш | Имәнлекләр яңа, юкәле-чикләвекле (II-I) | - | - | 0,8<br>0,7 | 20-35<br>5-10 | 20-25<br>15-20 | (8-9) Д<br>(1-2) Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр яңа (III-II; IV) | - | - | 0,8<br>0,7 | 20-30<br>5-10 | 15-20<br>15-20 | (8-9) Д<br>(1-2) Лп,<br>Е, Др.п. |
| | Имәнлекләр дымлы, озын үләнле | - | - | 0,8<br>0,7 | 20-35<br>5-10 | 20-25<br>15-20 | (8-9) Д<br>(1-2) Лп, Е,<br>др.п. |
| | Имәнлекләр дымлы, юкәле (III-IV; II) | - | - | 0,8<br>0,7 | 20-30<br>5-10 | 15-20<br>15-20 | (8-9) Д<br>(1-2) Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр елга буендагы – озын үләнле (II-III) | | - | 0,8<br>0,7 | 20-30<br>5-10 | 20-25<br>15-20 | (8-9) Д<br>(1-2) Ол.<br>ч., др.п. |
| 3.2. Составында имән өстенлек итә торган 5-7 берәмлек катнаш үсентеләр (йомшак яфраклылар һәм каты яфраклы токымнар) катыш | Имәнлекләр яңа, юкәле-чикләвекле (II-I) | 0,7<br>0,5 | 30-45<br>3-5 | 0,7<br>0,5 | 35-40<br>4-6 | 20-35<br>15-20 | (7-9) Д<br>(1-3) Лп,<br>Яс, Е |
| | Имәнлекләр яңа (III-II; IV) | 0, 7<br>0, 6 | 25-35<br>3-5 | 0,7<br>0,6 | 25-35<br>4-6 | 20-25<br>15-20 | (7-8) Д<br>(2-3) Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр | 0 | 30-4 | 0,7 | 30- | 20 | (7- |

| Кисүләргә кадәр урман үсентеләре составы | Урман типлары төркемнәре (бонитет классы) | Карый баш-лау яше, ел | Яктырту | | Чистарту | | Кисүләр яшенә максатчан состав (өлгергәнлек) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | карауга кадәр ябалдашларның минимальйомык-лыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | карауга кадәр ябалдаш-ларның мини-маль йомык-лыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | |
| | | | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | |
| | дымлы озын үләнле (II-III; I) | | | | | | |
| | | 0,7 0,5 | 0 | | 40 | -30 | 8)<br>Д |
| | Имәнлекләр дымлы, юкәле (III-IV; II) | 0,7<br>0<br>,5 | 3-5 | 0,5 | 4-6 | 15-<br>20 | (2-3)<br>Лп,<br>Е,<br>др. п. |
| | Имәнлекләр дымлы, юкәле (III-IV; II) | | 30-35<br>3-5 | 0,7<br>0,5 | 30-35<br>4-6 | 20-25<br>15-20 | (7-8) Д<br>(2-3)<br>Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр елга буендагы – озын үләнле (II-III) | 0,7<br>0,5 | 30-40<br>3-5 | 0,7<br>0,6 | 30-40<br>4-6 | 20-30<br>15-20 | (7-9) Д<br>(1-3)<br>Ол.<br>ч., др.п. |
| 3.2.1. Составында 3-4 берәмлек имән катыш катнаш үсентеләр | Имәнлекләр яңа, юкәле-чикләвекле (II-I) | 0,7<br>0,4 | 40-60<br>3-5 | 0,7<br>0,4 | 40-60<br>4-6 | 25-40<br>10-15 | (6-8) Д<br>(2-4)<br>Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр яңа юкәле-билчәнле (III-II; IV) | 0,7<br>0,5 | 30-50<br>3-4 | 0,7<br>0,5 | 30-50<br>4-6 | 25-30<br>10-15 | (6-8) Д<br>(2-4)<br>Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр дымлы, озын үләнле (III-IV; II) | 0,7<br>0,4 | 40-50<br>3-5 | 0,7<br>0,4 | 40-50<br>4-6 | 25-35<br>10-15 | (6-8) Д<br>(2-4)<br>Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр дымлы, юкәле (III-IV; II) | 0,7<br>0,5 | 40-50<br>3-5 | 0,7<br>0,5 | 40-50<br>4-6 | 25-35<br>10-15 | (6-8) Д<br>(2-4)<br>Лп,<br>Е, др.п. |
| | Имәнлекләр елга буендагы – озын үләнле (II-III) | 0,7<br>0,5 | 40-60<br>3-5 | 0,7<br>0,5 | 40-60<br>4-6 | 25-40<br>10-15 | (6-7) Д<br>(3-4)<br>Ол.<br>ч., др.п. |
| 3.3. Йомшак яфраклылар өстенлек итә | Имәнлекләр яңа, юкәле-чикләвекле (II-I) | 0,6<br>0,3 | 50-80<br>3-5 | 0,6<br>0,3 | 50-70<br>4-6 | | (5-7) Д<br>(3-5)<br>др.п. |

| Кисүләргә кадәр урман үсентеләре составы | Урман типлары төркемнәре (бонитет классы) | Карый баш-лау яше, ел | Яктырту | | Чистарту | | Кисүләр яшенә максатчан состав (өлгергәнлек) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | караугa кадәр ябалдашларның минималь йомык-лыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | караугa кадәр ябалдаш-ларның мини-маль йомык-лыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | |
| | | | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | |
| торган һәм составында кимендә 3 берәмлек имән катыш, әмма җитәрлек санда булмаган катлаулы үсентеләр | Имәнлекләр яңа юкәле-билчәнле (III-II; IV) | 0,6<br>0,4 | 40-70<br>3-5 | 0,6<br>0,5 | 40-60<br>4-6 | | (4-7) Д<br>(3-6)<br>др.п. |
| Составында имән өстенлек иткән агачлар формалаштыру өчен аларның саны | Имәнлекләр дымлы, озын үләнле | 0,6<br>0,4 | 40-70<br>3-5 | 0,6<br>0,5 | 40-60<br>4-6 | | (4-7) Д<br>(3-6)<br>др.п. |
| | Имәнлекләр дымлы, юкәле (III-IV; II) | 0,6<br>0,4 | 40-70<br>3-5 | 0,6<br>0,5 | 40-60<br>4-6 | | (4-7) Д<br>(3-6)<br>др.п. |
| | Имәнлекләр елга буендагы – озын үләнле (II-III) | 0,6<br>0,4 | 40-70<br>3-5 | 0,6<br>0,5 | 40-60<br>4-6 | | (4-7) Д<br>(3-6)<br>Ол. ч,<br>др. п. |
| 4. Каен үсентеләре | | | | | | | |
| 4.1. Каен үсентеләре: чиста һәм башка токымнар катыш | нарат җиләкле-кылганлы - (II-I) | - | - | >0,8<br>0,7 | 20-25<br>5-10 | 25-30<br>10-15 | (8-10) Б<br>(0-2) С |
| | катлаулы вак үләнле (II-I) | - | | >0,8<br>0,7 | 20-30<br>5-10 | 25-30<br>10-15 | (8-10) Б<br>(0-2) С<br>(Е) |
| | кара җиләкле-вак үләнле (II-III) | - | - | >0,8<br>0,7 | 20-25<br>5-10 | 25-30<br>10-15 | (8-10) Б<br>(0-2) С<br>(Е) |
| | озын мүкле (III-IV) | - | - | >0,8<br>0,7 | 15-20<br>5-10 | 20-25<br>10-15 | (8-10) Б<br>(0-2) С |
| | катлаулы киң үләнле (Ia-I) | - | - | >0,8<br>0,7 | 25-35<br>5-10 | 25-35<br>10-15 | (8-10) Б<br>(0-2) Е<br>(С) |
| | кара җиләкле-киң үләнле (I-II) | - | - | >0,8<br>0,7 | 20-30<br>5-10 | 25-30<br>10-15 | (8-10) Б<br>(0-2) Е<br>(С) |
| | елга буендагы – озын үләнле (II-III) | - | - | >0,8<br>0,7 | 20-25<br>5-10 | 20-25<br>10-15 | (8-10) Б<br>(0-2) Е |
| 4.2.Каен-усак | катлаулы вак үләнле | 0,8 | 20-40 | 0,8 | 20-40 | 20-40 | (8-10) Б |

| Кисүләргә кадәр урман үсентеләре составы | Урман типлары төркемнәре (бонитет классы) | Карый баш-лау яше, ел | Яктырту: карауга кадәр ябалдашларның минималь йомыклыгы / караганнан соң | Яктырту: кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % / кабатланыш (ел) | Чистарту: карауга кадәр ябалдашларның мини-маль йомык-лыгы / караганнан соң | Чистарту: кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % / кабатланыш (ел) | Кисүләр яшенә максатчан состав (өлгергәнлек) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| үсентеләре, башка токымнар | (II-I) | 0,6 | 5 | 0,6 | 5-10 | 10-15 | (0-2) С (0-+) Ос |
| | кара җиләкле-вак үләнле (II-III) | 0.8 0,6 | 20-40 5 | 0,8 0,6 | 20-40 5-10 | 20-40 10-15 | (8-10) Б (0-2) С (0-+) Ос |
| | катлаулы киң үләнле (Ia-I) | 0,8 0,6 | 20-40 5 | 0,8 0,6 | 20-40 5-10 | 20-40 10-15 | (8-10) Б (0-2) Е, С (0-+)Ос |
| | кара җиләкле-киң үләнле (I-II) | 0,8 0,6 | 20-40 5 | 0,8 0,6 | 20-40 5-10 | 20-40 10-15 | (8-10) Б (0-2) Е (0-+) Ос |
| | елга буендагы – озын үләнле (II-III) | 0,8 0,6 | 20-35 5 | 0,8 0,6 | 20-35 5-10 | 20-30 10-15 | (8-10) Б (0-2) Е (0-+) Ос |
| 4.3. Каен-чыршы (каен ябалдашлары астында чыршы агачлары саны җитәрлек-икенче ярус чыршы яисә шытымнар) | катлаулы киң үләнле (Ia-I) | 0,8 0,7 | 20-30 5 | 0,8 0,7 | 20-30 5-10 | 25-35 10-15 | (7-10) Б (0-3) Е II яр. (Пдр) 10 Е |
| | кара җиләкле-киң үләнле (I-II) | 0,8 0,7 | 20-30 5 | 0,8 0,7 | 20-30 5-10 | 25-35 10-15 | (7-10) Б (0-3) Е II яр. (Пдр)10 Е |
| | елга буендагы – озын үләнле (II-III) | 0,8 0,7 | 20-30 5 | 0,8 0,7 | 20-30 5-10 | 25-35 10-15 | (7-10) Б (0-3) Е II яр. (Пдр)10 Е |
| 5. Усак үсентеләре | | | | | | | |
| 5. .1. Усак үсентеләре: чиста һәм башка токымнар катыш | катлаулы вак үләнле (II-I) | - | - | >0,8 0,6 | 30-40 5-7 | 30-35 10-15 | (7-10) Ос (0-3) Е, Б |
| | кара җиләкле- вак үләнле (III-II) | - | - | 0,8 0,6 | 30-35 5-7 | 25-30 10-15 | (7-10) Ос (0-3) Е, Б |
| | катлаулы киң үләнле | - | - | >0,8 | 30-40 | 30-35 | (7-10) |

| Кисүләргә кадәр урман үсентеләре составы | Урман типлары төркемнәре (бонитет классы) | Карый баш-лау яше, ел | Яктырту | | Чистарту | | Кисүләр яшенә максатчан состав (өлгергәнлек) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | карауга кадәр ябалдашларның минималь йомык-лыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | карауга кадәр ябалдаш-ларның мини-маль йомык-лыгы | кисүләр интенсив- лыгы, запас буенча % | |
| | | | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | караган-нан соң | кабатла-ныш (ел) | |
| | (Ia-I) | | | 0,6 | 5-7 | 10-15 | Ос (0-3) Е, С, Б |
| | кара җиләкле-киң үләнле (I-II) | - | - | 0,8<br>0,6 | 30-35<br>5-7 | 25-30<br>10-15 | (7-10) Ос (0-3) Е, С, Б |
| | елга буендагы – озын үләнле (II-I) | - | - | 0,8<br>0,7 | 25-35<br>5-7 | 25-30<br>10-15 | (7-10) Ос (0-3) Е, Б |
| 5.2. Усак-чыршы (усак ябалдашлары астында чыршы агачлары саны җитәрлек-икенче ярус чыршы яисә шытымнар) | катлаулы киң үләнле (Ia-I) | 0,8<br>0,5 | 30-45<br>4-6 | 0,8<br>0,5 | 35-45<br>5-8 | 30-40<br>10-15 | (7-10) Ос (0-3) Е, Б II яр. (Пдр) 10Е |
| | кара җиләкле-киң үләнле (I-II) | 0,8<br>0,6 | 30-40<br>4-6 | 0,8<br>0,6 | 30-40<br>5-8 | 25-35<br>10-15 | (7-10) Ос (0-3) Е, С, Б II яр. (Пдр) 10Е |
| | елга буендагы – озын үләнле (II-I) | 0,8<br>0,6 | 30-40<br>4-6 | 0,8<br>0,6 | 30-40<br>5-8 | 25-35<br>10-15 | (7-10) Ос (0-3) Е, Б II яр. (Пдр) 10Е |
| 6. Юкә үсентеләре | | | | | | | |
| 4. | Рәт араларын 13 мәртәбә (4 – 3 – 2 – 1) кара-каршы культивацияләү – 3,33 км | МТЗ-80<br>(МТЗ-50)<br>КЛ-2,6 | м/см<br>м/см | 4,33<br>4,33 | 4,33<br>4,33 | 4,33<br>4,33 |
| 5. | 40 х 40 см = 177,6 кв. м зурлыктагы 1110 үрчетү мәйданчыкларында җиде мәртәбә (3 – 2 – 1 – 1) туфракны кулдан йомшарту һәм чүп үләннәрен утау (177,6 Х 7 = 1243,2 кв. м) | | кеше/сәг | 11,03 | 15,42 | 24,86 |

| № т/с | Эшләр атамалары | Машиналар һәм кораллар маркалары | Үлчәү бер. | Чыгымнар күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Туфрак категориясе | | |
| | | | | җиңел | уртача | авыр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Вариант – кара-каршы культивацияләү мөмкин булмаган тар кишәрлекләрдә | | | | | | |
| 4а. | Рәт араларын 13 мәртәбә (4–3–2–1) культивацияләү (3,33 х 13 = 43,29 см.) | МТЗ-80 (МТЗ-50)<br>КЛ-2,6 (Т-74, БДСТ-2,5) | м/см<br>м/см | 2,16<br>2,16 | 2,16<br>2,16 | 2,16<br>2,16 |
| 5а. | 40 см киңлектәге полосаларда җиде мәртәбә (3 – 2 – 1 – 1) туфракны кулдан йомшарту һәм чүп үләннәрен утау – 1330 кв. м (1330 х 7 = 9310 кв. м) | | кеше/сәг | 82,58 | 115,44 | 186,20 |
| Урман бүлемтеген карау | | | | | | |
| 6. | 1110 агачның аскы ботакларын кисү:<br>а) ике- өч еллык утыртмаларда<br>б) биш - алты еллык утыртмаларда | | <br>кеше/сәг<br>кеше/сәг | <br>20,76<br>51,73 | <br>20,76<br>51,73 | <br>20,76<br>51,73 |
| Чыгымнар җыелмасы | | | | | | |
| | Трактор МТЗ-80<br>Трактор – 74<br>Культиватор КЛ-2,6<br>Урман утырту машинасы ССН-1<br>Эләктергеч СБ-9<br>Урман хуҗалыгы эшчеләре<br>Тамыр җибәргән тополь ботаклары | | м/см<br>м/см<br>м/см<br>м/см<br>м/см<br>кеше/сәг<br>мең. шт. | 4,33<br>0,11<br>4,33<br>0,33<br>0,11<br>102,92<br>1,11 | 4,33<br>0,11<br>4,33<br>0,33<br>0,11<br>107,31<br>1,11 | 4,33<br>0,11<br>4,33<br>0,33<br>0,11<br>116,75<br>1,11 |
| | Вариант<br>Трактор – МТЗ-80<br>Трактор – 74<br>Культиватор КЛ-2,6<br>Урман утырту машинасы ССН-1<br>Эләктергеч СБ-9<br>Урман хуҗалыгы эшчеләре<br>Тамыр җибәргән тополь ботаклары | | <br>м/см<br>м/см<br>м/см<br>м/см<br>м/см<br>кеше/сәг<br>мең. шт. | <br>2,16<br>0,11<br>2,16<br>0,33<br>0,11<br>174,47<br>1,11 | <br>2,16<br>0,11<br>2,16<br>0,33<br>0,11<br>207,33<br>1,11 | <br>2,16<br>0,11<br>2,16<br>0,33<br>0,11<br>278,09<br>1,11 |

## Исәпләү-технология картасы № 36
## МПР-2 машинасы белән чистартыла торган 2,0 м коридорларда (полосаларда) чәчкеннәр утырту юлы белән биеклеге 4 метрга кадәр булган кыйммәте аз яшь агачларны реконструкцияләү

Урман үсү шартлары тибы: яңа һәм дымлы нарат катыш урманнар, ылыслылар катыш урманнар һәм бер генә токым ылыслылар урманнары – В2-3, С2, Д2, Д3 (нарат җиләкле, яңа кара җиләкле, куаксыман ачы җиләкле).

Туфраклар: кәсле-кәсле-көлсу, соры урман һәм кәсле-комлы һәм ярым балчыклы, селтеле кара туфраклар һәм көлле ком катыш һәм ярым балчыклы.

Киселгән урыннар: иске, яфраклы токымнарның кыйммәте аз булган яшь агачлары каплап киткән.

Төп токымнар: нарат, чыршы, карагай, имән (киң яфраклы урманнар һәм урман-дала зоналарында).

Культуралара схемалары

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. С – С – С – С | 2. Е – Е – Е – Е | 3. Л – Сп – Сп – Л | 4. Д – Д – Д – Д |
| С – С – С – С | Е – Е – Е – Е | Л – Сп – Сп – Л | Д – Д – Д – Д |

1 гектарга чыгымнар

| Эшләр атамалары | Машиналар һәм кораллар маркалары | Үлчәү бер. | Чыгымнар күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Туфрак категориясе | | |
| | | | җиңел | уртача | авыр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. Коридор трассалары буенча 5 метр саен визирлар кисү – 2 м. | | кеше/сәг | 4,10 | 4,10 | 4,10 |
| 2. Тамырларын тарап, туфракны йомшартып һәм чокырларны тигезләп 2 метрлы коридорлар чистарту – 2 км | МПР-2 (КП-1) | м/см | 0,9 | 0,9 | 0,9 |
| 3. 2,67 мең чәчкенне вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү | | мең. шт. | 2,1 | 2,7 | 2,7 |
| 4. Рәттә 0,75 м саен чәчкеннәрне механикалаштырылган утырту – 2 км<br>а) Катнаш урманнар зонасында<br>Ылыслы токымнар чәчкеннәре | Т-74 (ЛХТ-55, ТДТ-40М, СУП-3)<br>СБН-1А | м/см<br>м/см<br>мең. шт. | 0,20<br>0,20<br>2,67 | 0,20<br>0,20<br>2,67 | 0,20<br>0,20<br>2,67 |
| 5. Туфракны йомшарту юлы белән культураларны механикалаштырылган карау:<br>а) катнаш урманнар зонасында дүрт мәртәбә (0 – 1 – 2 – 1) 2 х 4 = 8 км | МТЗ-80 (ЛХТ-55, ТДТ-40М, СУП-3)<br>КЛБ-1,7 | м/см<br>м/см | 0,72<br>0,90 | 0,72<br>0,90 | 0,72<br>0,90 |
| б) киң яфраклы урманнар һәм урман-дала зоналарында – 5 мәртәбә (0 – 2 – 2 – 1) 2 х 5 = 10 км | МТЗ-80 (ЛХТ-55, ТДТ-40М, СУП-3) | м/см | 0,90 | 0,90 | 0,90 |

| Эшләр атамалары | Машиналар һәм кораллар маркалары | Үлчәү бер. | Чыгымнар күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Туфрак категориясе | | |
| | | | җиңел | уртача | авыр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | КЛБ-1,7 | м/см | 0,90 | 0,90 | 0,90 |
| 6. Киң яфраклы урманнар һәм урман-дала зоналарында 50 см киңлектәге полосаларда туфракны кулдан йомшарту һәм чүп үләннәрен утау юлы белән культураларны өч мәртәбә (1 – 1 – 1) кулдан карау (1000 х 3 = 3000 кв. м) | | кеше/сәг | 26,61 | 37,20 | 60,00 |
| Чыгымнар җыелмасы | | | | | |
| Катнаш урманнар зонасында | | м/см | 0,20 | 0,20 | 0,20 |
| Трактор Т-74 | | м/см | 0,72 | 0,72 | 0,72 |
| Трактор МТЗ-80 | | м/см | 0,90 | 0,90 | 0,90 |
| Машина МПР-2 (КМ-1) | | м/см | 0,20 | 0,20 | 0,20 |
| Катламнар буенча урман утырту машинасы СБН-1М | | кеше/сәг | 10,48 | 10,48 | 10,48 |
| Урман хуҗалыгы эшчеләре | | мең. шт. | 2,67 | 2,67 | 2,67 |
| Ылыслы һәм яфраклы токымнар чәчкеннәре | | | | | |
| Киң яфраклы урманнар һәм урман-дала зонасында | | | | | |
| Трактор Т-74 | | м/см | 0,22 | 0,22 | 0,22 |
| Трактор МТЗ-80 | | м/см | 0,90 | 0,90 | 0,90 |
| Машина МПР-2 (КМ-1) | | м/см | 0,90 | 0,90 | 0,90 |
| Катламнар буенча урман утырту машинасы СБН-1М | | м/см | 0,22 | 0,22 | 0,22 |
| Урман хуҗалыгы эшчеләре | | кеше/сәг | 37,62 | 48,21 | 71,01 |
| Ылыслы һәм яфраклы токымнар чәчкеннәре | | мең. шт. | 2,67 | 2,67 | 2,67 |

18.3 нче таблица

## Төрле урман типлары төркемнәрендә урманнар капламаган җирләрне яңартуның өстенлекле алымнары

| Төп иң күп токым | Урман типлары төркемнәре | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | С бел. | С бр. | С чер | С пр. | С сф д. | С тр.лп | С к.ч. | С слж. | С т.ос | Е бр. | Е ч. | Е пр. | Е сф.д. | Е слж. | Е к. | Д слж. | Д пм. | Б ос | Б т.ос. | Ольш | Тал |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| 1. Ярдәмсез генә табигый яңару | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | - | | | + | + | | | - | | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | | - | - | + | + | | | | | | | | |
| Д, Я, Кл Ильм | | | | | | | | | | | | | | | | - | + | | | | |
| Б | | - | - | + | | - | - | - | | - | - | + | | - | - | - | + | + | - | | |
| Ос, Т | | | + | + | | - | - | - | | | - | + | | - | - | - | + | | | | |
| Лп | | | | | | - | | - | | | | | | - | - | - | + | | | | |
| Ольха ч. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | |
| Ива др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + |
| 2. Туфракны минеральләштереп, табигый яңаруга ярдәм | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | - | + | + | - | - | + | + | - | - | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | - | + | - | - | + | - | | | | | | | |
| Д, Я, Кл Ильм | | | | | | | | | | | | | | | - | - | | | | | |
| Б | | - | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Ос, Т | | | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Лп | | | | | | - | - | - | | | | | | - | - | - | | | | | |
| Ольха ч. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - | |
| Ива др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Төп иң күп токым | Урман типлары төркемнәре | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | С бел. | С бр. | С чер | С пр. | С сф д. | С тр.лп | С к.ч. | С слж. | С т.ос | Е бр. | Е ч. | Е пр. | Е сф.д. | Е слж. | Е к. | Д слж. | Д пм. | Б ос | Б т.ос. | Ольш | Тал |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| 3. Шытымнарны саклау | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | - | + | + | - | - | + | + | - | - | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | - | + | - | - | + | - | | | | | | | |
| Д, Я, Кл Ильм | | | | | | | | | | | | | | | - | - | | | | | |
| Б | | - | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Ос, Т | | | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Лп | | | | | | - | - | - | | | | | | - | - | - | | | | | |
| Ольха ч. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - | |
| Ива др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. Урман культуралары | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | + | + | + | - | - | + | + | + | + | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | | + | + | - | - | + | + | | | | | | |
| Д, Я, Кл Ильм | | | | | | | | | | | | | | | | + | - | | | | |
| Б | | + | + | - | - | + | + | + | + | + | + | | | + | + | + | | | | | |
| Ос, Т | | | + | - | - | + | + | + | + | + | + | | | + | + | + | | | | | |
| Лп | | | | | | | | + | | + | | | | | | + | | | | | |
| Ольха ч. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - | |
| Ива др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - |

Искәрмә: + - тәкъдим ителүче чара;
- - чара тәкъдим ителми;
Буш графа - әлеге токым бу урман типлары төркемнәренә хас түгел.

## 2.18. Урман үсү зоналары һәм урман районнары буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре

“Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урман районнары исемлеген раслау турында” 09.03.2011 № 61 Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы нигезендә Урманчылыкның барлык территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасының ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районында урнашкан.

Бүлектә китерелгән нормативлар Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасының ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районына туры килә.

# 3 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУНЫ ЧИКЛӘҮЛӘР

## 3.1. Урманнарны максатчан билгеләнеше төрләре буенча чикләүләр

Урманнарны максатчан билгеләнеше төрләре һәм яклаучы урманнар категорияләре буенча чикләүләр 3.1 нче таблицада китерелә.

3.1 нче таблица

**Урманнарны максатчан билгеләнеше төрләре буенча чикләүләр**

| № т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдалану буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Түбәндәгеләр тыела:<br>1) урман үсентеләрен тоташ кисүләр;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен агулы химик препаратлар куллану, шул исәптән фәнни максатларда;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре;<br>4) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>5) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, линия объектларыннан һәм гидротехник корылмалардан гайре. |
| 2. | Табигать һәм бүтән объектларның яклау функцияләрен үтәүче урманнар: | Урман үсентеләрен тоташ кисүләр тыела. |
| | Гомуми файдаланудагы тимер юллар, гомуми файдаланудагы федераль автомобиль юллары, Россия Федерациясе субъекты милкендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйларына урнашкан яклаучы полосалар | Түбәндәгеләр тыела:<br>1) техник регламент белән каралган киңлектән киңрәк итеп линия корылмаларны кисү;<br>2) урманда аяк асты җәймәсен һәм мүк җыю и әзерләү. |
| | а) урман паркы зоналары | Түбәндәгеләр тыела:<br>1) урманнарны саклау һәм яклау өчен агулы химик препаратлар куллану, шул исәптән фәнни максатларда;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру; |

| № т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдалану буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | 3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү;<br>5) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, гидротехник корылмалардан гайре.<br>6) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру. |
| | б) яшел зоналар | Түбәндәгеләр тыела:<br>1) урманнарны саклау һәм яклау өчен агулы химик препаратлар куллану, шул исәптән фәнни максатларда;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, шулай ук авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылык максатларында койма кою;<br>4) файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү;<br>5) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, гидротехник корылмалардан, элемтә линияләреннән, электрүткәргеч линияләрдән, җир асты торбаүткәргечләреннән гайре;<br>6) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру. |
| 3. | Кыйммәтле урманнар | Урман үсентеләрен тоташ кисүләр, әгәр сайлап алып кисүләр яклаучы урманнарның максатчан билгеләнешен саклап калуны тәэмин итә торган үз функцияләрен югалта барган урман үсентеләрен алмаштыруны тәэмин итми торган очраклардан гайре.<br>Түбәндәгеләр тыела:<br>1) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, гидротехник корылмалардан гайре;<br>2) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру. |
| 4. | Эксплуатацион урманнар | Урманнардан файдалануның барлык төрләре рөхсәт ителә. |

## 3.2. Урманнарның махсус яклаучы кишәрлекләрен төрләре буенча чикләүләр

Урманнарның махсус яклаучы кишәрлекләренең хокукый режимы Россия Федерациясе Урман кодексының 102, 107 статьялары, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының "Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигать һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәте булган урманнардан, шулай ук урманнарның махсус якланылучы кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 № 485 боерыгы (алга таба – Үзенчәлекләре) белән регламентлана.

Урманнарның махсус яклаучы кишәрлекләрендә аларның максатчан билгеләнешенә һәм файдалы функцияләренә туры килми торган эшчәнлек алып бару тыела.

Урманнарның махсус яклаучы кишәрлекләрен төрләре буенча чикләүләр 3.2 нче таблицада китерелә.

3.2 нче таблица

**Урманнарның махсус яклаучы кишәрлекләрен төрләре буенча чикләүләр**

| № т/с | Махсус яклаучы кишәрлекләр төрләре (МЯК) | Урманнардан файдалануны чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су объектлары буйларында, ярлар авышлыкларында урнашкан ярлар саклау, туфрак саклау урман кишәрлекләре.<br>Яр буе яклау полосалары чикләрендәге урман кишәрлекләре, киңлекләре түбәндәгечә:<br>авышлыгы киресенчә һәм бөтенләй булмаган су ярлары өчен – 30 м;<br>авышлыгы өч градуска кадәр булган су объекты яры өчен – 40 м;<br>авышлыгы өч градус һәм аннан да күбрәк булган су объекты яры өчен – 50 м;<br>агучы һәм торучы күлләр һәм тиешле су агулар сазлыклары чикләрендә урнашканнар өчен – 50 м;<br>ярлар авышлыгында урнашкан урманнар һәм яр кырыена килеп җиткән 50 метр киңлектәге урман | Түбәндәгеләр тыела:<br>- тоташ кисүләр уздыру, Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 4 өлешендә, 21 статьясындагы 5.1 өлешендә каралган очраклардан гайре;<br>- урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>- урман плантацияләрен булдыру;<br>- авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре;<br>- капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, гидротехник корылмалардан гайре;<br>- әлеге урман районында табигый шартларда үсми торган агачлар, куаклар, лианалар, башка урман үсентеләре төрләрен (токымнарын) интродукцияләү.<br>Сайлап алып кисүләр бары тик корыган һәм зарарланган урман |

| № т/с | Махсус яклаучы кишәрлекләр төрләре (МЯК) | Урманнардан файдалануны чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | полосалары. | үсентеләрендә генә уздырыла. Даими рәвештә орлык бирүче кишәрлекләрдә агач токымнарының җимеш бирүләрен карау тәртибендә сайлап алып кисүләр рөхсәт ителә. |
| 2. | Урмансыз киңлекләр белән чиктәш урман авызлары. Урмансыз киңлекләр чикләреннән 100 м киңлектә урнашкан, урман кырыеннан кимендә 1,5-2,0 км ераклыктагы урман авызлары. | |
| 3. | Даими рәвештә орлык бирүче кишәрлекләр.<br>Кыйммәте югары булган табигый урманнарның яисә урман культураларының җитештерүчәнлеге зур, озак чорга чәчү сыйфаты югары булган агач токымнары орлыкларын алу һәм даими әзерләү өчен формалаштырылган кишәрлекләре. | |
| 4. | Халыкара Кызыл китапка, Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән, реликт һәм эндемик үсемлекләре булган урман кишәрлекләре. | |
| 5. | Сирәк һәм юкка чыга баручы кыргый хайваннарның яшәү тирәлеге урыннары.<br>Халыкара Кызыл китапка, Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән, сирәк һәм юкка чыга баручы кыргый хайваннарның яшәү тирәлеге урыннары булган урман кишәрлекләре. | |
| 6. | Тыюлык урман кишәрлекләре.<br>Дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли паркларның тыюлык зоналары чикләренә кермәгән, хуҗалык эшчәнлеге белән аз бозылган, озак вакытлар табигый юл белән формалашкан 100-150 га | Тыюлык урман кишәрлекләрендә түбәндәгеләр тыела:<br><br>1) урман үсентеләрен кисүләр уздыру;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен агулы химик препаратлар куллану, шул исәптән фәнни максатларда; |

| № т/с | Махсус яклаучы кишәрлекләр төрләре (МЯК) | Урманнардан файдалануны чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | мәйданлы урман кишәрлекләре. | 3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү;<br>5) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру<br>6) урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>7) урман плантацияләрен булдыру. |
| 7. | Махсус яклаучы урман кишәрлекләре: | Түбәндәгеләр тыела:<br>- тоташ кисүләр уздыру, Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясындагы 4 өлешендә 21 статьясындагы 5.1 өлешендә каралган очраклардан гайре;<br>- урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>- урман плантацияләрен булдыру;<br>- авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре;<br>- капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, гидротехник корылмалардан гайре;<br>- әлеге урман районында табигый шартларда үсми торган агачлар, куаклар, лианалар, башка урман үсентеләре төрләрен (токымнарын) интродукцияләү.<br>Сайлап алып кисүләр бары тик корыган һәм зарарланган урман үсентеләрендә генә уздырыла. Даими рәвештә орлык бирүче кишәрлекләрдә агач токымнарының җимеш бирүләрен карау тәртибендә сайлап алып кисүләр рөхсәт ителә. |
| | Тау районнарында урмансыз киңлекләр белән чиктәш җирдә аның өске чиге буйлап 200 м киңлектәге урман полосалары. | |
| | Урмансыз киңлекләрләр арасында урнашкан 100 га урман кишәрлекләре. | |
| | Тау районнарында 100-200 м киңлектәге полосалар, җирле шартларга бәйле рәвештә, 2,5 мең га артык мәйданда су җыю чикләре буенча дулкыннар һәм субүләрләр буенда урнашкан, 20°тан артык дулкыннар һәм субүләрләр барлыкка китерә торган | |
| | Сөзәклек экспозициясенә бәйсез рәвештә 30° текә урыннар авышлыкларындагы урман кишәрлекләре. | |
| | Дәүләт табигать заказниклары һәм башка махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендәге, мәйданнары аларны барлыкка китергәндә билгеләнә торган урман кишәрлекләре (ООПТ аерым урман кишәрлекләрендә файдалану режимы башка территориягә караганда катгый урнаштырылганда). | |
| | Мәйданнары аларны барлыкка китергәндә билгеләнә торган, әмма | |

| № т/с | Махсус яклаучы кишәрлекләр төрләре (МЯК) | Урманнардан файдалануны чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләре буйлап кимендә 1000 м киңлектәге полосалы саклау зоналары чикләрендәге урман кишәрлекләре. | |
| | Көртлекләрнең гөлдерәү урыннары тирәли 300 м радиустагы урман кишәрлекләре, 10 мең га урманга 3 тән артык шундый урман кишәрлеге исәбеннән. | |
| | Елганың яисә кондызлар яши торган бүтән су объектының һәр яры буйлап 100 м киңлектәге урман полосалары. | |
| | Бал бирә торган кишәрлекләр (өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган урман үсентеләре, даими умартачылыклар тирәли 3 км радиуста юкә һәм ак сәрби өстенлек итә торган урманнар). | |
| | Агачларны даими рәвештә җентекләп үлчәү һәм озак чорда агач-куак үсентеләре белән капланган урында урман корылышы яисә урман хуҗалыгы тамгалары белән төзекләндерелгән һәм урман корылышы планшетларына кертелгән үсентеләрне төгәл чагылдыру өчен билгеләнгән даими сынау мәйданнары. | |
| | Шифаханәләр, балалар лагерьлары, ял йортлары, пансионатлар, туристик базалар һәм башка дәвалау һәм савыктыру учреждениеләре тирәли 1 километрдан артык булмаган радиуста (дәвалау-савыктыру урыннарын шифаханә (тау шифаханәсе) саклау округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында яисә урман | |

| № т/с | Махсус яклаучы кишәрлекләр төрләре (МЯК) | Урманнардан файдалануны чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | хуҗалыгын алып баруның һәм урманнардан файдалануның шундый ук режимы булган яклаучы урманнарның бүтән категорияләре урманнарында урнашмаган булсалар, алар бүленәләр. | |
| | 100 до 250 м киңлектәге урман полосалары, җирле шартларга карап, федераль яисә региональ туристик маршрутның ике ягына таба да. | |
| | Авыл торак пунктлары һәм бакчачылык ширкәтләре тирәли 1 км киңлектәге урман кишәрлекләре. | |

Искәрмә. Махсус яклаучы урман кишәрлекләре урнашкан җир һәм аларның мәйданы урманнар коруны проектлаганда күрсәтелә.

## 3.3. Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр

Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр 3.3 нче таблицада китерелә.

3.3 нче таблица

**Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр**

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Агач материалы әзерләү | Исәпләнелгән урман бүлемтегеннән артып китә торган күләмнәрдә (агач материалын алуның мөмкин булган күләме), шулай ук кисүләр яшьләрен бозып агач материалы әзерләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 29 статьясындагы 4 өлеше). Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 01.08.2011 № 337 боерыгы белән расланган Агач материалы әзерләү кагыйдәләре нигезендә:<br>а) елга һәм инеш үзәннәрен агач материалын өстерәп йөрү трассалары һәм урман юллары |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | сыйфатында файдалану рөхсәт ителми;<br>б) урман үсентеләрен, үсемлек капламын һәм туфракны зарарлау, урман бүлемтекләреннән читтә сәнәгать һәм бүтән калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;<br>в) юлларны, күперләрне һәм гади урман юлларын, шулай ук киптерү челтәрен, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, су агып төшү урыннарын, инеш-елгаларны сакларга кирәк;<br>г) ауган агачларны (киселгән һәм урман бүлемтегендә агачлар калдыруны кертеп) һәм киселеп тә, аударылмый калган агачларны калдырып китү, саклanyrga тиешле шытымнарны зарарлау яисә юк итү тыела.<br>д) чиктәш, квартал, урман бүлемтеге һәм башка баганаларны һәм агачлардагы, түмәрләрдәге тамгаларны, келәймәләрне һәм номерларны юк итү яисә зарарлау тыела;<br>е) кисү өчен билгеләнмәгән һәм әлеге Кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлыклану чыганакларын һәм плюслы агачларны кисү һәм зарарлау тыела;<br>ж) рөхсәт ителгән срок узганнан соң агач материалы әзерләү (вакытын кичереп), шулай ук файдалану хокукын туктатып торганнан яисә туктатканнан соң агач материалы әзерләү;<br>з) билгеләнгән срокта чыгарылмаган агач материалын урман бүлемтегендә калдыру рөхсәт ителми (вакытын кичереп тә);<br>и) агач материалын урман бүлемтекләренең технологик картасында каралмаган урыннарга чыгару, трелевкалау рөхсәт ителми;<br>к) урман бүлемтекләрен чистарту эшләрен үтәмәү яисә үз вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;<br>л) туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми.<br>Урман бүлемтекләрендә агач материалы әзерләгәндә үзләренең табигый ареаллары чикләрендә үсүче яшәргә сәләтле кыйммәтле агач токымнарын (имән, бук, корычагач, кедр, юкә, |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | күгагач, элмә, кара зирек, чәчүлек каштан) кисү рөхсәт ителми (тиешле агач токымы урман үсентеләре өчен урманнар составында мәйданы урманчылык мәйданының 1 процентыннан артмаган очракларда).<br>Халыкара Кызыл китапка, Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән төрләр саклап калынырга тиеш.<br>Агач материалын әзерләгәндә өлгергән, картайган, составында өч һәм аннан да күбрәк кедр булган урман үсентеләрен кисү рөхсәт ителми. |
| 2. | Чәер әзерләү | Түбәндәгеләргә кирт салу рөхсәт ителми:<br>а) заралы организмнарны юк иткәнче алар чыганакларындагы урман үсентеләренә;<br>б) урман янгыннары һәм башка тискәре факторлар аркасында зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман үсентеләренә;<br>в) Россия Федерациясе законнары нигезендә агач материалы әзерләү максатларында, өлгергән һәм картайган урман үсентеләрен тоташ яисә сайлап алып кисү рөхсәт ителми;<br>г) даими орлык бирүче урман кишәрлекләрендә, орлык бирүче урман плантацияләрендә, генетик резерватларда урнашкан урман үсентеләрендә, шулай ук плюслы агачларда, орлык бирүче чәчәклекләрдә һәм полосаларда (Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 24.01.2012 № 23 боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләренең 7 пункты). |
| 3. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен түбәндәге үсемлекләр төрләрен куллану тыела:<br>- Халыкара Кызыл китапка, Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән;<br>- наркотик чаралар дип танылган;<br>- агач материалы әзерләү рөхсәт ителми торган агач һәм куак төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгән.<br>Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | җыю радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 05.12.2011 № 512 боерыгы белән расланган Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю кагыйдәләре нигезендә:<br>- эрозиягә каршы урманнарда, су объектлары буйлап урнашкан яр саклаучы, туфрак саклаучы урман кишәрлекләрендә, шулай ук тулылыгы 0,8-1,0 булган һәм ябалдашлары кушылмаган яшь урман культураларында түмәр чәерен әзерләү рөхсәт ителми (13 пункт);<br>- каен тузы әзерләү өчен агачларны кисү тыела (14 пункт);<br>- табигать һәм бүтән объектларны яклау функцияләрен үтәү өчен урманнарда аяк асты җәймәсен җыю тыела (20 пункт). |
| 4. | Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю | Халыкара Кызыл китапка, Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән яисә наркотик чаралар дип танылган гөмбәләрне һәм кыргый үсүче үсемлекләрне әзерләү һәм җыю тыела.<br>Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.<br>Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 05.12.2011 № 511 боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю кагыйдәләре нигезендә:<br>- җиләк-җимеш әзерләү өчен җимеш бирүче агачларны кисү тыела (14 пункт);<br>- чикләвек әзерләгәндә агачларны һәм куакларны кисү, шулай ук агачлар һәм куаклар зарарлануга китерә торган алымнарны куллану тыела (15 пункт);<br>- гөмбәләр әзерләү аларның ресурслары сакланышын тәэмин итә торган алымнар белән башкарылырга тиеш (16 пункт); |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | - каен сутын әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәргә 5 ел кала рөхсәт ителә (17 пункт);<br>- азык-төлек урман ресурсларының башка төрләрен әзерләү аларның вак шытымнарына зыян китермәслек алымнар белән алып барылырга тиеш; үсемлекләрне тамырлары белән өзеп чыгару, яфракларына һәм тамыр сабакларына зарар китерү тыела (18 пункт). |
| 5. | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру | Яшел зоналарда һәм урман паркы зоналарында, шулай ук шәһәр урманнарында аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясындагы 3 өлешенең 2 пункты). |
| 6. | Авыл хуҗалыгы алып бару | Су саклау зоналарында, печән чабудан һәм умартачылыктан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 104 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты).<br>Яр буе яклау полосалары чикләрендә җирләрне сөрү, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйләүләр, ванналар оештыру тыела (Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы 17 өлешенең 1, 3 пунктлары).<br>Урман паркы зоналарында авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясындагы 3 өлешенең 3 пункты).<br>Яшел зоналарда, печән чабудан һәм умартачылыктан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару, шулай ук авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылык максатларында койма кою (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясындагы 5 өлешенең 2 пункты).<br>Шәһәр урманнарында авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясындагы 5.1 өлеше).<br>Тыюлык урман кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 107 статьясындагы 2 өлеше).<br>Махсус яклаучы урман кишәрлекләрендә, |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | тыюлык урман кишәрлекләреннән гайре, печән чабудан һәм умартачылыктан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 107 статьясындагы 2.1 өлеше). |
| 7. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфракны зарарлау;<br>б) бирелгән урман кишәрлеген һәм ананн читтәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш чүбе, агач материалы калдыклары, бүтән төр калдыклар белән чүпләү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату (Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 23.12.2011 № 548 боерыгы белән расланган Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләренең 9 пункты).<br>Агулы химик препаратлар куллану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 103 статьясындагы 5 өлеше, 104 статьясындагы 1 өлеше, 105 статьясындагы 3 өлешенең 1 пункты). |
| 8. | Рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру | Рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен бирелгән урман кишәрлекләредә табигать ландшафтлары, хайваннар дөньясы, үсемлекләр дөньясы объектлары, су объектлары сакланып калырга тиеш (Россия Федерациясе Урман кодексының 41 статьясындагы 3 өлеше).<br>Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы минстрлыгының 21.02.2012 № 62 боерыгы белән расланган Рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен урманнар әйләнә-тирә мохиткә һәм кешеләр сәламәтлегенә зарар китермәслек алымнар белән гамәлгә ашырыла (6 пункт); |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | - вакытлы корылмалар, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмалар урнаштыру иң беренче чиратта агачлар һәм куаклары булмаган кишәрлекләрдә рөхсәт ителә, андыйлары булмаганда – кыйммәте аз булган урман үсентеләре үсә торган кишәрлекләрдә, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда (8 пункт). |
| 9. | Урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү | Урман плантацияләре булдыру өчен түбәндәге урманнардан файдалану рөхсәт ителми:<br>а) су саклау зоналарында урнашкан урманнардан;<br>б) табигать һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан;<br>в) кыйммәте булган урманнардан;<br>г) махсус яклаучы кишәрлекләрдә урнашкан урманнардан (Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министлыгының 14.12.2010 № 485 боерыгы белән расланган Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигать һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәте булган урманнардан, шулай ук урманнарның махсус якланылучы кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу үзенчәлекләренең 30 пункты). |
| 10. | Урман җиләк-җимеш, декоратив үсемлекләрен үстерү | Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 05.12.2011 № 510 боерыгы белән расланган Урман җиләк-җимеш, декоратив үсемлекләрен үстерү кагыйдәләре нигезендә:<br>- урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү өчен беренче чиратта урман фондының урманныкы булмаган җирләреннән, шулай ук урман утыртылмаган урман бүлемтекләреннән, ачыклыклардан һәм урман үсемлекләре каплап алмаган, аларда урман культуралары утырткanчы урманнарның табигый торгызыла торган җирләреннән; рекультивацияләнергә тиешле җирләрдән (эшкәртелгән торфянниклардан һәм башкалардан) файдаланырга мөмкин (11 пункт).<br>- урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | үсемлекләр һәм дару үләннәрен урман ябалдашлары астында үстерү өчен реконструкция өчен билгеләнмәгән кыйммәте түбән булган урман кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин (12 пункт).<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр очрый торган урман кишәрлекләре урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану РФ УКның 59 статьясы нигезендә тыела (13 пункт). |
| 11. | Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү | Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 19.07.2011 № 308 боерыгы белән расланган Урман үсентеләренең утырту материалын үстерү кагыйдәләре нигезендә:<br>- урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен беренче чиратта урман фондының урманныкы булмаган җирләреннән, шулай ук урман утыртылмаган урман бүлемтекләреннән, ачыклыклардан һәм урман үсемлекләре каплап алмаган җирләрдән, урманнар урнашмаган бүтән категория җирләрдән файдаланырга мөмкин (11 пункт);<br>- урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсентеләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары яисә алар булмаганда урман үсентеләренең нормаль орлыклары кулланыла (12 пункт).<br>- урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсентеләренең районлаштырылмаган орлыкларын, шулай ук чәчү һәм башка сыйфатлары тикшерелмәгән урман үсентеләре орлыкларын куллану рөхсәт ителми (13 пункт).<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр очрый торган урман кишәрлекләрен урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану РФ УКның 59 статьясы нигезендә |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | тыела (14 пункт ). |
| 12. | Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану | Яшел зоналарда һәм урман паркларында, шулай ук шәһәр урмананары территорияләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясындагы 1 өлешендәге 4 пункты).<br>Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү эшләрен башкару максатларында урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр тыела:<br>а) агачларны аудару һәм урман кишәрлекләрен бульдозерлар ярдәмендә агач үсентеләреннән чистарту, чиктәш полосаларны һәм урман авызларын агач калдыклары белән чүпләү, урман авызы агачларының кәүсәләрен һәм үрелеп үскән тамырларын зарарлау, яңа киселгән агач материалын җәйге чорда махсус яклау чараларыннан башка саклау;<br>б) урман үсентеләрен су бастыру һәм озак вакыт су астында тоту;<br>в) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлек капламнарын һәм туфракны зарарлау;<br>г) бирелгән урман кишәрлегендә һәм аннан читтә урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач материалы, көнкүреш һәм башка калдыклар, чүп-чар белән чүпләү;<br>д) бирелгән урман кишәрлеге һәм аннан читтәге территорияләр мәйданнарын химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>е) транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның юлларсыз, үзләре салган маршрут буенча узулары, шул исәптән урман кишәрлегеннән читтә (Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 27.12.2010 № 515 боерыгы белән расланган Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану тәртибенең 18 пункты). |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 13. | Сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехник корылмаларны һәм махсуслаштырылган портларны төзү һәм эксплуатацияләү | Тыюлык урман кишәрлекләрендә сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехник корылмаларны һәм махсуслаштырылган портларны төзү һәм эксплуатацияләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 107 статьясындагы 2 өлешендәге 5 пункты). |
| 14. | Линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү | Линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителә:<br>а) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) бирелгән урман кишәрлеге янындагы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән төр калдыклар белән чүпләү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) бирелгән урман кишәрлегеннән һәм тиешле саклау зонасыннан читтә транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның юлларсыз, үзләре салган, билгеләнмәгән маршрутлар буенча йөрүләре (Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 10.06.2011 № 223 боерыгы белән расланган Линия объектларын төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалануның кагыйдәләренең 15 пункты).<br>Урман парклары зоналарында линия объектларын төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясындагы 3 өлешендәге 5 пункты). |
| 15. | Агач материалын һәм башка урман ресурсларын эшкәртү | Яклаучы урманнарда, шулай ук махсус яклanучы урман кишәрлекләрендә агач материалы эшкәртү инфраструктурасы булдыру тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 14 статьясындагы 2 өлеше).<br>Агач материалын һәм башка урман ресурсларын |

| № т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | эшкәртү өчен түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә өске сулар һәм туфрак эченә сулар агып төшүне бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>б) бирелгән урман кишәрлеген һәм аның янындагы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән төр калдыклар белән чүпләү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) бирелгән урман кишәрлегеннән һәм тиешле саклау зонасыннан читтә транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның юлларсыз, үзләре салган, билгеләнмәгән маршрутлар буенча йөрүләре (Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 12.12.2011 № 517 боерыгы белән расланган Агач материалы һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләренең 6 пункты). |
| 16. | Дини эшчәнлек башкару | Дини эшчәнлек башкарганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә өске сулар һәм туфрак эченә сулар агып төшүне бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеген һәм аның янындагы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән төр калдыклар белән чүпләү. |

_______________